www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 40 (1405) 14 октябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

Өч гасырлык бәйрәме уңаеннан Пермь төбәгендә, Татарстан фәне һәм мәдәнияте көннәренә багышлап, «300 ел бергә» дип исемләнгән зур җыен узды.

8



Рәссам Салават Негъмәтов эшләрендә аның гомумиләштерү, композиция кору, кысыр чаралар белән тирән мәгънәне күрсәтү осталыгы ачык күренә.

12

Теш табибе булып эшләгән Снежана Хәйруллина кырык яшендә сәнгать юлын сайлап, керамикага гашыйк булып, гомерен кискен үзгәртә.

24

Ачы-татлы балан тәлгәшләре – Күзгә учак кузы гүяки...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанда мобилизацияләнеп, Казан танк училищесы территориясендә урнаштырылганнарга "Татмедиа" АҖ газета-журналларын китереп торачаклар.

- Казанның азык-төлек һәм социаль туклану департаменты генераль директоры Рима Мөхәммәтшина Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләре комитеты әгъзасы булды.

- Румыниядә яшәүче татарлар, 40 илдән 500 кунак җыеп, Корылтай-Сабантуй фестивале уздырды.

- Мәскәүнең «Зарядье» залында Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, композитор Рәшит Калимуллинның яңа программа концерты узды.

- Татарстан һөнәрчелек палатасы әгъзалары, Түбән Камада яшәүче Раил һәм Марат Әсләмовлар халык рәссамы Әхсән Фәтхетдинов музеена агачтан ясалган Бөек Болгар макетын бүләк итте.

- Уфада Булат Йосыповның халыктан акча җыеп төшерелгән, Башкортстанның халык шагыйре Рәми Гарипов тормышы һәм иҗатына багышланган «Шагыйрь көндәлеге» фильмы күрсәтелде.

- Арча район Мәдәният йортында Россиянең Халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы Фәрхәт Зыятовны искә алу кичәсе узды.

- «Алтын тәлинкә» төбәкара кинопремиясе кысаларында «Время кино» питчингына гаризалар кабул итела башлады.

- Татарстанда яшь буынга патриотик тәрбия бирү максатында, «Безнең тарих – безнең горурлык» проектының беренче өлеше буларак, яңа документаль фильм төшерелгән.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Зиннур ХӨСНИЯР, язучы, баш мөхәррир:

«Җитәкче булабыз икән яисә «исем калка» башлый икән, язучылар арасыннан, кинәт кенә нидер искә төшкәндәй, яшьләрне эзләргә керешәбез. Яшьләргә ярдәм кирәк, яшьләргә фәләнфәсмәтән дип, сүз саен, адым саен чаң кагабыз... Тик ул яшьләрнең берәрсе әдәбиятта бераз «күтәрелә» башласа, аны шундук «онытабыз», тагын, тыраша-тыраша, яңа «яшьләрне» эзли башлыйбыз... Ә теге яшьләргә сарыф ителгән энергия һәм вакыт әрәм булсынмыни?! Нишләп аларны «күрмибез» соң? Татарлык, дөресрәге, татарча хөсетлекнең бер чагылышы инде бу».

СЫНАМЫШЛАР

Покрауда (14 октябрь) җил көнчыгыштан булса, кышка суык китерер ● Покрауда кар күренсә, кырык көннән кар ятар ● Покрауга кадәр кар төшсә, көз озын булыр ● Покрау үтте – кыш җитте ● Кара көзнең кары ятмас.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 11 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 46 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 35 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **21 октябрьдә 10 сәгать 03 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

14 октябрь – язучы, шагыйрә Роза Галимулла кызы Хәмидуллинага 60 яшь (1962).

15 октябрь – Татарстанның дәүләт эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты, РФ Хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге премиясе лауреаты Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиевага 70 яшь (1952).

17 октябрь – шагыйрь Гали Хуҗи улы Хуҗиевнең тууына 110 ел (1912–1966);

– актриса, җәмәгать эшлеклесе. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Рәшидә Габдуллаҗан кызы Җиһаншинаның тууына 105 ел (1917-2003);

– җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, педагогика фәннәре кандидаты, профессор Лидия Алексей кызы Әхмәтовага 60 яшь (1962).

18 октябрь – актёр, Татарстанның халык артисты Әнвәр Габдрахман улы Гобәйдуллинның тууына 100 ел (1922–2012);

– драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Габдулла улы Сафиуллинга 75 яшь (1947).

20 октябрь – график, гамәли бизәү сәнгате рәссамы, Б.Урманче премиясе лауреаты Әлфия Ринат кызы Ильясовага 55 яшь (1967).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(17-25 октябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 18 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

БӨЕК ТАТАР ХАТЫНЫ

(«Зөләйха» трагедиясенең язылуына 110 ел)

Гаяз Исхакый иҗатында күренекле урын алып торган “Зөләйха” драмасы бер утырыда язылмаган. Әдип аны 1907 елда Чистай төрмәсенә ябылгач яза башлый. Татарларны урыс хөкүмәте һәм христиан чиркәвенең көчләп чукындыруы турында әле гыйльми тикшеренүләр булмый, ул гына да түгел, бу темага кагылу да тыела, ләкин халык хәтерендә әлеге каһәрле гамәл төзәлмәс яра сыман һәрвакыт сулкылдап торган. Заманында Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә дә бер өлеш халык чукындырыла. Әмма шунысын әйтергә кирәк: XVIII гасырның 30 елларында булдырылган “Яңа керәшен конторасы”ның эшчәнлеге нәтиҗәсендә Рәсәй татарлары арасында барлыкка килгән әлеге төркем хөкүмәт алдында православный христиан саналса да, чынлыкта күбесе яшерен рәвештә мөселман булып калган, мөмкинлек чыгу белән кире ислам диненә кайткан. Ә хәзерге татар керәшеннәренең күбесе – XVI-XVII гасырларда чукындырылган төрки һәм төркиләшкән фин-угыр халыклары арасыннан чыккан груһның токымнары. Гасырлар дәвамында калебләренә христиан дине ныклап сеңәргә өлгергән. Һәм сеңдергәннәр дә, әлбәттә. Ә “яңа керәшеннәр”гә килгәндә, 1905 елдагы Беренче урыс инкыйлабы нәтиҗәсендә патша манифесты вөҗдан иреге игълан иткәч, аларның барысы да диярлек христиан диненнән ваз кичә.

Татарларның чукындыру сәясәтенә каршылык күрсәтүен Исхакый милли-азатлык көрәше белән бәйләп карый, һәм ислам диненең халыкны туплап, үз асылын югалтмыйча саклап торуын бөтен дөньяга, иң мөһиме, татар халкының үзенә белдерергә омтыла. Аның өчен әдәбият – эстетик кыйммәткә ия булу белән бергә, иң әүвәл милли хокукларны яулау коралы. Үз халкын бүтәннәр белән тигез күрергә хыялланган язучы әдәби талантын сәяси максатларда да файдалана. “Кем син? Тор! Тик көрәштә генә табарсың үз бәхетеңне!” Ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, бу шигарьләр аның һәр әсәрендә кычкырып тора. Әлбәттә, үз халкын бергә тупларга теләгән, үз асылына кайтырга өндәгән Исхакый урыс хөкүмәте һәм чиркәве тарафыннан татарларны чукындыру сәясәтенә һич тә битараф кала алмаган. Сәяси яктан буйсындырылып та шушы сәясәткә гасырлар дәвамында каршы тора алган татарларның фидаи батырлыгы аны сокландырган. Мәсхәрә, җәфаларга бирешмичә үз асылына тугрылыклы калган төп каһарманның хатын-кыз булуы да шулай ук гыйбрәтле. Зөләйханың, билгеле, прототибы булган, ләкин язучы өчен әсәрдә төп максат: милләтнең яшәеше иң беренче нәүбәттә хатын-кызга бәйле, ул гына милли уакка утын өстәүче, ул гына туачак батырларны дөньяга китерәчәк, тәрбияләячәк Ана.

Бөек Татар Хатын-кызы!

Рәсәйнең иң төньягындагы Архангел сөргененнән качып килгәч, Исхакый әлеге әсәрен Истанбулда дәвам итә. Дәвам итү, дию бәлки дөрес тә түгелдер, ул аны яңадан эшли, каһарман хатынның исеме дә алышына. Ләкин бу юлы да язып тәмам итә алмый, Төркиядән Петербургка килгәч, 1912 елның гыйнварында гына, ниһаять, ул аңа соңгы ноктаны куя. Шул көннәрдә үк пьесаны генерал Шәех Гали өендә пайтәхетнең әдәбият белән кызыксынучы татар җәмәгатьчелегенә укый. Тагын бер мәҗлес Заһид Шамил (Дагстанлы шәех Шамилнең улы, ул Казан бае Аппаковның кызы Мәрьямгә өйләнә) өендә дә үтәргә тиеш була, әмма шул көнне Исхакый патша жандармнары тарафыннан яңадан кулга алына. Ярый, шуны сизгәндәй, ул “Зөләйха”ның кульязмасын Петербургта Югары Бестужев курсларында укучы Гөлсем туташ Камаловага (бу гаҗәеп шәхес турында Роза Туфитуллова роман да язды, ул Казанда гына түгел, Анкарада төрек телендә дә нәшер ителде) биреп куйган була. Шул рәвешле бөек драма югалмыйча исән кала...

Шул рәвешле, бу күренекле әсәрнең язылуына быел 110 ел...

“Зөләйха” 1917 елның Февраль инкыйлабыннан соң гына, патша цензурасы бетерелгәч сәхнәгә куела. Рәсәйнең бөтен төрки-татар дөньясына мәшһүр “Сәйяр” труппасы аны беренче тапкыр Казанның Рус Зур театры бинасында 1917 елның 17 мартында режиссер һәм актер, татар театрына нигез салучыларның берсе Габдулла Кариев бенефисы уңаеннан уйный. Спектакльгә музыканы танылган композитор Солтан Габәши яза. Тамашада халык шулкадәр күп була ки, басып торырга да урын таба алмыйлар. Һәм көн саен диярлек шул ук хәл! Бераздан спектакльне Мәскәүдә Бөтен Россия мөселманнарының 1 нче корылтае делегатларына уйныйлар. “Зөләйха”ның даны барлык империя киңлекләренә тарала. Мөгаен, Гаяз Исхакый канәгать калгандыр – төрки-татар дөньясында әдәби әсәрнең бу кадәр кодрәтле сәяси коралга әверелүе моңа кадәр булмаган. Кызганыч, моннан соң да булмады. Большевиклар тәхеттә ныгып алгач, “Зөләйха” гына түгел, Исхакыйның башка әсәрләре дә тыела. Дөрес, чит илләрдәге татар мөһаҗирләре әлеге трагедияне әледән-әле һәвәскәр сәхнәләрдә куеп тора. Аны Токиода, Харбинда, Тампереда уйнаулары билгеле.

Профессиональ татар сәхнәсенә исә “Зөләйха” беренче тапкыр уйналуыннан соң 75 ел үткәч кенә менә алды – 1992 елда Казанның Г.Камал исемендәге Академия театрында аны сәхнәгә режиссер Празат Исәнбәт куйды. Ике елдан соң аны Уфадагы “Нур” татар театры сәхнәләштерде (режиссеры Байрас Ибраһимов). 2004 елда Казанда “Зөләйха” нәфис фильмы төшерелде (сценарий авторы Юныс Сафиуллин, режиссеры Рамил Төхфәтуллин). Болар барысы да туксанынчы еллар башындагы реформалар, демократия чалымнары барлыкка килү белән бәйле иде. Татарның милли аңын уяту өчен “Зөләйха” яңадан сафка басты!

Соңгы елларда “Зөләйха” әсәренең яңадан сәхнәдә уйналуын күз алдына китерүе кыен. Патша вакытында яисә большевиклар хакимияте заманындагы кебек үк, Рәсәй тарихы рәсми дәүләт күзлегеннән карап кына мәктәпләрдә укытыла башлады. Билгеле, бу тарихта татарларны яисә башка урыс булмаган халыкларны көчләп чукындыру сәхифәләре юк. Урыс чиркәве дә кара гасырларда калган үз җинаятьләрен инкяр итә – кайда ул тәүбә иту! Янәсе Рәсәйдә беркайчан да башка халыкларны көчләп христианлаштыру булмаган, һәркем үзе теләгән динне тоткан. Әнә бит татарларның күбесе һәмишә мөселман! Шулай итеп татарлардагы мөселманлыкның кан һәм күз яшьләре, газап һәм искиткеч рух кодрәте, иман ныклыгы аркасында сакланып калганын яшерергә тырышалар. Әмма тарихта вакытлыча гына ялганлап була, тарихи дөреслек барыбер яңадан калкып чыга ул! “Зөләйха” да ак яулыгын бөркәнеп яңадан сәхнәгә күтәреләчәк әле. Чөнки ул татар халкының рухи ныклыгын гәүдәләндерүче образ, Сөембикәләр, Гөләйзалар, Мөхлисәләр белән бергә безнең мәңгелек пантеонда.

Халкыбызга рухи ныклык аеруча кирәк булган бүгенге заманда Зөләйханың гыйбрәтле язмышы турында без онытмаска тиеш.

МӘҖ
Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Уйландыра һәм рухландыра да торган көн

Иртәгә – татар халкының Хәтер көне. Милли җанлы милләттәшләребез бу көнне, кайда яшәвенә карамастан, 1552 елда Казанны яклап шәһит киткән ата-бабаларыбызны зур хөрмәт белән искә ала, алар рухына багышлап дога кыла. Иманы ныклы имамнарыбыз мәчет-мәдрәсәләрдә дә вәгазьләрен алар рухына багышлый, ә чын мөгаллимнәр мәктәп вә башка уку йортларында укучыларына тарихның ул фаҗигале чоры турында дөрес мәгълүмат бирү өчен дә вакытын таба. Чөнки үз тарихындагы кайгылы көнне дә хәтерендә саклый һәм билгеләп үтә алмый торган милләт үзен цивилизацияле дип тә саный алмый. Искә төшерик, хөрлек елларында Хәтер көне Татарстанда да, ата-бабаларыбыз рухын иңдерү вә зурлау чарасы буларак, халык тарафыннан күтәп алып һәм колачлырак итеп үткәрелә иде. Шуңа анда рухи һәм тәрбияви якка да зур урын бирелеп килде. Күрәсең, нәкъ әнә шулары куркытты да инде бәгъзеләрне: төрле юллар белән, алар халыкның әлеге хәтер яңарту мөмкинлеген дә тыю җаен тапты. Әмма татар халкы бүген инде бөтен кыйтгаларга таралып яши. Демократик илләрдә яшәүче милләттәшләребез бүген дә Хәтер көнен үзләре теләгәнчә билгеләп үтә, бу уңайдан төрле чаралар үткәрә, аның рухи вә тәрбияви асылын саклап килә.

Ә заманалар үзгәреп тора. Насыйп итсә, милләт тарихындагы фаҗигале көнне дә халык хәтереннән алай гына җуйдырып булмас. Киресенчә, мондый мөнәсәбәт аны тирәнтен уйланырга, бүгенге рухи төшенкелекнең эчке һәм тышкы сәбәпләрен дә ачыкларга мәҗбүр итә. Әлбәттә, ил-көндә бара торган бүгенге хәтәр хәлләр дә киләчәккә оптимизм өстәми. Чөнки, эчке вә тышкы сәясәт бүгенгечә дәвам иткәндә, алга таба инде илне тагы да зуррак тетрәнүләр көтәргә һәм эш хәтта ватандашлар сугышына кадәр дә барып җитәргә мөмкин. Ихтимал, яңа дөньяви тәртип (ЯДТ) урнаштыручылар өчен ул, бәлки, кулайдыр да. Әмма аңа кадәр илнең атом-төш коралын ныклы контрольгә алу лязем (әйтик, СССРны таркаткандагы кебек). Хәлбуки, ЯДТ урнаштыручыларның глобаль планда эш итүләрен дә онытмыйк. Зурдан алганда, чыннан да, ошбу геосәяси уеннарда Көнбатыш һәм Россия уртак максатларда, әмма капма-каршы яктан эш итә. Күренә ки, соңгысына аның иң авыр һәм канкойгыч өлеше туры килә: төп халык анда кабаттан да «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» итеп кулланыла. Алай гына түгел, геосәяси тетрәнүләрнең әлеге кайнар фазасына тәүге адымны да ул ясады. Шуңа күрә, һич икеләнмичә әйтергә була, мондый тетрәнүләр әле ЯДТ урнаштырганчыга кадәр дәвам итәчәк һәм аның бөтен авырлыгы алга таба да гади халык җилкәсенә төшәчәк.

Үзеннән-үзе сорау туа: ил күләмендә генә түгел, глобаль планда да зур проблемалар тудыра торган бүгенге кискен шартларда татар халкы нәрсә эшләргә тиеш соң? Әлбәттә, ул үзе генә ничектер изоляцияләнеп, ил-көндә бара торган процесслардан читтә кала алмый. Әмма, узган гасырлардагы кебек, читләр уенында үзен корбан итүләр дә аның юлы түгел. Чөнки милләтне ул чираттагы фаҗигагә генә китерергә мөмкин. Димәк, татар үз киләчәген ышанычлы итәрдәй һәм чор таләпләренә дә туры килә торган хакыйкый юлны табарга тиеш була. Ә аның өчен ул бердәнбер – Күкләр тарафыннан йөкләнгән илаһи миссия. Тик, ни кызганыч, «паровоз»дан алга чыгып чабучылар анда әле бүген дә җитәрлек. Ә мондый хәл инде дөньяда бара торган геосәяси процессларның асылын аңламаудан килә. Хәлбуки, метасәяси вазгыять тә хәзер бөтенләй башка. Шуңа күрә, илаһи миссияле милләт буларак, татарның бүген читләр уенында «сәясәт коралы»на әверелергә хакы юк. Хәтер көне уңаеннан уйланулар әнә шундый, аңык һәм икеләнүләргә урын калдырмый торган нәтиҗәләргә дә китерә.

Ә инде бүгенге кискен шартларга килгәндә, татарның Хак Тәгалә тарафыннан тәгаенләнгән бурычы анда да анык: Урталык җирләрендә тотрыклылык һәм илаһи борылыш факторы булу. Ә андый бурычны ул метасәяси дәрәҗәдә үзоешканда гына башкарып чыга алачак. Үзоешуның ошбу югары формасы турында тәфсилле сүз узган язмаларыбызның берсендә («МҖ» №31, 12.08.2022) инде булган иде. Шунысын да искәртеп үтик, татарда моның өчен әзерлек дәрәҗәсе бүген җитәрлек. Ә эшнең уңышы инде һәр кешенең үзеннән, аның милләт миссиясенә нинди өлеш кертә алуыннан торачак. Таләпләрнең катгыйлыгы исә алда торган бурычларның зурлыгы вә мөһимлеге белән аклана. Күрүебезчә, Хәтер көне милләтпәрвәрләрне уйландырып кына калмый, ә зур вә изге эшләргә дә рухландыра.

Фоат УРАЗАЙ.

Каһарманга – мәһабәт һәйкәл

Башкортстан Республикасы көнендә, Уфаның Совет мәйданында легендар комдив, Россия Герое Миңнегали Шәйморатовка һәйкәл ачылды.

Башкортстан башлыгы Радий Хәбиров ачылу тантанасында моның республика өчен истәлекле вакыйга, Ватанны саклаучы якташлар батырлыгына хөрмәт күрсәтү көне дип атады.

Тантанада шулай ук Донецк Халык Республикасы башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы Денис Пушилин, Россия Федерациясе Президенты ярдәмчесе Владимир Мединский, Россия Федерациясе Саклану министрлыгының генераль инспекторы Валерий Баранов, Россия Сәнгать академиясе академигы, архитектор Салават Щербаков чыгыш ясады.

– Миңнегали Шәйморатовка һәйкәл ачу – тарихи гаделлек билгесе. Һичшиксез, әлеге чара Россия Федерациясе төбәкләрен, бу очракта Донбасс белән Башкортстанны берләштерә. Төбәкләрнең тарихы да уртак: генерал Шәйморатов Донбассны азат итеп һәлак була, – диде Д.Пушилин.

Һәйкәл Россиянең халык рәссамы Салават Щербаков белән Башкортстанның атказанган архитекторы Константин Донгузовның уртак проекты буенча төзелгән монументаль ансамбльнең үзәге булып тора. Ике яктан, постаментны колачлаган колонна дошман алдында халыкның берләшүен символлаштыра.

Театрлар дөньясында

Камал театрының Данияр Соколов җитәкчелегендәге оркестры концертлар сериясе үткәрә. Аларның беренчесе 9 октябрьдә тәкъдим ителде. Программага Фәрит Яруллин, Мансур Мозаффаров һ.б. татар һәм чит ил композиторларының әсәрләре кергән.

Чирмешән районы Лашман авылы мәдәният йортына Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, күп еллар К. Тинчурин театрында чыгыш ясаган Наил Шәйхетдинов (1941-2016) исеме бирелде.

«Әкият» курчак театры бу көннәрдә Чаллы театры сәхнәсендә чыгыш ясый. Монда «Маугли» һәм «Страна чудес Алисы» спектакльләре күрсәтелә.

Әлмәт татар дәүләт драма театрында сезон ачылу алдыннан уздырылган матбугат конференциясе кысаларында режиссер Наилә Нәҗипованың иҗат эше – Әлмәт театры труппасының яшь составы катнашындагы «Далада» спектакле тәкъдим ителде.

Театр директоры Фәридә Исмәгыйлова яңа проектлар һәм юнәлешләрнең «Т» хәрефе астында алып барылачагын хәбәр итте. Әлеге символ ныклы, ышанычлы, кагылгысыз, ныгытылган, кыю, какшамас, чигенүсез дигәнне аңлата.

Минзәләдә театраль сезонны ачу ике өлештән тора. Быел да театр бу традицияне саклады. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» спектакле премьерасыннан соң, икенче – тантаналы өлештә узган сезонга йомгак ясалып, артистлар, театр хезмәткәрләре, актив тамашачылар һәм театр дуслары бүләкләнде. Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте тәмамлап килгән яшь артист Рөстәм Авзалов тантаналы төстә театр коллективына кабул ителде.

Башкортстанның Стәрлетамак дәүләт театр-концерт берләшмәсенең драма театрына башкорт театр эшлеклесе Илшат Юмагулов исемен бирү тантанасы булды. Берләшмәгә нигез салучы Илшат Юмагулов хөрмәтенә аның сыны куелды.

Уфа Яшь тамашачы театры 15 октябрьдә яңа сезонын «Бәби» музыкаль спектакле белән ача. Пьеса авторы – драматург Илгиз Зәйниев. Пьесаны рус теленә Нияз Игъламов тәрҗемә иткән.

Уфадагы Республика халык иҗаты үзәгенең Мәдәният йортында «Акмулла» спектакле премьерасы булды. Сценарийның авторы – «Табын» башкорт халык иҗаты коллективы режиссеры, Мостай Кәрим исемендәге Милли яшьләр театры актеры Илнур Локманов.

«Яңа татар пьесасы – 2022» конкурсына барлыгы 61 пьеса килгән. Бәйгедә җиңгән авторларның исемнәре 2022 елның 22 декабрендә игълан ителәчәк.

Бәйгенең шартлары катгый

Татарстан Президенты каршындагы туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Казан утлары» журналы белән берлектә 2022 елның 1 октябреннән татар телендәге әдәби әсәрләр бәйгесен игълан итте. Шул уңайдан «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат очрашуы да үтте.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла ябык әдәби конкурска кертелгән үзгәрешләр турында аңлатты. «Быелгы конкурска әдәби тәнкыйть мәкаләсе һәм рецензия номинациясе кертелде. Моны әдәбият галиме Дания Заһидуллина тәкъдим итте. Бу бик урынлы тәкъдим. Чөнки әдәби тәнкыйть өлкәсе аксый дип гел зарланабыз», – диде берлек рәисе. Профессор Дания Заһидуллина бәйгегә нинди әсәрләр җибәрү отышлы икәненә тукталды. «Җюри әгъзалары әсәрне укыганда, берничә критерийга игътибар итә. Беренчедән, аның укылышлылыгы мөһим, ул укылмый икән, нинди генә темага һәм проблемага багышланса да, укучыга кызык түгел. Икенче критерий – аның заманчалыгы. Өченчесе – әсәрнең дөнья әдәбиятында барган процесслар белән авазлашлыгы», – диде ул.

Конкурста катнашу өчен моңа кадәр басылмаган әсәрләр генә кабул ителә. Бер автордан килгән әсәрләр саны чикләнми. Ләкин бер номинациядә бары тик бер псевдоним белән генә катнашу мәҗбүри.

Конкурска җибәрелгән әсәрләр техник таләпләргә җавап бирергә тиеш дип ассызыклады оештыручылар. Компьютерда басылган биттә 1800 билге, 30 юл, юлда якынча 60 билге булуы шарт.

Романнар 2023 елның 1 декабренә, башка номинацияләрдәге әсәрләр 2023 елның 1 сентябренә кадәр кабул ителә.

1 нче биттә – кыргый балан уңышы. И.Зәкиев фотосы.

Китапханәгә зур бүләк

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев шәхси китапханәсеннән 4000 китапны Милли китапханә фондына тапшыру турында килешүне имзалады.

Республиканың беренче Президенты әүвәл Милли китапханәгә үзе тапшырган китаплары куелган күргәзмә белән танышты. Ул култамгалы китапларга карап Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов белән аралашуын искә төшерде. Күренекле актрисалар Нәҗибә Ихсанова, Наилә Гәрәевага багышланган китапларга күз салып әлеге артистлар турында җылы сүзләрен әйтте.

Республиканың беренче Президенты Милли китапханәгә «Бизнес, хакимият һәм җәмгыятьнең китап ядкәрләренең сакланышын тәэмин итү өчен фонд саклаучылар белән хезмәттәшлеге» халыкара конференциясенә чакырылган иде.

М.Шәймиев үз чыгышында Болгарны һәм Свияжскны төзекләндерү, Татарстан объектларының ЮНЕСКО исемлегенә керүе турында искәртеп узды. «Бу ике шәһәр 1 миллион 600 мең турист бирә», – диде ул.

Сүз уңаеннан «Яңарыш» фонды эшчәнлеге белән таныштырды, ачык һавада куелган «Кара пулат» спектаклен искә төшерде.

Милли китапханә директоры Мәдинә Тимерҗанова Минтимер Шәймиевкә рәхмәтләрен җиткереп бу китапларның укучылар өчен һәрвакыт ачык булачагын ассызыклады.

«Минтимер Шәймиевнең шәхси китапханәсеннән 4 меңгә якын китапны кабул итеп алдык. Әлеге фонд өйрәнелә генә башлады. Кабул ителгән китаплар арасында татар әдәбияты да, фотоальбомнар да, сәясәт эшлеклеләре тарафыннан бүләк ителгәннәре дә бар, – дип әлеге фонд белән таныштырды Милли китапханәнең директор урынбасары Тәбрис Яруллин. – Китаплар арасында Минтимер Шәрип улының үзенә кызык булганнарын күрәбез. Китапның укылганлыгы күренә. Укылган китаплар аша шәхесне өйрәнеп була, димәк, әлеге китаплар аша беренче президентыбыз турында да яңа мәгълүмат алырга мөмкин», – диде ул.

Тәбрис Яруллин «сәяси яктан бик кызыклы булган туксанынчы елларга караган китапларга» игътибарны юнәлтте. Әлеге култамгалы китаплар аша беренче президентның кемнәр белән күрешүен дә күреп булуын искәртте. Аның хоббие булган атлар, шахматлар темасына китапларны күрсәтте.

Кабул ителгән китаплар арасында Милли китапханә фондында моңарчы булмаган китаплар да шактый. Әйтик, Шәймиевнең шәхси китапханәсендә Габдулла Тукайның алтай телендә 2021 елда чыккан шигырьләр китабы, балкар телендә «Идегәй» дастаны бар.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

● Һиндстанның Көнбатыш Бенгалия штатында яшәүче Руни Хатунның ашказаныннан, операция ясап, барлыгы 1,6 килограмм бизәнү әйбере – 69 нечкә чылбыр, 80 алка, 46 көмеш тәңкә, 8 медальон, борынга кия торган 11 бөҗра, 5 беләзек һәм кул сәгате алганнар. "Хәзинә" якынча 53 мең фунт стерлингка (4,2 миллион сум чамасы) бәяләнә. Аларның барысын да йоткан 22 яшьлек кызны психиатрга дәваланырга җибәргәннәр.

● Дөньяда өлкән яшьтәге 854 миллионга якын кеше укый-яза белми.

● Көньяк Кореядә телгән һәр бай кеше 100 мең долларга этенең клонын ясата ала.

● Фил тиресенең калынлыгы кайбер урыннарда 2,5 сантиметрга җитәргә мөмкин, аның 20-30 килограммлы йөрәге исә минутына 30 тапкыр тибә.

● 1975 елда һинд шагыйре Шри Чимной бер көндә 843 шигырь язган.

Кояшка тиң Фирая

Г.Камал театрында Татарстанның халык артисты Фирая Әкбәрованы матур гомер бәйрәме белән тәбрик иттеләр.

Ф.Әкбәрова татар тамашачысы күңеленә «Ташкыннар», «Гөргөри кияүләре», «Өйләнәм.tat» һ.б. спектакльләрдәге рольләре белән керде. Телевизион фильмнарга иң күп төшкән артисткабыз да ул. «Габбас хәзрәт», «Зәңгәр кыңгыраулар», «Көтелмәгән кунак», «Рәхәт яшибез», «Бер-бер хәл», «Семейные хлопоты», «Кире» һ.б. телефильмнарда һәм сериалларда Ф.Әкбәрова халыкчанлыгы белән йөрәкләрне җылыта торган образлар иҗат итте. Театрларыбызда әллә нинди чибәр артисткаларыбыз бар. Әмма экран бөтен сәхнә осталарын да, Әкбәрованы кебек, яратмый. Фирая ханымның ихласлыгы, үзебезчә гади булуы, халкыбызның иң күркәм сыйфатларын күңеленә сеңдерүе, ачык, көр күңеле аңа театрда да, кино сәнгатендә дә бердәй уңышларга ирешергә мөмкинлек бирә.

Артистка Ф.Әкбәрованың бер канаты театр булса, икенче канаты – җыр. Драма артистлары башкарган җырлар нигәдер аеруча күңелгә үтә. Фирая ханым шундый үтемле итеп, моңлы җырлый белүче актрисаларыбызның берсе. Камал театрында озак еллар оркестр җитәкчесе, дирижер булып эшләгән Фоат Әбүбәкеров аның өчен бик матур җырлар язды, бергәләп лазер тәлинкәләр яздырып чыгардылар.

Иҗат кичәсендә актрисаны президентыбыз Рөстәм Миңнеханов исеменнән Татарстан мәдәният министры урынбасары Линар Хәкимҗанов тәбрик итеп, «Фидакяр хезмәт өчен» медале тапшырды. Туган ягы Югары Ослан районы (Ф.Әкбәрова – Салих Сәйдәшевнең туган авылы Кызыл Байрактан) – башкарма комитеты җитәкчесе Илнур Шакиров, Уфа «Нур» театрыннан талантлы артистка Резидә Фәхруллина, М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт театрыннан күренекле артистлар Илсөяр Газетдинова һәм Илдар Гомәров, сәнгать осталары юбилярга иң изге теләкләрен җиткерде.

Нужа күргәннәр генә тормышның кадерен, яшәүнең ямен белә, диләр. Үз башыннан кичергәннәрнең һәр сүзе, һәр авазы моң булып ишетелә. Фирая Әкбәрованың моңланыр чаклары күп булганга, бүген ачык йөрәкле, «җылы» бу артистның рольләренә сокланып яшибез. Әтисе белән әнисе аерылышканда, аңа нибары ике ай була. Кире төп йортка кайткач, анда сыймаганга күрә, әнисенең нарасыен иренә калдырып китүдән башка чарасы калмый. Фирая биш яшенә җиткәнче, әтисе биш тапкыр өйләнеп өлгерә. Нәни кызчыкка биш үги әнине алмаштырырга туры килә дигән сүз. Ниһаять, әнисе белән Казанга күчеп килгәч кенә, кызчык елмаерга өйрәнә...

Туган җиренең моңын үзендә туплаган һәм, болытлар артыннан балкып чыккан кояш кебек, тормыш ачысын узып елмаерга өйрәнгән Фирая Әкбәрова бүген дә татар тамашачысын шатландыра.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Комитет бюджетны тикшерде

Дәүләт Советында Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында 2023 елга һәм 2024, һәм 2025 елларның планлы чорына республика бюджеты турында закон проекты каралды. Утырыш эшендә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Дәүләт Советы секретаре Лилия Маврина катнашты. Утырышны профиль комитеты рәисе урынбасары Людмила Рыбакова үткәрде.

2023 елда «Мәгариф» бүлегә буенча чыгымнарның берләштерелгән күләме 128,6 млрд сум дәрәҗәсендә планлаштырылган, шул исәптән республика бюджеты хисабына – 78,4 млрд сум. Акчалар республиканың мәгариф учреждениеләрен финанслауга, башлангыч сыйныф укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүгә, матди-техник базаны яңартуга, педагогик хезмәткәрләргә, яшь белгечләргә грант ярдәмәнә һәм башка юнәлешләргә юнәлдереләчәк.

Мәдәният һәм кинематографияне финанслауга 2023 елда берләштерелгән бюджет буенча – 17,3 млрд сум, республика бюджетында – 10,1 млрд сум каралган. Акчаларны грантлар бирүгә, китап фондларын туплауга, иҗади берлекләргә ярдәм итүгә, музейларны, театрларны, циркны, китапханәләрне, иҗат коллективларын тотуга юнәлдерү планлаштырыла. «Массакүләм мәгълүмат чаралары» бүлегә буенча бюджет чыгымнары 2023 елга 1,7 млрд сум күләмендә планлаштырылган.

Докладларны тыңлап, комитет әгъзалары сорауларга күчтеләр. Депутат Рамил Төхвәтуллин бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы индексацияләнәчәкме, дип сорады. Икътисад министрының беренче урынбасары Олег Пелевин хәбәр иткәнчә, 2023 елның 1 гыйнварыннан 10% дәрәҗәсендә арттыру планлаштырыла.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина яңа балалар бакчалары һәм мәктәпләр төзелешенә бюджетта акча каралганмы, дип кызыксынды. «Киләсе елда федераль программа буенча республикада өч гомуми белем бирү мәктәбе төзү планлаштырыла, – диде мәгариф министры урынбасары Рамил Хәйруллин. – Казанда Р.Гәрәев урамында мәктәп ачарга ниятлибез, тагын берсе Яр Чаллыда һәм Арчада». Лилия Маврина шулай ук профильле министрлыкларга, балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә булачак ихтыяҗны исәпкә алу өчен, торак комплексларын төзүчеләр белән якынрак эш алып барырга тәкъдим итте.

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов фикер алышулар вакытында туган телдә укучы балалар санының дәреслеккә туры килүенә шиген белдерде. «Районнарга йөрү цифрларның дәреслеккә туры килмәвен, аларның кәгазьдә генә булуын күрсәтә», – диде депутат. Депутат туган телдә белем бирүче оешмаларны даими тикшереп тору мәсьәләсен комитетның 2023 елгы эш планына кертүне сорады. Аңа каршы килүчеләр булмады.

Мөгаллим мирасы

Быел галим һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче Нургали Сибгатулла улы Надиевнең тууына 140 ел тулды. Шушы уңайдан Шәриф Камалның мемориаль фатиры – татар әдәбияты тарихы музее бинасына эленгән мемориаль такта янына чәчәкләр куелды, галимнәр, педагогның туганнары, якташлары катнашында Нургали Надиевнең тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган күргәзмә ачылды һәм Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре тарафыннан оештырылган түгәрәк өстәл утырышы узды.

● Нургали Надиев.

● Истәлек тактасы янында Нургали Надиевнең оныгы Альмира Йосыпова.

Н.Надиев Казандагы татар-рус мәктәбендә һәм Оренбургтагы Хөсәения мәдрәсәсендә укыучы, соңрак Оренбургтагы татар педагогика институтының беренче директоры һәм Казан педагогика институты доценты буларак мәгълүм шәхес. Педагог Оренбургта Фатыйх Кәрими һәм Шәриф Камал белән бергә аралашып яшәгән. Ул – шулай ук Россия тарихы буенча татар телендә беренче дәреслекләр авторы. Аның хезмәтләре педагогика, мәктәптә математика укыту методикасына карый.

Педагог, галим Нургали Надиевне Шәриф Камал музеенда искә алу очраклы түгел. Ул 1925-1940 елларда шушы бинаның беренче катындагы фатирда яши, бернчә бүлмә Надиевләрнеке була, биредә аларның балалары, оныклары үскән. Педагог янына Салих Сәйдәшев, Һади Такташ, Муса Җәлил һ.б. күренекле шәхесләр килеп йөргән. Нургали Надиев Казанда да Шәриф Камал белән күрешеп торган. Гомумән, беренче каттагы фатирда бик күп истәлекле очрашулар булуы мәгълүм.

Н.Надиевнең биредә яшәве турындагы истәлек тактасы бинага 1983 елда куелган булган. Әмма ул, йортны сипләү эшләре алып барылган вакытта, реставрацияләү өчен алынган һәм аны биш елдан соң гына кабат элү мөмкин булган. Милли музей истәлек тактасын реставрацияләүне үз хисабына башкарып чыккан. «Нургали Надиевнең биредә яшәве музейның әһәмиятен тагын да арттыра. Аның Шәриф Камал белән дуслыгы әле өйрәнелмәгән тема булып тора. Безгә бу исемнең кайтуы кадерле», – диде Ш.Камал мемориаль фатиры – татар әдәбияты тарихы музее директоры Айдар Шәйхин. Музейчылар, истәлек тактасының яңартылуы зур эзләнү эшләре башланып китүенә дә сәбәп булыр, дип ышандыралар.

Истәлек тактасына чәчәкләр кую тантанасында Н.Надиевнең туганнары исеменнән аның оныгы Альмира Йосыпова сәламләде. Ул дәү әтисенең гомерен фәнгә, халкына багышлавын искә төшереп, аның талантлы педагог булуын, татар мәдәниятен, телен үстерү өчен тырышуын ассызыклады. Бүген инде дәү әтиләренең мөгаллимлек эшчәнлеген балалары, оныклары дәвам итә, алар барысы да педагоглар.

Чираттагы тантана – «Нургали Надиев: Гыйлем җәүһәрләре» күргәзмәсен ачу иде. Аның экспонатлары гаилә архивы, Казан дәүләт университеты китапханәсе, Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университеты фондларыннан тупланган экспонатлар – кулъязмалар, фоторәсемнәр, китаплар Н.Надиевнең фәнни педагогик эшчәнлеген һәм көндәлек тормышын күзалларга булыша. «Гарәп язуындагы күп кенә истәлекләрне кириллица хәрефләренә күчерергә, укырга кирәк. Безнең зур эшләр башланып кына китә», – диде А.Шәйхин. Музейчылар шушы көннәрдә педагогның хәзерге Милли музейда эшләп алуын да ачыклаганнар.

Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры урынбасары Марат Гыйбатдинов галимнәрнең, архив ишекләре ачылып, тарихыбызны язу өчен мөмкинлекләр булдырылгач, революциягә кадәр – 1920 елларда басылган тарих дәреслекләренә, аларны язу тәҗрибәсенә таянып, эшне дәвам итә алуларын әйтте.

Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты Ләлә Мортазина утырышта Н.Надиевнең эшчәнлеген шактый киң яктыртты, аның аеруча тәрбия мәсьәләләренә багышланган фикерләре әһәмиятле булуын әйтте. Галимә искәрткәнчә, Нургали Сибгатулла улы татар мәгарифен югла салу, аны оештыруга зур өлеш керткән, татар телендәге совет мәктәбен оештыру, аның нигезен коручыларының берсе булган шәхес. Педагогның күпчелек хезмәтләрендә бүгенге заман өчен дә әһәмиятле һәм актуаль мәсьәләләр күтәрелгән. Н.Надиев балаларны тәрбия кылу мәсьәләсенә дә игътибарлы булган, хезмәтләрендә баланы мәктәптә һәм гаиләдә ничек тәрбияләргә кирәк, дигән сорауга җавап табарга тырышкан. Галим татар мәктәбендә укучы татар балаларына өй эшен бирү методикасын эшләгән. «Аның кайберләрен бүген дә татар балаларына белем һәм тәрбия бирүдә куллану мөмкинлеге бар дип уйлыйм», – диде Л.Мортазина. Педагогның 1908 елда нәшер ителгән татар телендәге «Россия тарихы» дәреслеге 1915 елга кадәр биш тапкыр кабаттан нәшер ителгән. Аның татар телендә «Педагогика курсы» китабы да басылып чыккан. Аеруча хәзерге заман өчен әһәмиятле темалар күтәрелгән хезмәтләрен бүгенге татар балаларына белем һәм тәрбия бирүдә куллану мөмкинлеге бар.

Нургали Надиев моннан тыш арифметика укыту методикасын үстерүгә әһәмиятле өлеш керткән, аның татар балаларына арифметиканы укыту турындагы хезмәтләре, мәкаләләре басылып дөнья күргән. «Надиев, беренче чиратта, математика укыту буенча көчле методист булса, ул дәреслекләр төзү, методика фәненең торышы һәм аның проблемаларына һәрвакыт үз фикерен белдерә торган булган», – диде Ләлә Мортазина. Галимә дә Н.Надиевнең күп гыйльми хезмәтләре гарәп имлясында язылуын, шуңа күрә аларны уку өчен гарәп язуын өйрәнгән белгечләр кирәклеген дә искәртте.

Нургали Надиев халкыбыз хәтерендә Шәриф Камал белән бергәләп 13 яшьлек Муса Җәлилне, урам тормышыннан аралап, хәрби-сәяси мәктәпкә урнаштырулары уңаеннан да кереп калган. Нургали абый Оренбургтан Казанга күченгәч, үз янына Җәлилне дә чакырган.

Тарих фәннәре кандидаты, Саратов өлкәсе Диния нәзарәтенең Шәех Сәед мәдрәсәсе директоры урынбасары Али хәзрәт Хәбибуллин түгәрәк өстәл утырышында ясаган чыгышында Н.Надиевнең Саратов губернасының Селәү авылында тууын, булачак галимнең соңрак, белемнәрен арттыру өчен, Казанга килүен сөйләде. 1913 елда Селәүдә биш мәктәп булган. Аның 60 бала укытыла торганында – Әхмәтфәрит Надиев, 70 балага белем бирелә торган мәхәлләнекендә Сибгатулла хәзрәт Надиев мөгаллимлек иткән. Нургали Надиев та, ата-бабаларының эшен дәвам итеп, белем ала һәм 1917 елның апрелендә икенче җәмигъ мәчете имам-хатибы итеп билгеләнә. 1930-1931 елларда мәчетләр ябыла, имамнар сөргенгә озатыла. Алар арасында Нургалинең туганнан туган энесе Әхмәтфәрит хәзрәт тә була. Былтыр Селәү авылы тарихы турында китап та әзерләп нәшер ителгән. Аның Селәү авылының мәчетләренә, мәхәлләләренә багышланган бүлегендә Надиевләр турында да киң мәгълүмат бирелгән. Али хәзрәт Хәбибуллин утырышта катнашучыларны нәсел шәҗәрәсе белән дә таныштырып үтте.

Тарихчы галимә Тәэминә Биктимерова татар халкының Н.Надиев кебек күренекле педагоглары күплеген, алар өйрәнү, эшчәнлекләрен халыкка җиткерү кирәклеген кабат-кабат әйтте, Н.Надиев шәхесен җентекләбрәк ачыклауда исә Оренбург тарихчыларының да ярдәм итә алачагын искәртте. Марат Гыйбатдинов та татар халкының галимнәре, күренекле шәхесләре күп булуын, галимнәрнең генә аларны өйрәнеп бетерә алмавын, бу эшне бергәләп алып барырга тиешлегебезне белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.



● «Россия тарихы» китабы.

Лев Гумилев – татарлар өчен кадерле

Октябрь аенда татар халкын яклаган, 90 нчы елларда татарның үзаңы үсүенә зур йогынты ясаган күренекле галим, язучы Лев Гумилевның тууына 110 ел тулды. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары Марат Гыйбатдинов белән галимнең татарлар өчен тарихи роле турында сөйләштек.

– Лев Гумилев татарлар өчен ник әһәмиятле?

– Лев Гумилев татарларның гына түгел, гомумән, төрки халыкларның борынгы тарихын тирәнтен өйрәнгән, ә татар тарихының борынгы өлеше һуннар, төрки һәм хәзәр каһанлыклары, Алтын Урда белән бәйле.

Галим төрки халыкларның тарихын бөек империяләрнең өлеше итеп кенә түгел, ә мөстәкыйль дәүләт буларак, үзенең бөек вакыйгалары, шәхесләре, төрле нечкәлекләре белән караган. Л.Гумилевның безнең өчен иң зур әһәмияте шунда булган.

Төрки халыклар тарихына башка дәүләтләр күзлегеннән генә карыйбыз икән, ул әлеге дә баягы сугышлар, яулар тарихы булып кала, ә чынбарлыкта, борынгы тормыш сугышлар белән генә чикләнмәгән. Һәр халыкның үз сәясәте, икътисады, мәдәнияте булган.

Аның тагын бер әһәмиятен билгеләп үтәсем килә. Л.Гумилев җәмәгатьчелекнең Алтын Урдага карата тискәре карашын үзгәртүгә зур этәргеч биргән. Хәзер инде ул позиция рәсми кабул ителгән. Хәзерге тарихи-мәдәни стандартта «татаро-монгольское иго» дигән сүз юк. Хәзер ул «Рус кенәзлекләренең Алтын Урда ханнарына бәйлелек чоры» дип атала. Менә бу карашны алга сөрүдә Гумилевның әһәмияте зур.

Алтын Урда белән рус кенәзлекләренең бәйләнеше бары тик яулап алу һәм салым түләү белән генә чикләнмәгән. Анда үзара мөнәсәбәтләр бик тыгыз булган. Аның теориясе буенча, рус кенәзлекләре белән «дала» арасында, табигатьтәге кебек, симбиоз булган. Бөтен галимнәр дә Гумилев белән килешми, ләкин аның хезмәтләре җәмгыятьтә Алтын Урдага карашны үзгәртүгә бик зур йогынты ясады.

Тагын бер әйберне әйтергә кирәк. Ул төрки халыкларның, шул исәптән, татар тарихын популярлаштырды, чөнки ул, тарихи хезмәтләр язу белән бергә, сөйләү осталыгына да ия иде. Бәлки, бу осталык аңа атасы Николай Гумилевтан һәм анасы Анна Ахматовадан күчкәндер. Аның лекцияләре Интернетта бар. Кызыксынсагыз, карый аласыз.

Аның телевизион лекцияләрен тыңларга күпләр телевизор каршына җыела иде. Аны тыңласаң, артыннан иярергә мөмкинсең. Харизмасы булган кеше теле белән башкаларны да кызыктыра ала. Лев Гумилев халык арасында чын мәгънәсендә йолдызга әверелде. Аның фәнни хезмәтләре дә, бай әчтәлекле булуы белән беррәттән, мажаралы һәм укучыга бик кызыклы.

90 нчы елларда бик күп тарихи фактлар ачылды, цензурасыз сөйләү мөмкинлеге туды, бөтен кеше диярлек тарих белән кызыксына башлады. Бигрәк тә татарларның, төрки халыкларның кызыксынуы сизелерлек артты. Аның йогынтысы белән күп кешеләр тарих белән кызыксына башлады.

Лев Гумилев татарларның күтәрелешенә зур йогынты ясады. Тарихны аңлау аркылы милләтнең үзаңы үсте. Татар милләтен татар кешесе «чөю» – бер әйбер, ә бу мәсьәләләрне башка милләт галименең профессиональ дәрәҗәдә күтәрүе бөтенләй икенче төрле тәэсир итә.

– Без Лев Гумилевны рус галиме буларак таныйбызмы?

– Әлбәттә. Анна Ахматовада татар тамырлары булса да, алар бик тирәндә. Николай Гумилев – чын рус кешесе. Алар икесе дә – рус мохитендә яшәгән, рус мәдәниятенең йөзек кашлары булган шәхесләр. Лев Гумилев та рус мәдәниятендә тәрбияләнгән, әмма аның дөньяга карашы империячел караштан ерак. Ул Россиядә яшәгән халыкларга өстән түгел, ә тигез итеп караган. Бу – бик мөһим. Кече халыкларга империячел караш Россиядә генә түгел, башка илләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән, Европаның күпчелек галимнәре башка континентларда яши торган халыкларга кимсетеп, «артта калганнар» дип карый.

– Гумилевның татарлар турында әйткән сүзләре бармы?

– Аның мин өйрәнгән хезмәтләре борынгы чорларга кагыла, шуңа күрә бөтен цитаталары белән таныш түгел. Аның иң билгеле: «Мин рус кешесе булсам да, гомерем буе татарларны ялалардан якладым», – дигән сүзләре Петербург урамы башында куелган һәйкәлдә язылган. Бу сүзләр, чыннан да, аның тормыш позициясен чагылдыра.

Совет чорында Алтын Урданы өйрәнү тыелган иде. Ул замандагы ТАССР тарихы дәреслекләрен ачып карасагыз, татарның 300 еллык тарихы төшеп калган. «Казан ханлыгы Идел буе Болгарыннан барлыкка килгән» дип аңлатканнар, юкса Казан ханлыгы – Алтын Урданың турыдан-туры дәвамчысы. Болгар җирләре ханлыкка кергән, әмма Алтын Урданы тарихтан сызу – дөрес түгел. Гумилев менә шуның белән гомере буе көрәшкән.

– Рус мохитендә үскән галимне татарларны яклауга нәрсә этәрде икән?

– Ул нахакка кыерсытылган халыкларны якларга тырышкан, чөнки җәберләүләрне үз җилкәсендә дә күп күргән. Бер сәбәпсезгә ул берничә тапкыр кулга алынган, төрмәдә утырган. Минемчә, татарларны яклауда шушы фактор әзме-күпме сәбәпче булгандыр.

Л.Гумилев төрки дөнья белән бик яшьли кызыксына башлый. Рим, Кытай, Фарсы, Рус империяләре арасындагы территория ныгытып өйрәнелмәгән булуы галимне кызыксындыра. Әлеге җирләр буш ятмаган, анда да кешеләр яшәгән бит. Бу турыда ул бер китабының кереш өлешендә язган.

Гумилев «күчмә тормыш – ул бер урыннан икенче урынга хаотик рәвештә күченеп йөрү түгел», дип исбатлаган. Күчмә тормыш нигезендә табигатькә сакчыл караш ята. Бу позиция хәзерге экологик карашларга бик якын килә. Төрки күчмә халыклар табигатьне кешегә яраклаштырырга түгел, ә үзләре табигатькә яраклашырга тырышкан. Шуңа күрә бөтен күченүләр табигый цикллар белән бәйле.

Гумилев, төп белеме буенча тарихчы булса да, башка фәннәргә дә тирәнтен кергән. Мәсәлән, география буенча диссертация язган, экологияне яхшы өйрәнгән, фәлсәфә белән кызыксынган. Төрле өлкәдәге белемнәре аңа тарихны киңрәк яссылыкта өйрәнергә мөмкинлек биргән. Мисал өчен, ул борынгы кавемнәрнең үсешенә табигать үзгәреше нинди йогынты ясавын тикшергән. Тарихны башка фәннәр белән бәйләп өйрәнү – бүгенге фәндә бик киң кулланыла торган алым.

– Гумилев милләтнең характеры формалашуына табигать ландшафты зур йогынты ясавын исбатлаган дип беләм.

– Гумилевның иң популяр пассионарлык теориясен бүген инде тулысынча расланган дип әйтеп булмый, чөнки аның белән килешмәүче галимнәр күп, әмма ул – бик кызыклы теория. Бәлки, аны расларга башка төрле алымнар кирәктер. Гумилевның әйтүе буенча, һәрбер халык аерым территориядә, табигый шартларда яшәп, шул шартларга хас булган сыйфатларны үзендә тәрбияли. Чүлдә яшәгән кешеләрнең бер төрле гадәтләре була, ә урман халыклары башка төрле формалаша. Табигый үзенчәлекләр кешеләргә, һичшиксез, йогынты ясый. Кайбер халыклар физиологик дәрәҗәдә читтән килгән ризыкны кабул итә алмый. Мәсәлән, рәхәтләнеп чи балык ашаучы халыклар бар. Башка җирдә яшәүче кешенең организмы балыкны бөтенләй эшкәртмәскә мөмкин.

– Ни өчен халыкта пассионарлык арта яки кими?

– Лев Гумилевның теориясе буенча, һәрбер этнос – тере организм кебек: туа, үсә, балигъ була, аннары әкренләп картая, ягъни хәлсезләнә бара. Бу процессларны ул төрки халыклар үрнәгендә карарга тырышкан. Дөньяның зур өлешен үз кулында тоткан Рим, Фарсы империяләре кебек кодрәтле дәүләтләр дә, хәлсезләнеп, кечкенәрәк кыргый кабиләләр һөҗүме нәтиҗәсендә таркалган. Кодрәтле дәүләтне еккан кабиләләр аннары үзләре дә юкка чыккан. Тарихта шундый циклылар бар. Нindидер халыклар тарихи аренага «ташып чыга», бик зур йогынты ясый, ә аннары тарихи аренада глобаль әһәмияттен югалта.

– Кавказ халыкларын без пассионар дип йөртәбез. Татарда пассионарлык ни дәрәҗәдә?

– Без пассионарлыкны сиземли алабыз, ләкин аны үлчәү бик авыр. Кайбер халыклар тынычрак, ә кайберләре – активрак. Гаспринскийның Казан татарлары турында: «Бер тиен артык акчалары булса, алар аны саклый һәм, тагын бер-ике тиен җыеп, сәүдә итү өчен товар ала. Шул рәвешле зур капиталлар җыйган татарлар бар», – дип әйткән бик кызыклы сүзләре бар. Үз-үзләрен үстергән татар байлары күп булган. Андыйлар бүген дә аз түгел. Татар кайда гына яшәсә дә, мул тормыш җиткерергә тырыша. Бу – пассионарлык күренешеме? Монда күп фаразлар булырга мөмкин. Шуңа күрә пассионарлык теориясе ул теория генә булып кала. Аның тарафдарлары да, инкяр итүчеләре дә бар. Ул әле фәндә расланмаган. Кызганыч, гади халык Гумилевны пассионарлык теориясе аша гына белә. Күпләр аны шуның белән чикләнгән дип уйлый. Гумилев – ул күпкырлы шәхес. Аны пассионарлык теориясе белән генә чикләргә ярамый.

– Татарстанда Лев Гумилев исеме ни дәрәҗәдә мәңгеләштерелгән?

– Петербург урамы башында һәйкәл куелды. Нindидер оешмага, урамга аның исеме бирелүен белмим. Аны төрки дәүләтләрдә, аеруча Казахстанда хөрмәт итәләр, хәтта Гумилев исемендәге университет бар. Россиядә ул, зур галим булса да, дәүләттән зур бүләкләр, дәрәҗәләр алган, зур урыннарда утырган кеше түгел. Беренчедән, ул – репрессия корбаны, бу аның карьерасында зур киртә булып торган. Аннары ул – мөстәкыйль фикерле, кыю кеше иде. Сәяси вазгыятькә карамыйча, теләгәнен әйткән, теләгәнен эшләгән кешене күтәрмәгәннәр.

– Галимнең юбилее уңаеннан нинди чаралар көтелә?

– Ноябрьдә Тарих институтында Гумилевка багышланган илкүләм фәнни-гамәли конференция оештырабыз. Галимнәрне төрки дәүләтләрдән дә җәлеп итәргә җыенабыз. Бер конференция Санкт-Петербургта үтте. Алдагы елларда аңа багышланган китаплар чыкты. Бу юбилей аның хезмәтләренә, идеяләренә яңадан кызыксыну уята.

Рифат КАЮМОВ.
intertat.tatar

Җил-давылны күбрәк күргән саен, Ныгый гына бара иманнар...

(Танылган шагыйрь Гали Хуҗинең тууына 110 ел)

Гали ХУҖИ

ТУГАН ТУФРАК

Күп узгансың, илем, сынауларны,
Баш имичә һичбер офтанып.
Тап төшермәс өчен намусыңа,
Синең һәр уч көлең, туфрагың
Миллионнарның тир һәм каны белән,
Ут һәм металл белән кушылган.
Яктылыкка үрләп, яшәргә, дип
Чыктык шытып барыбыз шушыннын.

Һәм аңарга күңел тамырларын
Бик тирәнгә җәйдек аннары.
Һичбер вакыт нинди давыллар да
Ала алмас каерып аларны.

ФӘРИДӘ КУДАШЕВА КОНЦЕРТЫНДА

Җырлады безгә Фәридә,
Моңайтты, уйландырды;
Төшерде язны хәтергә:
Чишмәләр уянуны,
Ужымнар борын төртүен,
Ташкыннар басылуын,
Тууын чыклы иртәнең,
Бөреләр ачылуын –
Һәммәсен искә төшерде,
Уятты азмы дәрт, моң,
Килгәндәй безгә ул үзе
Илчесе булып язның.

Җырлады җырчы җан атып,
Үз, кардәш күреп безне,
Язмышы белән халыкның
Яктыртып күңелебезне.

Тирбәлде, гүя, якында
Агыйдел камышлары.
Юксынып куйдым янымда
Дусларны, танышларны;
Сугышта бергә йөргән,
Таяныч була белгән
Дусларны куйдым юксынып –
Салават оныкларын,
Торганга сизеп һәрвакыт
Аларның онытмавын.
Дәште җыр Димгә, Сакмарга,
Яшьлекне сагындырды;
Унҗиде яшьлек чаклардай
Сөйдерде, кабындырды.

Тыңладык Сәйдәш моңнарын
Йотылып барыбыз да;
Әйтерсең, үзе елмаеп
Утырды янибызда.

Нигә соң безгә җыр кирәк,
Күңелне тибрәтмәсә,
Тормышны күбрәк, көчлерәк
Сөяргә өйрәтмәсә!?

Җырлады аннан Фәридә:
– Безгә дә килегез, – дип,
Эндәште аңа йөрәкләр:
– Киң икән күңлегез, – дип.

* * *

Ничә еллар әйтер сүз тапмадым,
Газаплады шушы хис кенә;
Онытырга күпме тырышсам да,
Оныта алмадым сине һич кенә.
Син хыялым булып әверелдең, –
Гомерем буе, димәк, янарга.
Күргән саен сине
Йөрәгемдә
Иске яра әрнеп яңара.

Аңлыйм ләкин күңел тетрәүләре
Синдә инде кабат тумавын;
Бер йөрәкнең җылысын, мәхәббәтен
Өч өлешкә бүлеп булмавын.

Хыялымда, гүя, ак каен син...
Тормыш җиле каршы иссә дә,
Сыгылмаска тырыш.
                Һәм башыңа
Нинди генә кайгы төшсә дә,
Болай диген:
Бозлы яңгыр уза,
Язын эри салкын кар, диген;
Гомереңдә дә
Мине онытмаучы,
Оныта алмаучы кеше бар, диген.

Ә мин җуйдым, кабат тапмам сине,
Көтмим синнән хәтта бер сүз дә.
Калсын күңел охшап кояш нурын,
Давыл көчен җыйган диңгезгә.
Онытма син
Кайгы елмаймавын,
Уйлама да аның турында.
Син яшәрсең йөрәк сагышым булып,
Кабатланып һәрбер җырымда.

КҮҢЕЛЕМ ҺАМАН УНСИГЕЗДӘ

Узмас картлык читләп безне генә;
Тик кирәкми әрнеп йөдәвем;
Күңелем әле
            һаман унсигездә,
Унсигездә һаман йөрәгем.
Ялкын белән һаман тулы алар;
Һәркем мине дөрес аңласын:
Пыскып сүнәр булсаң ярты юлда,
Кабынудан нинди файда соң?
Сүрелми ян –
            яшәү мәгънәсе шул;
Көчлерәк ян, «сүнә» дисәләр.
Җырлар үлми, әгәр йөрәкләргә
Дәрт һәм ялкын өстәп керсәләр.

Еллар үтәр; арткы эшелонга
Күчмәм ләкин юлда – походта.
Яраксыз бер буш обойма булып
Калмас күңелем һичбер вакытта.
Сизә күңелем
            безнең арсеналга
Нинди җырлар күбрәк кирәген,
Һәм ышанам:
            гомерем соңынача
Унсигездә булыр йөрәгем.

ТИРӘН СУЛАР ТЫН АГАЛАР...

Ләбибә Ихсановага.

Тирән сулар, беләм, тын агалар,
Төпләрендә кала комнары.
Беләм, уза авыр кайгылар да,
Тик күңелдән китми моңнары.

Син болай да бераз уйчан идең,
Беләм сине шактый яшь чактан.
Чәчләреңә иртә чал кунуы
Түгел, сеңелем, бер дә һич юктан.
«Үтми тормыш баштан сыйпап кына...» –
Барысын шулай искә төшерден,
Йөрәкләрне озак сулкылдаткан
Чакларны син ничә кичердең.

Яшьли җуйдың шагыйрь-юлдашыңны,
Әле янып яшәр көннәрдә.
Күтәрербез, –
            авыр кайгы йөген
Күбрәк төшсен безнең иңнәргә.

Күтәрербез...
            Кем аңламас икән
Мондый чакта кеше кайгысын?
Шундый бәндә булса, сора аннан:
– Әйт, йөрәгең синең бармы соң?
Очрый әле бездә туң күңелләр, –
Уйлаучылар бары үзләрен.
Ә беләсең, язлар юып китә
Кышның ямьсез, соңгы эзләрен.

Чын җыр белми сүнү-сүрелүне,
Аңа бары кабыну хас, диям;
Солдат дусның якты истәлеген
Хөрмәт итеп, ихлас баш иям.

Уртак безнең иҗат омтылышы;
«Зур сәнгатьтә урыным таптыммы?»
Китапларың аша һәр яшь буын
Тояр синең күңел яктыңны.

Тирән сулар, беләм, тын агалар,
Кипми алар ерак юлда да.
Синекедәй олы, саф күңелләр
Охшый шундый тирән елгага.

КӨЗЛӘР ҖИТСӘ..

Көзләр җитсә, китә кошлар
Суларын ташлап.
Төшә тәүге кырпак карлар
Үрләргә – башлап.

Үз законы табигатьнең,
Ул – хуҗа үзе.
Берәүне дә үтми читләп
Гомернең көзе.

Инде безнең үрләргә дә
Кырпак кар төшә;
Ул, яшьлектән көнләгәндәй,
Чәчләргә күчә.
Ә гомернең җимешләре
Ник соңлап пешә?

БЕР УЧ ТУФРАК

Җәйләрен дә, кышларын да
Гел беренче эшелонда
Иңләп үттем Кобзарь җирен
Фронтташларым белән бергә.
Походларда тозлы тирем
Азмы тамды шушы җиргә.
Узып кургаш бураннарын,
Безне көткән туганнарның
Тоеп күңеле сулкылдавын,
Карпатларны иңләп үттем.
Гади поход сумкамда мин
Бер уч изге туфрак йөрттем.

Васыять итеп туганымнан,
Бөек Кобзарь туфрагыннан
Алдым аны ерак юлга.
Утта янып-көйгәнгәме,
Анда нәфрәт йөргәнгәме,
Хиросима көле кебек
Чиксез кайнар иде ул да,
Авыр иде, Хиросима
Кайгысы да кушылганга.
Уттай көйдереп алды сыман,
Йөрәгемә кысылганда.

Ут-су аша уздык ерак,
Эльбагача җитте туфрак.
Походлардан илгә кайткач,
Туганнарым Тукай, Такташ
Каберенә сиптем аны,
Күрмәсен, дип, дөнья тагын
Утлы хәтәр циклоннарны.
Күтәрелеп күмер-көлдән,
Тормыш кабат яңарганда,
Олы дуслык чәчәкләре
Шытсын, дидем, аңардан да...

КАРТАЯСЫЗ, ДИЛӘР

1

– Картаясыз,– диләр безгә яшьләр,
Дөреслек тә бар бит бу сүздә.
Әмма
Давыл көчен, язгы кояш нурын
Бергә җыйган тынмас диңгезгә
Охшый, әле һаман безнең күңел,
Бирешмәскә уйлый тиз генә.
Чал булуы чәчнең берни түгел,
Хәер, чал бит диңгез үзе дә...

2

Картаясыз, имеш... Гадәтемме,
Исем китми болай дигәнгә,
Һәркем белә, гади хакыйкатьне:
Тамырлары булса тирәндә,
Җил-давылны күбрәк күргән саен,
Ныгый гына бара иманнар.

ИХ, ЯҢАРСА ГОМЕР ДИГӘНЕҢ..

Шытып үсте иман орлыгы
Уңдырышлы әйбәт туфракта;
Җил-давыллар күреп ныгыды,
Тамырларын җәеп еракка.
Хәтәр хәлләр якын, дигәндә,
Тормыш көчен тоеп тирәндә,
Горур чайкап башын чак кына,
Үсте иман күзгә күренеп;
Үсте иман һаман яктыга –
Гел югары таба үрелеп.

Ә бер төнне иман-гүзәлне
Яшен сугып кара яндырган.
Ярый әле, алдан сизгәндәй,
Орлыкларын коеп калдырган.
Яшь иманнар шыткан алардан
Һәм тормышы аның яңарган.
Их, яңарса гомер дигәнең,
Яшәведәй шушы иманнең!

Атнаның сәяси мизгелләре

Чик-чаманы югалту казасы

Атна сәяси вакыйгаларга бай булды. Аларның күбесе Украинада үткәрелә торган махсус хәрби операциягә бәйле. Арада иң резонанслысы, мөгаен, узган шимбәдә (8 октябрьдә) Кырым күперенең шартлатылуы белән бәйледер. Сәяси күзәтүчеләр аның максаты вә башкаручылары турында төрле версияләрне алга сөрде. Россия Президенты В.Путин шартлатуны гражданнар инфраструктурасына каршы кылынган террор акты буларак бәяләде. Ә авторлары, башкаручылары һәм заказ бирүчеләре Украинаның махсус хезмәтләре булуы турында да белдерде. А.Бастрыкин сүзләренә караганда, аны әзерләүдә РФ һәм кайбер чит ил гражданнары да ярдәм иткән. Йөк машинасының маршрутын да ачыклаганнар: Болгария-Грузия-Әрмәнстан-Төньяк Осетия-Краснодар крае. Димәк, Украинаның махсус хезмәтләре бу илләрдә дә эш иткән булып чыга.

Сәяси яңгырашы ягыннан игътибарны Россия Кораллы көчләренең (РКК) 10 октябрь иртәсендә Украина территориясендәге дистәләгән калаларда энергетика, хәрби идарә һәм элемтә объектларына, шулай ук кайбер завод-фабрика һ.б. предприятиеләргә зыян салу ниятендә, зур ераклыктан ата торган һәм югары төгәллекле ракеталар ярдәмендә ясалган тупланышлы һөҗүме дә җәлеп итә. Ә ул Кырым күперен шартлатуга РКК тарафыннан әзерләнгән җавап буларак кабул ителә. Россия Президенты бу җәһәттән, РФ территориясендә террор актлары үткәрү омтылышы дәвам иткән очракта, җавапның катгый булачагы турында кисәтте. Ракета һөҗүме исә икенче көнне дә яңартылды. Көнбатышның реакциясе дә озак көттермәде. АКШ президенты Джо Байден алга таба да Украинага ярдәм итәчәге, хәтта һава һөҗүменә каршы яңа системалар да бирәчәге турында белдергән. Шундый ук вәгъдәләр «зур җиделек», НАТО һәм ЕС тарафыннан да ишетелде. Алмания исә һава һөҗүменнән саклану буенча Украинага вәгъдә ителгән 4 системаның беренчесен шушы көннәрдә аңа тапшырган.

Бу атнада БМО Генераль Ассамблеясе 10 көн элек БМО КШ утырышында Россия вето хокукын куллану нәтиҗәсендә кабул ителмичә калган резолюция проектын тикшерү өчен ашыгыч төстә махсус сессиясенә җыелды. Документ исә 23-27 сентябрь көннәрендә 4 төбәктә үткәрелгән референдумнарны законсыз дип тану турында. Атнаның башка вакыйгаларыннан игътибарны РФ Президенты В.Путинның Запорожье АЭСын Россия милке дип тану турында указ чыгаруы, Украина иминлек хезмәтенең (СБУ) Россиядәге күп кенә түрәләрне эзләүгә бирүе, ә СКРның андый карар кабул иткән СБУ хезмәткәрләренә карата җинаять эше кузгатырга җыенуы, шулай ук Чечня башлыгы Р.Кадыйровка вакытыннан алда «генерал-полковник» дигән хәрби дәрәҗә бирелүе җәлеп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

ПЕРМЬДӘ

Дөньяда татар яшәмәгән почмак юк. Бу дөрестән дә шулай. Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессы каршында галим Альберт Борһанов җитәкчелегендә татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең Пермь крае, Свердловск, Чиләбе өлкәләрендәге Пермь, Серов, Каменск-Уральск, Екатеринбург, Чиләбе, Троицк шәһәрләре, Бәгәрәк Тамак (Усть-Багаряк), Мөслим авылларында яшәүче милләттәшләребезнең тарихын барлауга багышланган «Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» VII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе көннәрендә дә бу хакыйкать ачык күренде. Тарихчылар җыенында Россиянең дистәдән артык шәһәреннән һәм республикабыз районнарыннан килгән 50 гә якын җирле тарихчы катнашты.

●**Пермьнең үзәк мәчете.**

●**Гөлүзә Муллахмәтова, композитор-башкаручы Әдис Маликов һәм Рәүф Муллахмәтов кунакларны как бәлеш белән каршы алды.**

Фәнни-гамәли конференция Пермь шәһәрендә башланды. Ул ике көн дәвамында крайның иң зур китап йортында – М.Горький исемендәге китапханәсендә Пермьнең 300 еллыгы уңаеннан «300 ел бергә» дигән исем астында Татарстан фәне һәм мәдәниятe көннәренә багышлап уздырылды.

Төбәктә 115 мең татар яшәве теркәлгән. Бу исә милләттәшләребезнең исәп буенча руслардан кала икенче урында булуын күрсәтә. Пермьдә исә алар Пермь өлкәсе татар-башкорт иҗтимагый үзәге, Татар милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе, техник фәннәр кандидаты, профессор, күп китаплар авторы Данир Закиров тирәсенә берләшеп яши. Данир әфәнде конференциядә татарларның бу якларга килеп утыру тарихы белән таныштырды. Ул искәртеп үткәнчә, милләттәшләребезнең Пермь төбәгендә беренче килеп чыгуы Идел Болгарстаны чорларына – VIII-X йөзләргә карый. Галимә Н.Аверина һ.б. биргән мәгълүматларга караганда, Пермь шәһәре биләмәләре үз заманында татар морзасы Култай Шигиревнеке булган. Ул үзенең йорты белән Түбән Мулянка (Нижняя Мулянка – Каманың сул як кушылдыгы) елгасының югары агымы янына күчеп утыра. Бу урын Култай Кыры (Култаево Поле) дип йөртелә башлый.

Соңрак галимнәр Трапезников һәм Оборин Култайның улы Шигалей Култаев үз вотчинасы биләмәләренә патшаның жалованная грамотасын (ташламалар белән файдалану турында) алган. Авыллар елга исемнәре (Югары һәм Түбән Мулла) белән аталган. «Хәзер бу урында Пермь шәһәренең индустриаль районы урнашкан», – дип сөйли Д.Закиров. Әлбәттә, шәһәр В.Татищев үз заманында искәртеп үткән, «народом великим, в ремеслах хитрым, в плодах обильным и купечестве богатым, в строительстве преславным» татар һәм башкортлар катнашыннан башка гына үсмәгән.

Татарлар үзләренең әби-бабалары, танылган якташларының уңышлары белән горурланып яши. Алар арасында бизнес, сәнәгать, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәләрендә, сәнгатьтә һәм спортта Пермь шәһәренең данын күтәргән, крайда гына түгел, үзләрен башка илләрдә дә таныткан шәхесләр бар. Әйтик, Октябрь инкыйлабына кадәр Пермьдә Рус Америкасының баш идарәчесе, кенәз, контр-адмирал Д.Максутов туып үскән.

Төбәкне өйрәнүче Марсель Миннәхмәтов бу якларда XIX гасыр ахырында танылган татар сәүдәгәрләре яшәвен бәян итте. 1907 елда шәһәрнең Печән базарында тикшерүләр нәтиҗәсендә 98 предприятиенең татар һәм башкортларныкы булуы ачыкланган. Әйтик, Мөхәммәт Биктаһиров киптерелгән җиләк-җимеш, акмай, хушбуйлар белән сату иткән, Абдул Зәйнетдинов мануфактура кибете тоткан. «Тимкин һәм аның уллары» фирмасы да тирә-якта киң танылган. Сәүдәгәр-меценатлар Хисаметдин Агафуровның үзенең уллары белән ачкан «Бертуган Агафуровлар» сәүдә йортын, Зиннәтулла Ибәтуллинның галантерея, мануфактура кибетләрен шәһәрдә яхшы белгәннәр. Алар хәйрия эшен дә киң җәелдергән.

Шулай ук Гражданнар сугышы каһарманнары, Совет дәүләтенең күренекле шәхесләре Хөсәен Мәүлетов, Кашшаф Мохтаров, Советлар Союзы Геройлары, Бөек Ватан сугышы командирлары Әнвәр Гатауллин, Зиннәтулла Исхаков, эре сәнәгатьчеләр Рәфкать Разетдинов, Әлфрид Хәйбрахманов, Рөстәм Хисаев, Раил Хисмәтуллин – бу яклардан...

Башка милләтләр арасында яшәгән татар балаларының туган телләрендә белем алу мөмкинлеге юк, уку йортларындагы, балалар бакчаларындагы барлык аралашулар да русча алып барыла. 1989 елда Пермь өлкәсендә 92 милли мәктәптә балаларга туган телләрендә белем бирелгән. Соңгы елларда алып барылган вазгыять нәтиҗәсендә этник компонентлы 32 мәктәп кенә калган, авыл мәктәпләрендә дә татар теле һәм әдәбияты дәресләре атнага ике сәгать кенә укытыла, ә кайберләрендә факультатив буларак кына кертелә. Крайның татарлар күпләп яшәгән Березовский, Кишертский, Суксунский округларында да татар теле укытыла торган бер генә мәктәп тә юк икән. Иң аянычы – балалар Г.Тукай, М.Җәлил, Г.Камал, С.Сәйдәшев, Б.Урманче кебек мәшһүрләребезне дә белми үсә. Теләгән балалар Пермь крае төбәк милли-мәдәни автономиясе оештырган якшәмбе мәктәбенә йөреп туган телебезне өйрәнә. Алар «Җәлил укулары», «Ягъфәров укулары» конкурсларында призлы урыннарны ала. Әмма якшәмбе мәктәбе генә балаларга кирәкле белемне биреп бетерә алмый.

«Пермь өлкәсе татар-башкорт иҗтимагый үзәге», Пермьнең Татар милли-мәдәни мохтарияте әлеге вазгыятьтә төбәктә һәм шәһәрдә туган телебезне, милли мәдәниятебезне һәм гореф-гадәтләребезне саклап калуны төп максат итеп куйган. Шушы ниятттән «Татар мәдәнияте – Пермь краеның аерылгысыз гомуммилли казанышы» дигән инновацион комплексы проект эшләнгән. Төп игътибар исә баланы гаиләдә туган телендә, милли традицияләрне белгертеп тәрбияләүгә бирелә, ел саен «Пермь шәһәренең иң яхшы татар гаиләсе» дигән конкурс та үткәрелә, җиңүчеләргә губернаторның махсус бүләге тапшырыла. Конференциядә кат-

ТАТАРСТАН КӨННӘРЕ

●Пермь шәһәре Татар милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе, техник фәннәр кандидаты, профессор Данир Закиров һәм тарихчы галим, академик Альберт Борһанов Татарстанның Мөслим районы төбәкне өйрәнүчеләре Рушат Солтанов белән Назилә Бәдретдиновага мактау грамотасын тапшыра.

нашучыларга узган елгы бәйгедә җиңүче булган Миләүшә һәм Ленар Маматовларның гаилә ансамбле чыгышын да күрергә насыйп булды. Миләүшәнең этисе Әдис Маликовны Пермьда композитор, җырчы, талантлы оештыручы буларак беләләр.

Шәһәрдә автономия каршында шулай ук «Чәк-Чәк» яшьләр оешмасы булдырылган. Ә «Пермь талантлары» татар-башкорт халык иҗаты фестивале, шәһәр һәм район Сабантуйлары барлык милләттәшләребезне берләштереп, милли мәдәниятебезне пропагандаларга ярдәм итә.

10 ел элек Пермьдә татар җыр һәм бию сәнгатен күрсәтә алырдай үзешчән коллективлар булмау сәбәпле, мөстәкыйль мәдәни чаралар үткәрә алмасалар, һәвәскәрләрне Барда районыннан чакырырга туры килсә, хәзер хәл үзгәргән. Шәһәрдә «Мирас», «Аваз», «Мәхәббәт», «Яшьлек», «Гүзәл Чулман», «Ирбис», «Тургай», «Илһам» кебек иҗат коллективлары татар мәдәниятен күрсәтә. Кунаклар алдында чыгыш ясаган «Гүзәл Чулман» фольклор ансамбленең җыр-биюләре дә сокландырырлык. Гөлүзә Хәмзина җитәкчелегендәге бу коллектив Ульяновскида узган «Түгәрәк уен» Россия фольклор фестивале җиңүчесе булган, Татарстанда Гран-при алган, Италиядә, Венгриядә үткәрелгән Халыкара фестивальдә лауреат исемен яулаган. Ильнура Уфимцева җитәкчелегендәге «Ирбис» ансамбле исә Испаниядә узган халыкара этник фестиваль-конкурсының бронза призын яулап кайткан.

«Пермь опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты, В.Барсова исемендәге Бөтенроссия конкурсы премиясе лауреаты Айсылу Хәсәнова да – бу якта яшәүче милләттәшләребезнең мактанычы. Илдус Арсланов, Вилия Госманова алып барган «Арслан» студиясе дә актив мәдәни-мәгърифәти эш алып бара», – ди Д.Закиров...

Төбәк тарихын өйрәнүчеләрне Пермь ягы татарлары гына әзерли торган татлы милли ризыкларының берсе – Татарстан фәне һәм мәдәнияте көннәренә багышлап бик матур итеп бизәлгән как бәлеш белән каршы алганнар иде. Пермь төбәгендә бер генә туй да, бер генә бәйрәм дә как бәлешсез узмый икән. Аны Көнгер районының Яланыч (Бажуки) авылында яшәүче Гөлүзә һәм Рәүф Муллахмәтовлар гаиләсе әзерли. Алар бу бәлешләрне Казанда да күрсәткән. Гомумән, Муллахмәтовлар әзерләгән как бәлеш, чәкчәк, кош теле, өчпочмак, бавырсак, бөккән кебек милли ризыкларыбыз теләсе кайсы бәйрәм, туй табыннарының бизәге, диләр. Гөлүзә белән Рәүф җитәкчелегендәге пекарняда әзерләнгән шәңгәләр дә тел йотарлык тәмле. Алар эшне Яланыч кешеләре өчен икмәк пешерүдән башласа, еллар узган саен ризыкларының төрләре арткан. Как бәлеш исә җиде бик юка катламнан тора, араларында иттарткычтан чыгарылган ак һәм кара йөзем, күрәгә, хөрмә, караҗимеш, хәлвә.

Пермьдә яшәүчеләр Римма Хисмәтуллинаның шәхси кафесында әзерләнгән милли ризыкларыбызны бик ярата икән. Бу кафеда югары сыйфатлы хәләл ашлар әзерләнә, милли ризыклар тәкъдим ителә...

Төбәкне өйрәнүчеләр Пермь шәһәре белән дә танышты. Шәһәрдә биек мәчет манаралары күп. Дистәгә якын мәчет эшли. Пермь крае мөфтиенең урынбасары Рөстәм хәзрәт Рәхмәтулла Пермь крае хакимияте, меценатлар көче белән җәмигъ мәчете төзелешен дә башлап җибәрүләре турында сөйләде. Аның инде эчке эшләре генә калган. Аллаһ йортының быел бер өлеше файдалануга тапшырылыр, ул шәһәрнең бизәге булу белән бергә, мөселманнар үзәгенә дә әверелер, дип уйлыйк. Мәчетнең бер өлешендә мәдрәсә дә урнашырга тиеш. Әлегә мәдрәсә шәкертләргә 1937 елда төзелгән бинада белем бирә. Екатеринбургның Урал тау университетында теология кафедрасында укытыла. Ураза, Корбан, Мәүлид бәйрәмнәре, Сабантуй шәһәрнең Горький исемендәге ял-мәдәният паркында һәм стадионнарда үтә.

Пермьдә шулай ук үзенчәлекле сыннар да күп. Берсе «Тозлы колак» дип атала. Шәһәр кайчандыр диңгез булган урында урнашкан, бик тирән катламнарда тоз ятуы беленгән. Аны зур авырлыклар белән чыгарганнар, бәясе исә алтын белән исәпләнгән. Тозны капчыклап иңнәрендә ташыган йөкчеләрнең исә колаклары күпереп чыга торган булган. Татар скульторы Рөстәм Исмәгыйлев ясаган бу сын исә шушы вакыйгаларны искә төшерә.

Пермьдәге конференциядә Данир Закировның «Шахтеры – гвардия труда» китабы да тәкъдим ителде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

●Оренбургтан төбәк тарихын өйрәнүче Алмира Омарова һәм Иж-Бубыйдан Рәзилә Хәмидуллинаның эше кызу.

●Тозлы колак.

●«Гүзәл Чулман» ансамбле чыгыш ясый.

Мәдәни җомга
14 октябрь
№40, 2022

Көзнең гадәти бер көне

Рөстәм ЗАРИПОВ

Дөбердәп ишек ачылды һәм укытучылар бүлмәсенә ике кеше килеп керде. Алар плащтан, эшләпәдән һәм саз ерудан олтаны калынайган пычрак күн итекләрдән иде.

– Нишләп утырасыз монда авыз ерып? – диде алдагы кара мыеклы, тәбәнәк, юан кеше. Ул, идәндә эре-эре эзләр калдырып, түргә, ян як стенадагы «Директор» дигән язулы ишеккә ыргылды. Юлдашы сүзсез генә аңа иярде. Ул ишек тоткасын ике кат йолыкты. – Кайда директор?

– Иртән ронога дип китте, кайтышлый басуга да сугылырмын дигән иде.

– Басуга сугылырга кирәкми, эшләргә кирәк анда, сеңелкәем. Бөтен составны бәрәңгегә мобилизовать итәргә, диелде. Почему үтәмисез? Ә? Замы бармы аның берәр? Завуч бармы?

– Мин булам, Нуриәхмәт Зиннурович, – диде Мәрзия Әгъливеевна, урыныннан корт чаккандай чәчрәп торып басып.

– Йә, сайрап җибәр, – диде Нуриәхмәт Зиннурович, завучның бер чеметем борынына, җыерчыклы тар маңгаена текәлеп, һәм теш арасыннан гына: – Ханым... – дип өстәде.

– Мин директорга җиткердем, ләкин ул үзенчә хәл итте, күрәсең...

Яшь укытучы Һашим Мәрзия ханымга карап күзләрен челт-мелт йомгалады да җәһәт кенә урыныннан торып:

– Югары класслар шунда, Нуриәхмәт Зиннурович, түбән класслар да атна буе эшләделәр, ничәсе чирләп больницага керде, – дип ашыга-кабалана тезеп китте.

– Тукта! – дип бүлдерде аны Нуриәхмәт Зиннурович, сөмсере коелып. – Гыйниятов, кара әле бу Түләшкә батырына. Син нәрсә, – дип, Һашимга бәләкәй күзләре белән тишәрдәй итеп кадалды ул. – Нәрсә син ат дагалаганда ботыңны кыстырасың? Ә? Дезорганизация таратып! Алайса, без әйтербез. Безгә ак перчаткалы укытучылар түгел, ә народный укытучылар кирәк диярбез, халык арасында йөри торган. Кара син аны! Үкчәле туфлиләр киеп, галстуклар тагып, чалбар төбе шомартып утырасыз. Ә без саз ерып йөрергә тиеш.

Сөйләгән чакта, ара-тирә акселераторга баскач, үкереп-үкереп куйган машина моторы сыман, Нуриәхмәт Зиннурович та вакыт-вакыт тавышын көчәйтеп-көчәйтеп җибәрә иде. Ул пычрак итекләренә ялт кына карап алды да юлдашына борылды.

– Боларга бәрәңге кирәк түгел, Гыйниятов. – Нуриәхмәт Зиннурович, күзләрен әрле-бирле йөртеп, каһәрле карашы белән берара бүлмәдәгеләрне ашады.

Һашимның куллары салынды, башы иелде, ялганчы чокыры йодрык сыярлык булып тирәнәйде.

– Юк, син кем булдың соң әле безне өйрәтергә? – диде Нуриәхмәт Зиннурович бүртенеп һәм җөмләсен берничә хәтәр сүз белән җилемләп тә куйды.

Риза Сафичның урындыгы шыгырдап куйды.

– Сез мәктәп дигән изге йортка сүгенергә килдегезме? – диде ул саңгырау тавыш белән.

Нуриәхмәт Зиннурович песи баласыныкыдай тере, нәни түгәрәк күзләрен Риза Сафичка текәде.

– Изге йорт, имеш, – диде ул, иреннәрен ямьшәйтеп. – Бардак сезнең монда, панимаеш. Энәдән-җептән киенеп, чалбар төбе шомартып утырасыз. Балаларыгыз чыр-чу килеп, тәккә чабып йөри. Аяк киемегезне салыгыз дип, ике имгәге юлга аркылы төшеп тора бит әле. Ә бит оялмыйсыз! Аларны басуга чыгарсак, илгә файда килер дип куркасызмы? Саботажниклар сез! Яңгыр ява анда: кала, чери бәрәңге...

Риза Сафичның җыерчыклары тирәнәйде, күзләре урынында ярыклар гына калды. Кинәт аның кылт итеп исенә төште: мондый сөйләшү бер булган иде инде. Күптән, байтак еллар элек булган иде. Шул ерак чорда менә шушы Нуриәхмәт кәнәфиен биләгән Камалетдинов дигән бәндә, исеме аның Әләметдин иде, укытучыларның матур киенгән булуларын, балаларның эш барышында куышып китеп уйнап алуларын ошатмыйча, котырынып җикеренгән иде. Әйе, әйе, көз иде, мәктәп балалары белән колхоз бәрәңгесе алырга чыкканнар иде... Камалетдинов ишеләргә бернинди дәлил дә тәэсир итмәячәген белгәнгә күрә, Риза Сафич тәртәне зиректән бөгәргә булды.

– Сезгә безнең матур киенүебез ошамый, – диде ул нәфрәт белән. Аннары: – Балаларыбызның шатланып уйнап көлүләрен ошатмыйсыз, – дип дәвам итте. – Бар иде инде ул андый берәү... – Риза Сафич, Камалетдиновның шешенке күзләренә күзен текәп, бермәл дәшми торды, аннары салмак кына теш арасыннан сыгып: – Гитлер иде ул. Без аны өненә барып дөмектереп кайттык, – дип өстәде...

Мәктәп директорлыгыннан кайчандыр әнә шулай очкан иде Риза абзагыз... һәм менә каршыда тагын бер Әләметдин тора...

– Ә сез ояласызмы соң?

– Без нәрсәдән оялырга тиеш әле? Дәүләт планнарын хәл иткән өченме?

– Оккупантларча кылануыгыздан. – Риза Сафич Нуриәхмәт Зиннуровичны баштанаяк, мөхтәрәм күренер өчен водород перекисе белән көмешләндерелгән бер тотам чәченнән алып, пычрак күн итекләренәчә күздән кичерде. – Ә планнар хәл итүгә килсәк, – диде ул тыныч кына, – хәбәрдарбыз. Ит планын туберкулезлы сыерлар тапшырып, сөт планын Башкортстан һәм Круглое поле базасы атланмаен сатып алып, шуны кабат тапшырып тутырасыз. Ә яшелчәне тагын да кызык юл белән үтисез. «Үзәк» совхозы азык кишерен районга тапшыра, аны икенче хуҗалык сатып ала да... хөкүмәткә илтә. Әллә дөрес түгелме? Йон белән балны бодайга алмашка башка районнардан җыйныйсыз. Бәрәңге белән чөгендер планын да үтәүнең җаен беләсез.

– Син шулай материал туплау белән дә шөгыльләнәсеңмени әле? – дип үкерде Нуриәхмәт Зиннурович, кара коелып. – Әллә андый һөнәрең дә бармы?

Әңгәмәгә Мәрзия ханым ачыклык кертәсе итте.

– Аның янына элекке укучылары кереп йөри, – диде ул. – Кайсы бухгалтер, кайсы инженер, милиционерына кадәр бар. Шулар гайбәтен сөйли булыр.

– Йә-йә. Бәрәңге белән чөгендер проблемасын хәл итү ничек эшләнә?

– Җәй буе басудан кайтып кермәгән балаларны, укытучыларны, укуларны өзеп, тагын да басуга куып чыгару юлы белән.

– Эшләгәннәре әллә минем өченме? Үзләре өчен, үзләре яшәгән колхоз өчен, үзләре яшәгән район өчен!

– Һәм колхоз җитәкчеләре, белгечләре, бер көтү роно сорыкортлары, тагын басуга килеп тә карамаган әллә кемнәр бүләк алсын өчен. Әйтерең бармы? «Маяк» колхозы рәисе җәйнең җәй буена без эшкәрткән, көз җиткәч, берәмтекләп, саздан арындырып, сабагын кисеп, шәһәрдән килгән машиналарга без төяп озаткан шикәр чөгендере өчен ике мең ярым сум премия ала. Ә ел азагында ялганлап үтәлгән барлык төр планнар өчен аңа тагын мең тугыз йөз алтмыш сум бүләк. Хәтта колхоз конторасы җыештыручыга да, план үтәлгән өчен дип, өч йөз җитмеш сум өлеш чыга.

– Колхозчылар эшләми дисеңмени инде син?

– Алар басуда күренмиләр.

– Ә бригадирлар, звеноводлар, бригадир ярдәмчеләре? Алар да күренми что ли?

– Бригадир ярдәмчесеме? – диде Риза Сафич, җене чыгып, – рәхим итте бер тапкыр. Иелеп бәрәңге чүпләгәндә борын төбемдә күн итекләр күреп күтәрелеп карасам, күрәм, өч класс белемле бригадир ярдәмчесе Хәсәнша рәхим иткән икән, рәхмәт яугыры. Балчыкка типкәли торгач, ике бәрәңге казып чыгарды бу. Минем биткә туфрак чәчрәтүенә исе китмәде моның, бәрәңгеләрне иелеп алып чиләккә салу да уенда юк. Күн итеге очы белән күрсәтә миңа Хәсәнша: «Күзең чыккан мәллә, нәрсә калдырасың?» – янәсе.

– Сиңа нәрсә, акча кирәкме? Нигә сөйлисең бу әкиятләрне? Безгә аңлашылмый. Син аңлыйсыңмы берәр нәрсә, иптәш Гыйниятов?

Басыйр Гыйниятович, «юк» дигәнне аңлатып, башын чайкады.

Риза Сафич, бармаклары белән аралап, чәчен артка сыпырды.

– Сез мине үзегез белән бутамагыз: хехе-хе... Мин бераз мәктәп өчен өмет итеп кенә. Балалар эшләгәннең чирегә кулләмендә булса да. Сер түгел, елның елында йә күмер бетеп, йә торба ярылып ятрышар кыш мәктәп җылытылмый. Җылыту системасы череп беткән, ә балалар туңа, чир ала.

– Мәктәбегезне без килеп җылытып биргәнне көтәсезмени әле сез? Ансат! Ха! Сезнең бит директорыгыз бар. Әйтегез аңа, җылытсын. Шуның өчен ул акча ала.

– Акча ала, дисез. Нигә соң алай булгач үзегез ярдәм кулы сузмыйсыз?! Балалар хезмәте түгеп килгән ул хәрам премияләрдән сез дә өлешсез калмыйсыз түгелме соң?

Нуриәхмәт Зиннурович үзе дә сизмәстән ике адым артка чикте һәм бер адым алга атлап куйды. Юлдашы да ни өчендер шул хәрәкәтләрне кабатлады.

– Ремонт турында, – диде Нуриәхмәт Зиннурович, карлыгып китеп, һәм бер кулы белән галстугын бушата-бушата: – Директорыгызга әйтегез, мәсьәләне кабыргасы белән куйсын. Җыламаган балага имезлек каптырмыйлар, әйе, чишәрбез. Ә премия хакында, агай кеше, үзегез белмәгәнне лыгырдамаска кирәк. Ә сез, иптәш завуч...

– Тыңлыйм, Нуриәхмәт Зиннурович.

– Кемнәр килеп йөри бу картка, списогын төзеп минем секретарьга төшер.

– Ярар, Нуриәхмәт Зиннурович, ярар!

– Менә шул... Стоп. Тукта әле. Сиңа ничә яшь?

– Миңа?

– Сиңа, сиңа. Нигә шүре җибәрдең? – Нуриәхмәт Зиннурович мыскыллы көлемсерәп куйды: – Сиңа!!!

– Алтмыш өч, шуннан ни диярсез? – диде Риза Сафич, каушый төшеп.

– Ах, алтмыш өчмени? – дип сузды Нуриәхмәт Зиннурович, ияген чайкый-чайкый. – Син кайчанга кадәр яшь буынны бозарга җыенасың инде? Ә! Гыйниятов, – диде ул, юлдашына ымлап. – Менә син тозүче кеше, әйт, канализация торбасына берәр сусәргән чүпрәк яисә иске мунчала тыгылса, шакшы су өскә чыгамы?

Гыйниятов, «әйе» дигәнне аңлатып, ияк какты.

– Аны ыргаклы колга төшереп тартып чыгаралар, шуннан агым дәвам итә, тәк?

Гыйниятов янә житез генә ияк какты.

(Дәвамы киләсе санда).

Рамил КУРАМШИН: «Мин хәзер дә сәхнәгә чыгып уйнарлык хәлдә идем»

(Ахыры.Башы 39 нчы санда).

– Гомумән, татар җырчысы нинди булырга тиеш соң ул?

– Татар җырчысы грамоталы булырга тиеш. Беренчедән, ул үз халкының тарихын белсен. Еш кына мин радио тапшыруларын тыңлыйм. Анда шулкадәр акыллы фикерләр әйтәләр, шуларның беразын гына отып калсаң да, син инде шул белемнәр белән дә теләсә кемне «егып сала» аласың. Сәхнәдән генә мин-минләнеп түгел, ә бүтән җирдә дә белемеңне, акылыңны, милләт өчен файдалы сүзләреңне җиткерергә, гамәлдә күрсәтергә тиешсең. Чөнки акыллы фикерне 80 яшьлек абзый әйтсә – бер хәл, ә менә 20-30 яшьләрдәге егет-кызлар сөйләп бирсә, икенче нәрсә була. Университет дәрәҗәсендә дә бик кирәкле материаллар яңгырый, аларны тыңлап баручы кешеләр, һәрхәлдә, надан булып чыкмый.

Җырчылар хәзер көтүләре белән йөри. Ләкин элекке замандагы уртакул җырчы бүгенге «йолдыз» булып йөргәннәрдән күпкә өстенрәк. Тәртипкә салып булыр иде шуларны, әгәр дә белгечләрдән торган худсовет булса. «Чүп-чар»га бераз киртә куелыр иде. Бөтен бәла шунда: халык җырларын башкаручылар, мөстәкыйльлеккә чыккач, шул эстрада агымына кушылып китәләр. Акча эшлиләр. Кайда акча – анда профессиональлек юк... Ул яктан караганда, мин бик каты консерватор кеше. Тел, моң саклансын, дип борчылам.

Мине 20 яшьлек чагыма кайтара алсалар, нәрсә дияр идемме? Шул арада алган белемнәремне ныгытып, шул белемнәрем белән сай фикерле кешеләрне «егып» салыр идем. Тыңлап торам да, күбесе хәзер акыллы, укымышлы. Дини темаларны күбрәк күтәрсеннәр иде. Диннән куркучылар бар, аларга күбрәк вәгазьләр тыңларга киңәш итәр идем. Бер тапшыруда бер авыл мулласы Аллаһы Тәгаләнең барлыгын исбатлады. Ә мин гомер буе Совет власте системасында яшәдем, шул тапшыруны тыңлагач, «чынлап та шулай бит» дидем.

– Кешене җырларга өйрәтеп, аның тавышына моң өстәп буламы?

– Тырышсаң, була. Аның өчен бик күп, бик күп мәшһүр җырчыларны тыңларга кирәк. Менә мин Илһам абыйның бер башкорт җырын башкарганын игътибар белән тыңлый идем һәм шунда ук сүзләрен дә, көен дә отып, үземчә җырлап йөрдем. Вак-төяк җыр түгел иде ул.

Мин татарлыктан читкә китмәдем. Бормалар гади музыканы баета, ул – татар җырларына хас күренеш. Бормалар – татар халык көйләренең байлыгы. Аны элекке җырчылар да, баянчылар да бик әйбәт эшли иде. Ә менә хәзер татар халык җырлары үлеп бетеп бара, дисәң дә була. Чөнки ул җырчылар бормаларны дөрес җырламый, тыңлап үсмәгән, ул аның күңелендә юк. Күңелдә булмагач, чыгарып та булмый, дигән сүз. Бөтен нәрсә буыннан буынга күчәргә тиеш. Хәзер буыннан буынга күчү туктады.

Баян өчен язылган кайбер әсәрләрдә мин ул бормаларны кертәм, нотага язам, тырышкан, теләгән кеше аларны табып, шул стильдә уйнарга мөмкин. Ул бормаларны башкарып чыгу бик катлаулы.

Татарның моңы да шул бормаларда, диләр. Кавказ халкының җырларын ишеткәнең бардыр. Аларның үзләренең специфик бормалары бар. Аларда хәзерге җырларны бормалар белән башкару бара, алар, безнең кебек, бормаларны онытмый. Минем тыңлаганым булды, чөнки ул якларда булганым бар. Алар бормалы җырларның элекке халәтен, нигезен саклый. Аларның барысын да нотага төшереп булмый, ул күңелеңдә булырга тиеш. Аны күңелеңдә тоярга һәм күңелеңнән чыгарып уйнарга кирәк.

Бездә кайбер яшьләр тырышмакчы була, әмма үзебезнең элекке музыкантларны, җырчыларның язмаларын тыңласыннар иде башта. Татар көйләрен уйнаучылар, җырлаучылар бормаларны күңелгә сеңдереп, аны киләчәк буынга җиткерүне дәвам итсен иде. Олырак музыкантлар белән киңәшеп эшләсәләр, булыр, дип уйлыйм. Ә бүгенге көн музыкасы белән генә халыкны туендыру җитми.

Алар руслашмый да, европалашмый да. Әйтик, казахлар думбрада уйнаса да, үз үзенчәлеген саклап кала. Кыскасы, элекке алымнар уен коралларында уйнаучылар һәм җырчылар тарафыннан сакланырга һәм дәвам итәргә тиеш. Беркөнне ул халыкларның музыкасы аңлаешсыз җырга әйләнер. Аны беркем дә «менә бу – казах җыры, бу – үзбәк җыры, монысы – таҗик җыры» дип аерып алып әйтә алмас.

– Халыкны ничек итеп үзебезнең җырларны тыңларга өйрәтеп була?

– Аңлату эшен алып бару кирәк. Мәсәлән, лекция концертларын оештырып була. Алар бит элек була иде, хәзер юк.

– Татар моңын, татар җырын дөньяга танытып буламы? Бу мөмкин хәлме?

– Була, бу һич тә оялырлык әйбер түгел. Вакытында дөнья аренасына Илһам абыйның «Карурман» җырын чыгарып булыр иде, ул – эталон. Илһам абый Мәскәүдә «Карурман»ны җырлаганда, яһүд халкы аңа бик зур бәя биргән иде. Димәк, безнең халык көйләребез кемнекеннән дә ким түгел, бары тик аларны әйбәтләп эшкәртеп, әйбәт итеп башкара белергә генә кирәк!

– Эстраданың бүгенге халәте нинди?

– Бик үк әйбәт түгел. Күңелне һич кенә дә куанычлы уй-фикерләр биләми шул. Әгәр моннан 30-40 еллар элек бу дөньядан киткән кешене терелтеп, бүгенге эстрада концертына кертеп утыртсаң, миңа калса, ул башта кая эләккәнен аңламый торыр иде, чөнки ул еллардагы көй-җырларыбыз белән бүгенгеләр арасында аерма бик зур һәм, әйтергә кирәк, яхшы якка түгел.

Мин олы сәхнәгә аяк баскан 1960 еллар азагында, 1970 елларда да моң-көйләребез, музыкаль сәнгатебезнең миллилеге әле исән-сау хәлдә иде. Әмма 1980 еллар тирәсендә, «заманча» дигән сүзгә таянып, моңсызлану, миллилектән ерагаю процессы башланды.

Бүген татар җаны өчен илаһи нәрсә булган моңның нәрсә икәнен белмәгән җырчылар «йолдыз» булып йөри. Рәтләп нотаны да белмәгән кайберәүләр «ни татар, ни рус» җырлары язып, үзләрен композитор дип атый. Халкыбызның милли рухын җимерүгә илтүче бу афәттән котылу өчен, яшь буыннарга алда санап үткән мәшһүр шәхесләребезнең иҗатларын пропагандалау зарур. Алар өчен безнең халыкның үз сәнгатькәрләребезнең иҗаты кыйбла булырга тиеш. Шул чакта гына без милли рухыбызны, милли йөзебезне саклап кала алачакбыз.

Хәзерге җырларны тәнкыйтьләр идем. Элегрәк татар композиторларның әсәрләреннән миллилек аңкып тора иде. Ә хәзер – бер-берсенә охшаш көйләр, аранжировкалар... Бу – эстраданың бер бәласе. Төрлелек күп булырга тиеш түгел, бөтен нәрсәнең чамасы бар. Хәзерге кайбер җырларның сүзләрен алып атсаң, «бу – татар көе» дип беркем әйтмәс. Бу – мескенлек, бу – дөрес юл түгел.

Эстрадада төрле нәрсәләр булыр, әмма ни генә булмасын, без – Аллаһ бәндәләре. Дин кануннарын мин мәктәп балаларына, студентларга укытыр идем. Анда бик күп кирәкле әйберләр бар. Бер көнне мулланың сөйләгәнен тыңлап тордым: дин кануннары көндәлек тормышта кешегә бер дә комачау итми, элек әби-бабаларыбыз ислам кануннары буенча яшәгән бит, тормышны алып барганнар. Дин кануннары кешене әхлак-тәрбиягә, яхшылыкка өйрәтә. Дин тәрбиясендә берниндә зыян юк.

– Тормышыгыз турында да сөйләсәгез иде.

– Хәзер уңайсыз хәлгә калдым шул. Бераз атласам, аяклар арый, йөри алмый башлыйм. Ял итеп алмыйча булмый.

...Инсульт – бик кабахәт авыру икән ул. Аның белән хәзер бик күп кеше авырый, бик күп яшьләрдә дә бар. Харап итте бит! Мин бит әле хәзер дә сәхнәгә чыгып уйнарлык хәлдә идем.

Әңгәмәбез тоташ дәвам итмәде, әлбәттә. Рамил абый ял иткән арада, аның хатыны Рузалия апа белән дә сөйләшеп алдым.

– Рузалия апа, ничек таныштыгыз сез?

– Шунысын әйтим: дөньяда Рамилдән дә яхшырак кеше юк. Без Казанда таныштык. Мин Рамилнең катнашындагы концертларга йөри идем. Мин аннан 4 яшькә олырак. Рамил – талантлы, тырыш, грамоталы, акыллы, бик тә чибәр кеше. Иң элек, мин аның шушы сыйфатларын күреп алдым. Без танышканда, ул тыйнак иде, шуңа күрә аны «ычкындырмаска» тырыштым.

Холкым ягыннан мин әрсез. Сәяхәтләргә киткәндә хатлар язышa идек. Рамилнең туган ягы – Кучкай Пожары авылына да кайтып килдем, әти-әнисе белән таныштым. Әти-әниләре, мине күргәч, аңа өйләнергә киңәш итте.

Рамилгә кияүгә чыкканда, ике балам – кызым һәм улым бар иде. Рамил аларны үз балаларыдай карап үстерде. Кызганыч, уртак балабыз булмады.

– Үз баласы булмаганга үкенмәдеме?

– Юк. Һәрхәлдә, үкенүен миңа күрсәтмәде. Гомумән, Рамилнең миңа бармагы белән дә чирткәне булмады, ул беркайчан да кул күтәрмәде, хыянәт итмәде. Бик тәртипле, әдәпле кеше. Андый кешеләр бик сирәк ул, кызым.

– Икегез дә пенсиядә...

– Пенсия акчасына яшибез. Тегендә-монда эш тәкъдим итәләр, идән себереп, юа алырлык хәлдә әле мин, ләкин Рамилне калдырып чыгып китә алмыйм.

– Рамил абый, халкыбызга теләкләрегез нинди?

– Татар халкы татарча сөйләшсен, җырчылар дөрес итеп җырласын, музыкантлар дөрес итеп уйный белсен иде. Шул өч таләп үтәлсә, эстраданың халәте яхшы, гомумән, татар халкының киләчәге булыр. Көнчыгышка ияреп, заманчалаштыру дәвам итсә, телсез, моңсыз калырга да мөмкинбез.

«Чын сәнгать әсәре һәм чын талант ияләренең иҗаты гына мәңгелеккә кала», – дигән мәгълүм хакыйкать бар. Алар беркайчан искерми, таушалмый, киресенчә, еллар үткән саен, аларның кыйммәте арта гына бара. Кызганыч, менә шушы хакыйкатьне бездә соңгы елларда оныта башладылар, һәм «заманча» дигән шаукымга ияреп, җырларыбыз да, җырчыларыбыз да «интернациональләшә», ягъни урыслаша башлады.

Әгәр без бүген Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов, Әлфия Афзалова, Флера Сөләйманова кебек мәшһүр җырчыларыбызны оныта башласак, киләчәктә халкыбыз күңелен аулаган җырчыларыбыз бөтенләй онытылмагае... Ә милли сәнгате һәм милли рухы булмаган халык, милләт буларак, яшәүдән туктый, бу – аксиома! Шуңа күрә Рәшит Ваһапов кебек җырчыларыбызның сәнгатен без радио-телевидениедән дә, матбугат битләреннән дә һ.б. төрле чаралар белән дә үсеп килүче яшь буынга һәрдаим пропагандаларга тиешбез. Күбрәк классик татар җырларын тыңласыннар иде.

«Дошманың сине мактар, дустың дөресен әйтер» дигән халык. Мин, милләтемнең сәнгате яшәсен, дип янып-көям. Тәнкыйтьләсәм дә, ихластан әйтәм. Кем дә бу дөньяда мәңгелек түгел, буыннарыбыз өзелмәсен иде. Яшьләргә ул гореф-гадәтләрне дәвам итәргә кирәк.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

НЕГЪМӘТНЕҢ

Ниһаять, ул Казанда. Рәссам Салават Изад улы Негъмәтов башкалабызга бик урау юллар аша килеп ирешә. Тамырлары Башкортстаннан, кендек каны Таҗикстанның шәһәр тибындагы Обигарм бистәсендә тамган. Аларның гаиләсе, Башкорстанга кайтып бераз яшәп алгач, Бохарага барып төпләнгән. Мәскәү академия сәнгать училищесында белем алганнан соң, 1973 тә юллама белән «Камаз» төзелешенә җибәргәннәр. С.Негъмәтов байтак еллар Чаллы шәһәренең йөз сурәтен матурлау, зур заводлардан торган эшчеләр шәһәренә җан, җылы өрү өчен армый-талмый хезмәт итте. СССР сәнгать фондының иҗат бүлекчәсендә, «Камгэсэнергострой» берләшмәсенең архитектур-сәнгать бүлегендә, Чаллының бер районында – баш рәссам, шәһәр башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсендә баш рәссам булып эшләде. Көнне төнгә ялгап проектлар сызганда исә, күңелендә матур фәлсәфи образлар туды һәм рәссам аларны кәгазьдә гәүдәләндерергә ашыкты. Проектлар белән мавыгып яшәгәндә, зур күргәзмәләр үткәрергә вакыты җитенкерәмәгән, билгеле. Лаеклы ялга чыккач, рәссам С.Негъмәтовның бер-бер артлы шәхси экспозицияләре күренә башлады. Чаллы, Алабугада тамашачы хикмәтле бу кылкаләм остасының рәсемнәрен күрү бәхетенә ирешкән иде инде. Сентябрь ахырында исә Казаныбызның Ратуша бинасында Салават Негъмәтовның башкалада беренче шәхси күргәзмәсе ачылды.



Чаллыдагы производстволар, зур авызлы аждаһа сыман, халык массаларын йотып барган кебек, Чаллыда рәссам С.Негъмәтовның да серле рәсемнәре байтак еллар капчыкта яшеренеп яткан икән ләбаса! Бохара кояшында иркәләнеп, шәрык дөньясының матур төс-бизәкләрен күңеленә сеңдергән, мәһабәт Мәскәү каласында реализмнан башлап абстракционизмга кадәр бөтен иҗат агымнары белән танышкан милләттәшебезнең рәсемнәрендә хикмәт бар. Алар беренче караганда гына китап иллюстрацияләренә яки мәзәк рәсемнәр – карикатураларга охшаган кебек. Чынлыкта, күпләрендә якты юмор, җиңел сызымнар артында тирән фәлсәфә яшеренгән. Күзен кысып, елмаеп куйса, койган да куйган Хуҗа Насретдин ул үзе дә.

С.Негъмәтовның иҗат әсбаблары гап-гади кәгазь һәм каләм белән карадан гыйбарәт булса да, ул каләм очыннан рәсем җирлегенә нинди генә уй-фикерләр таммый. Җаны булган һәркем ир-ат һәм хатын-кыз, мәхәббәт темаларын читләтеп үтми. Салават Изад улының «Капма-каршылыкның берлеге», «Беренче караштан гашыйк булу», «Ачуланышканнар», «Тартылу» кебек рәсемнәрендә дә мәхәббәтнең җитмеш җиде төрле төсмерен күрергә мөмкин. Бохара пейзажлары тансык бер җылылык белән өретелгән һәм шәрык әкиятләрендәге әкияти сарайларны хәтерләтә. Рәссамның балачак хисләре әнә шулай әкияти бер самимилек белән гәүдәләндерелгән. Җылы якта үскән Негъмәткә салкын кышларга, яңгырлы, пычрак көзләргә ияләшү авыр булганын да рәсемнәреннән чамалавы бик җиңел. Шәрык базарының байлыгыннан, муллыгыннан, күптөслелегеннән соң рәссамның бер-берсенә охшаш соры төсле катлы-катлы йортлар арасында берникадәр югалыпкуырылып калганын да сизеп аласың. «Шәһәр һөҗүм итә» исемле рәсемендә, мәсәлән, сап-сары кырның һәр яктан һөҗүм иткән биек катлы йортлар камалышында калганын күреп, үзең дә шомланасың. Икенче рәсемендә зур тәрәзә янында тамашачыга арты белән бер кызчык моңланып утыра. Аның шулай утыруында, тәрәзә артындагы бер-берсен уздырырга теләгәндәй тезелгән биек катлы йортлар сурәтендә һәм тәрәзә төбендә үсеп утырган нәни кактусларда ниндидер киеренкелек бар сыман. Адәм баласы шәһәр цивилизациясе алдында шушы кызчык кебек бик бәләкәй һәм көчсез, дигән фикер килә. Шәһәрнең азмы-күпме җан җылысы саклаган үсемлекләре дә шушы әнәле кактуслар гына, дип тә уйлап куясың. С.Негъмәтнең бу әнәле гөлләргә багышланган «Кактуссыманнар» дип исемләнгән рәсемнәр шәлкеме 1990 елларда ук иҗат ителә башлап, шул елларданы халәтенең чагылышы булып тора. Рәсемнәрнең күплеге тормышында төшенке көннәрнең байтак булуын искәртә.

Икенче ир-балалары дөньяга аваз салгач, тумыштан авыру йөрәкле хатынын паралич суга. С.Негъмәтов сөекле кешесе-

ХИКМӘТЛЕ РӘСЕМНӘРЕ



нең көннәрен озынайтыр өчен җан-фәрман тырыша. Әммә... «Минем иптәш кызым Кадрия синең тормыш иптәшең булсын», – дип хатыны васыять әйтеп калдыра. Кадрия белән Салаватның тагын бер ир балалары дөньяга килә. Кадрия ханым улларын бердәй яратып-сөеп, үз итеп үстерә. Бүген С.Негъмәтнең һәр сүзендә хатынына мәхәббәте, баһадир уллары белән горурлануы сизелә.

Гаилә җанлы булуы рәсемнәреннән үк күренә. Авыл йорты янында сурәтләнгән яшь ир белән хатынны ике яктан җылытып, улы белән чәчләренә ак ленталар үргән кызы басып тора. Дөньялары түгәрәк, барыр юллары кызчык чәчендәге ак ленталар кебек ак. Рәссамның иҗатында гаилә темасы милли тамырларга багышланган сурәтләр белән бербөтен тәшкил итә. Биек, нәфис манаралы мәчет рәсемнәре, татар орнамент өлешләре милли-дини яшәешебезнең бер чагылышы булып, милләттәшләребезнең күңелен җылыта. Шулар арасында «Аксакаллар» рәсеме игътибарга лаек. Биредә кылкаләм остасының гомумиләштерү, композиция кору, аз сызымнар, кысыр чаралар белән тирән мәгънәне күрсәтеп бирү таланты ап-ачык күренә. Өч аксакалның башы рәсем зурлыгында сурәтләнгән. Ак сакаллары да бар, билгеле. Әммә сакалларыннан бигрәк, рәсемнең уңышы – композициянең корылышында. Йөзьяшәр картларның башлары болытларга тиеп торган биек тауларны хәтерләтә. Авторның мәһабәт таулар ничә яшьтә булса, бу аксакаллар да шуныңча яшәп, белем-тәҗрибә туплаган, дип ассызыклыйсы килгән сыман. Җирдәге яшәү һәм мәңгелекнең асылын ачкан тагын бер рәсемдә йортын, машинасын калдырып китәргә теләмичә, аларга таба кулын сузган җирдән кубарылып очып баручы ак шәүлә күрәбез. Байлык – бер көнлек, рух мәңгелек, дигән фикерне рәссам бик бәләкәй булып калган йорт сурәте аша әйтеп биргән...

Казанга күчеп килү турында Салават Негъмәтов күптәннән хыялланган була. Биредә башка рәссамнар белән бер казанда кайнау, күргәзмәләрдә катнашу, бер-берсенең сулышын тоеп иҗат итү теләге тарта аны. Ниһаять, Татарстан Рәссамнар берлегеннән остаханә алуга ирешеп, ул хыялын тормышка ашырды дияргә була. Остаханәсе Попов урамында матур җирдә урнашкан. Күршедә генә – тыңгы белмәс рәссам Мөдәррис Минһаҗев. Остаханәгә урнашканына әле санаулы гына көннәр, шуңа да карамастан киштәләр куеп, су җылыткыч, душ көйләп, иҗат бүлмәсен гөл иткән. Рәссамның кулы эшкә ятып тора. Эшләп арыгач, күршесе Мөдәррис белән баллап, майлап чәй эчкәндә, пленэрга баруларын искә төшерәләр. Татарстан рәссамнар берлегенең пленэрлар саны иллегә җиткән. Мөдәррис белән Салават шул пленэрлар аша якыннан танышып һәм дуслашып киткән дә инде. М.Минһаҗев Чаллы егетенең җиңел сөякле, эшкә батыр, көр күңелле, ачык чырайлы булуына игътибар иткән һәм үзе моннан берничә ел элек Бөгелмәдән күчеп килгән рәссам буларак, Негъмәтнең Казанга килүе өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләгән. Мөдәрриснең җитмешне тутырып килгәненә, Салаватның җитмеш бишкә якынлашуына кем ышансын? Шундый зур кала араларын да чүпкә дә санамыйча, Казаныбызга тартылучы, Ратуша бинасын тутырып күргәзмә оештыручы егетләребез булганда, рәсем сәнгатебез гөрлиячәк әле!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.



Министр кулыннан бүләк

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин «Авыл укытучысы» һөнәри осталык конкурсында җиңүчеләргә бүләкләр тапшырды.

Конкурс Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан «Мәгариф» журналы редакциясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы Республика иҗтимагый фонды белән берлектә, иҗади үзешчәнлекне тәрбияләү, педагогик хезмәткәрләрнең алдынгы инновацияләренә омтылыш, авыл укытучыларының абруен күтәрү максатында үткәрелә.

Җиңүчеләр һәм призерлар исемлеге

1 урын – Балык Бистәсе районы Яңа Арыш урта мәктәбенең физика, информатика укытучысы **Нәбиуллин Руслан Дамир улы;**

2 урын – Биектау районы Әлдермеш урта мәктәбенең биология укытучысы **Сабирова Гөлназ Мансур кызы**;

3 урын – Аксубай районы Иске Ибрай урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Сөләйманов Рамил Хафиз улы** һәм Питрәч районы Татар Тау иле урта мәктәбенең биология укытучысы **Җиһаншина Зөлфия Равил кызы.**

Номинацияләрдә җиңүчеләр

«Җиңүгә омтылыш» – Баруди исемендәге 4 нче Биектау урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Хәлилова Гөлнар Мансур кызы;**

«Нәтиҗәле иҗади эшчәнлек өчен» – Сәләтле балалар өчен Актаныш гуманитар гимназия-интернатының татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Шәрипова Чулпан Рәмзил кызы;**

«Үзе укыткан предметка мәхәббәт» – Әлмәт районы Минлебай урта мәктәбенең инглиз теле укытучысы **Әхмәтзаһирова Гүзәл Мөкатдәс кызы;**

«Тема тирәнлеге өчен» – Арча районы Шушмабаш урта мәктәбенең биология һәм география укытучысы **Һадиева Рүзилә Рәфыйк кызы;**

Тәрбиячеләр арасында

«Туган телгә мәхәббәт» номинациясендә - 3 нче номерлы Актаныш балалар бакчасы тәрбиячесе **Шакирова Әлфирә Индус кызы;**

«Балалар сәламәт булсын» номинациясендә – Балтачның 5 нче балалар бакчасы тәрбиячесе **Закирова Гөлназ Нурулла кызы;**

«Мактаулы остаз» күкрәк билгесе, хезмәт ветераны, Биектау районының легендар математика укытучысы **Афанасьева Флера Васильевнага** тапшырылды.

«Шәйморатов» романын – зур бүләккә!

Әсәрләре Мәскәү нәшриятларында һәм журналларында, шулай ук чит илләрдә дөнья күргән күренекле башкорт язучысы Флүр Галимовның “Генерал Шәйморатов” дип аталган тарихи романы “Агизел” журналында басылып чыкканнан соң, республикабызның төрле төбәкләрендә бу күләмле әсәр буенча матур әдәби чаралар үтте. Стәрлетамак шәһәренең башкорт-татар әдәбияты үзәгендә дә Ф.Галимовның яңа романы буенча китап укучылар конференциясе булып узды. Анда әдип үзе һәм, кунак буларак, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Зәки Әлибаев та катнашты.

Флүр Миншәриф улы киңкатлам укучыларга күптән таныш автор. Аның “Яңа башкорт” романы киң танылган иде. Моңача булмаган әдәби алым белән әлегәчә күтәрелмәгән тема – бизнес, һәм шулай ук, безнең әдәбиятта әлегә сурәтләнмәгән яңа герой – башкорт эшкуарының базар шартларына яраклаша алу-алмавы турында язган ул. Язучының аннан соң басылган “Азгын тәүбәсе” трилогиясе адәм баласының фәлсәфи эзләнүләрен һәм рухи ачышларын, иҗади азатлыкка омтылу мәсьәләләрен күтәреп чыккан иде. Россиядә һәм чит илләрдә тугыз тапкыр басылып чыккан бу трилогиядә бөтен дөнья тарихы чагылдырылган: анда җәннәт бакчасында яшәгән Адәм белән Һава да бар (ягъни, дөньяның башы), башка дәверләр дә һәм хәтта ахырзаман да сурәтләнгән. Бу әсәрдә якты дөньяның иң зур серләренең берсе – яшәү мәгънәсе дә ачып бирелгән… Һәм менә тагын яңа юнәлеш – тарихи роман жанрына да тотынырга җөрьәт иткән әлеге язучы.

112 нче Башкорт атлы дивизиясе командиры, Россия Герое, генерал Миңнегали Шәйморатов турындагы романын язганда авторның Икенче Бөтендөнья һәм Бөек Ватан сугышы темасын төптән өйрәнгән булуы сокландыра. “Аны иҗат итүгә төп этәргеч – Бөек Ватан сугышында Туган илебез һәм киләчәк буыннар өчен җаннарын фида кылган ата-бабаларыбызның рухлары алдында безнең буынның һәм үземнең зур бурычымны тану булды”, – ди Ф.Галимов үзе.

Роман турында фикерләрен китапханә мөдире Гүзәл Ишбулдина да, БДУның Стәрлетамак филиалы студентлары Урал Таһиров һәм Элина Мусина, “Агинәйләр” оешмасы әгъзасы Гөлшат Кәлимуллина да җиткерде. Чынлап та, роман үзәгендә торган шәхес Миңнегали Шәймоpатовка да сокланып, горурланып туйгысыз! Роман безгә легендар генералны да, тарихи фактларны да әдәби нечкәлекләр аша күз алдына бастырырга ярдәм итә. Миңнегали бала чактан ук бик чос булган, тугыз яшендә ятим калгач, хәзерге Кырмыскалы районының Шәйморат (ул чакта Биштәкә) авылы баеның атларын көтә башлаган. Аның үтә дә сәләтле булуы шул вакытта ук беленгән. Бәләкәй генә килеш гармунда уйнарга өйрәнеп алган малайның ничек атларны тыңлатуын авылдашлары башта аңлый алмый азапланган, ниндидер сихри көч белән алар үзләре утлауга чыга да, кичен кире байның ихатасына әйләнеп кайта! Соңыннан гына бу могҗизаның асылына төшенгәннәр, Миңнегали аларны билгеле бер көй уйнаганда яланга чыгарга, икенче көйгә туплауга төшәргә, өченче бер көйне яңгыратса, кайтырга өйрәтеп алган икән! Рәхәтләнеп гармунда уйнап утырып кына ат көткән. Шулай, бәләкәйдән шук та, башлы да булган киләчәктә танылачак разведчик, полководец һәм данлыклы генерал Шәйморатов…

Ә бит полковник М.Шәйморатов җитәкчелегендәге 112 нче Башкорт атлы дивизиясе исәпсез-сансыз җиңелүләрдән соң совет гаскәрләрендә төшенкелек, хәтта паника хөкем сөргән чорда яуга керә. Әйе, СССР буенча 46 милли часть, шул исәптән, 19 кавалерия дивизиясе төзелгән була. Араларыннан бер 112 нче дивизия генә бу чаклы дан казана. Ә башка милли дивизияләрнең күбесе тәүге алышта ук кырылып бетеп, байтаклары әсир төшеп, калганнарын таркатырга туры килә…

Ниһаять, Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршылаган вакытта романның төп герое М.Шәйморатовка Россия Герое исеме бирелде. Әйе, батыр үзе үлсә дә даны кала. Халык шагыйре Кадим Аралбайның шундый шигъри юллары бар: “Җитмеш биш ел көтү / кирәк булган!.. / Көттек халык таңы атарын. / Көтеп алды халкым төп Указны: / “Шәйморатов – Россия батыры!”

Конференциядә Ф.Галимовның “Генерал Шәйморатов” романын Стәрлетамак язучылар оешмасы исеменнән драматург Хәмит Иргалин яклап чыкты:

– Флүр Галимовның бу романы Башкортстан Республикасының иң зур бәһасенә – Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясенә лаек!

Шушы ук фикергә шәһәр мәдәният бүлеге башлыгы Зөфәр Зиннәтуллин, Стәрлетамак башкортлары корылтае рәисе Ләйсән Йосыпова да кушылды.

Китап укучылар конференциясен Башкортстан Язучылар берлеге рәисе, филология фәннәре кандидаты Зәки Әлибаев йомгаклады. Ул оештырылган чараны югары бәһаләде, Ф.Галимов әсәренә төпле, җитди анализ бирүләре өчен студентларга, аларның гыйльми җитәкчесе Рәйсә Илешевага рәхмәтләрен җиткерде, стәрлетамаклыларның әдәбият белән кызыксынып яшәвенә сокылануын да белдерде. “Флүр Галимов соңгы елларда генерал Шәйморатов һәм 112 нче Башкорт атлы дивизиясенә багышлап бик күп көч түкте: “Генерал Шәйморатов” романын, шул исемдәге пьеса һәм либретто, янә “Данлыклы 112нче” дигән киносценарий да язды. Язучының зур хезмәте дөрес бәяләнер”, – дип тәмамлады чыгышын Зәки Әлибаев.

...Халкыбызның бөек улы Миңнегали Шәйморатов дивизиясе туган илдә тынычлык өчен Доннан Эльбага кадәр мең чакрым җир үтә. Шәйморатовның каһарманлыгы озак еллар тиешле һәм гадел бәһаләнмәсә дә, халык үз батырын бервакытта да онытмады, бүген дә ул утта янмас, суда батмас милли батырыбыз булып күңелләребездә яшәвен дәвам итә.

Римма ГАЛИМОВА,
шагыйрә,
Стәрлетамак язучылар
оешмасы җитәкчесе.

ҖЫЛЫ ИҖАТ

Соңгы ярты гасырда татар драматургиясе һәм театрын пьесалары, сәнгать осталары турындагы китаплары, очерк-истәлекләре, фәнни һәм тәнкыйди мәкаләләре белән баеткан шәхесләрнең берсе – Юныс Сафиуллин. Аның тормыш һәм иҗат юлы башкалардан әллә ни аерылмаса да, үз эшенә бирелгәнлек, халкыбыз өчен кирәклеген аңлап хезмәт кую үрнәге булып тора.

Юныс Габдулла улы 1947 елның 18 октябрендә Яшел Үзән районы Бакырчы авылында дөньяга килә. Мәктәп елларында шигырьләр яза, аларның район һәм республика матбугатында басылуы яшүсмергә рухи көч, ышаныч бирә. Җыр-биюгә осталыгы аны сәхнәгә тарта. Күршедәге Акъегет сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, Казан театр училищесына укырга кергәч, Ю.Сафиуллин баш-аягы белән театр дөньясына “чума”: танылган остазларыннан белем алу белән бергә, драматургия һәм театр тарихын өйрәнә, Камал театры спектакльләрендә катнаша. Армия хезмәтен үтеп кайткач, 1969 елдан Кучмә театрда (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) артист булып эшли. Шул елларда А.В.Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы икееллык Югары режиссёрлар курсында белем ала. Ә инде 1981 елдан иҗади тормышы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры белән бәйле. Ул М.Кәримнең “Айгөл иле”, И.Юзеевнең “Бөркетләр кыяга оялый”, “Бәхетемнән узып барышлый”, А.Гыйләҗевнең “Син дөньяда берәү генә”, Т.Миңнуллинның “Уйланыр чак”, “Китәр юлың еракмы?”, “Үзебез сайлаган язмыш” һ.б. пьесалар буенча куелган спектакльләрдә төрле рольләрдә уйный, белгечләрнең уңай бәясенә лаек була.

Ю.Сафиуллин алдагы иҗат юлын драматургия белән бәйли. Аның “Менә без дә үсеп життек”(1983), “Пар канат”(1997), “Әллә өйләнергә инде?” (2004) җыентыкларында чыккан пьесалары буенча дәүләт һәм халык театрларында куелган спектакльләре зур уңыш казана. Ә инде “Әллә өйләнергә инде?”, “Алмазбулат”, “Пар канат”, “Идегәй”, “Йөзек һәм хәнҗәр”, “Йосыф һәм Зөләйха”, “Акмулла” кебек әсәрләре буенча куелган спектакльләр мәдәни вакыйга төсен алып, тәнкыйтьчеләрнең (И.Илялова, Н.Ханзафаров, Б.Поюровский, М.Сәлимҗанов, А.Әхмәдуллин, Д.Гыймранова, С.Поварисов, Ф.Галимуллин, А.Гыйләҗев, В.Шамсулин, Р.Игъламов, А.Габәши һ.б.) югары бәясенә лаек була.

Ю.Сафиуллин драматургиягә килгән 1970 еллар башында татар сәхнә әдәбияты алдагы унъеллыкка хас сан һәм сыйфат үзгәрешен дәвам итә. Билгеле булганча, “Хрущев җепшеклеге” йогынтысында әдәбият, шул исәптән драматургия яңа бер баскычка күтәрелә. Актив иҗатта булган Н.Исәнбәт, Ю.Әминев, М.Әмир, Ә.Баян һ.б. янәшәсендә Х.Вахит, А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Ш.Хөсәенов кебек талантлар үсеп чыга, бераздан аларга Р.Батулла, Р.Хәмид, Р.Мингалим, Ә.Гаффар һ.б. килеп кушыла. XX гасырның 60 елларында сәхнә әдәбияты халык тормышына якыная, ясалмалылыктан арындырылган заман герое мәйданга чыга. Моңа кадәр өстенлек иткән реалистик сурәтлелек янына җете буяуларга бай романтик әсәрләр (И.Юзеев, Ә.Баян пьесалары) килеп кушыла. Г.Камал, М.Фәйзи, К.Тинчуриннар традициясенә таянып, чорның җитди каршылыкларын чагылдырган, яңа сурәт чаралары урын алган заманча пьесалар языла. Шуның белән бергә, драматургия система идеологиясенең кыршауларыннан котыла алмый. Бу елларда вак, тар мәсьәләләр белән мавыгу, бер каптырмалы конфликтлар корып, аларның партия җитәкчелегендә хәл ителүе кебек эчпошыргыч, сәхнәдән тиз төшүче әсәрләр күпләп языла. Сәхнә закончалыкларын яхшы белгән Ю.Сафиуллин, драматургия традицияләрен өйрәнү аша, беренче иҗат тәҗрибәләре ясый. Яшь авторның “Ур-тура, сатирик” (1970), “Буйдак ир һәм танышлары” (1970), “Әллә өйләнергә инде” (1972), “Менә без дә үсеп җиттек” (1972) пьесалары комедия жанрына карый. XX йөз башы классиклары кебек үк, татарлар тормышындагы каршылык-кимчелекләрне көлү алымнары аша фаш итүгә килә. “Ур-тура, сатирик” пьесасы әдәбият-сәнгатьнең партия номенклатурасына буйсындырылуына әрнеп язылган. Шартлылык алымнары ярдәмендә кеше шәхесе, аның ирек мәсьәләләре җитди яңгыраш ала. Шул ук вакытта партия-совет органнарында эшләүчеләрнең халык мәнфәгате турында кайгыртуының төрле өндәү-лозунглар, киләчәктә матур, бәхетле тормыш вәгъдә итү белән чикләнүен, язучыларның да шуны пропагандаларга мәҗбүр булуын ачып сала. Әсәр герое Өйрәтүче болай ди: “Язучы ул – солдат! Солдат уйламый! Солдат күрәшә!” Пьесада кеше һәм коллектив мөнәсәбәтен ачуга да киң урын бирелә. Халык мәнфәгатенә өстенлек бирелү күренеше артында кешене шәхси теләкләреннән баш тарттыру, өстән кушканны үтәп яшәүгә күнектерү теләге ята. Автор моны үзенең Герое мисалында ача. Әлеге Герой хәмер белән мавыга башлагач, коллектив әгъзалары партия җитәкчелегендә аны дөрес юлга бастыра. Ул тырышып эшли. Моңа кадәр коллектив белән бергә балык тотарга йөрмәгән Герой бераздан “атказанган, орденга атланган халык балыкчысы” була. Чор каршылыкларын ачык тоемлаган драматург шартлы-фантастик күренешләр ярдәмендә яшәп килгән системаның бушлыгын, ялганга корылуын фаш итә.

Ю.Сафиуллин шул чорда язылган башка комедияләрендә дә язу стиленә тугры кала. “Буйдак ир һәм танышлары” комедиясендә ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтенең четерекле яклары аша яшәешкә тирән үтеп кергән әдәпсезлек, имансызлык күренешләренең сәбәпләре турында уйлана. Автор Г.Камал, И.Богданов, К.Тинчуриннардан килә торган “уен” алымына мөрәҗәгать итә. Төп герой Буйдак белән бәйле күренешләр Шекспирның “Отелло” трагедиясен сәхнәгә куярга әзерләнү белән үрелеп бара. Инглиз драматургы әсәрендәге котылгысыз фаҗигале мәхәббәт тарихы фонында түбән инстинктлар буенча эш кылучы хатын-кызларның мәгънәсез эш-гамәлләрен ачу халыкчан көлүнең бер чагылышы булып тора. Шуңа да автор яман күренешләрдән арыну юлын халыкның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен саклауда һәм яклауда күрә.

Драматургның XX йөз башы әдәбияты традицияләренә мөрәҗәгать итүе артында халыкның бүгенгесен һәм киләчәген кайгырту омтылышы ята. Монда нигез итеп гаиләне ала. Төрле буыннар арасындагы бәйләнеш аша гына татарны татар иткән әхлакый кыйммәтләрне саклап була дип саный ул. Шуңа да ир һәм хатын, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләренең каршылыклы яклары бер пьесасыннан икенчесенә көчәеп бара һәм төрле планда ачыла. Автор аны әсәрләренең исеменә дә чыгара. “Ләйсән ире Хәсән”, “Әллә өйләнергә инде” комедияләрендәге гаиләкөнкүреш вакыйгалары артында авторның яшәешебезгә тирән үтеп кергән бушлык, әдәпсезлек, вак мәнфәгатьләр белән мавыгу күренешләре өчен тирән әрнүе ята. Пьесаларда уңышлы кулланылган көлкеле ситуацияләр, мәкаль-әйтемнәр, гыйбарәләр, аеруча образ-детальләр (пешеп чыкмаган пилмән, тактасы купкан койма аша йөрү һ.б.), бер яктан, авторның Көлү эстетикасын чагылдыра, икенче яктан, бу эчпошыргыч мохитне кире кагып, үзгәрешләрнең котылгысызлыгын аңлата.

Сәнгати эзләнүләрен дәвам итеп, драматург драма жанрының да яңа мөмкинлекләрен ача. “Ни булган бу ирләргә?” (1979), “Нигез туздыручылар” (1986), “Пар канат” (1987) кебек пьесалары аның сәхнә закончалыкларын ныграк үзләштерүен, әдәби осталыгы арта баруын күрсәтә. Нәтиҗәдә әлеге әсәрләр озак еллар дәвамында төрле сәхнәләрдә уйнала, авторга киң танылу алып килә. Комедияләрендә кешеләр характерындагы кимчелекләрне, җәмгыятьтәге мәгънәсезлекләрне фаш итү өчен көлү алымнарын уңышлы кулланса, драмаларында яшәеш каршылыкларын ачуның яңа юлларын эзли. Драматург тормышны ничек бар, шулай сурәтләргә алынып, экзистенциаль сурәтләнеккә килә. Сызлану фәлсәфәсенә нигезләнгән әлеге алым ярдәмендә газаплану тормышының төп хакыйкате кебек кабул ителә. Әсәрдә тормышның мәгънәсезлеге ачылып, аннан котылу мөмкин түгеллеге күрсәтелә, ул исә чарасызлыкка китерә. Ю.Сафиуллин үз геройларының мөстәкыйльлеген, һәрберсенең дөньяга үз карашы, үз мөнәсәбәте булуын таный. Әмма каршылыкларны хәл итү юлларын таба алмау, аерым геройларын әйләнә-тирә белән кискен каршылыкка китерә, сызлану, сыкрану хисе тудыра. “Ни булган бу ирләргә?” пьесасы җәмгыять таләбе буларак языла. Үткән гасырның 70-80 елларында җәмгыятьнең нигезе булган гаилә институты бик какшый башлый. Бу исә ир белән хатынның үзара мөнәсәбәте, тигез хокуклылыгы, җаваплылыгы мәсьәләсе буенча бәхәсләр артуга китерә. Аны хатын-кызларга бәйләп ачу омтылышлары белән бергә, ир-атның гаиләдәге, җәмгыятьтәге урынын өйрәнү дә игътибардан читтә калмый. Драматургиядә Р.Мингалимнең “Кайда сез, ирләр?”, Т.Миңнуллинның “Ир-егетләр” кебек әсәрләре языла.

(Дәвамы киләсе санда).

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ.

РЕДАКЦИЯДӘН. Каләмдәшебез Юныс Габдулла улы Сафиуллинны 75 яшьлек юбилее белән ихластан котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп калабыз.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

15 октябрь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
16 октябрь – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
18 октябрь – «Хуш, авылым!» (А.Җаббаров).
19 октябрь – Шәрык клубында 17.00 – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт). 19.00 – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
20 октябрь – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
21 октябрь – 17.00 Шәрык клубында «Яңа шимбәчеләр» клубы утырышында түгәрәк өстәл янында артист Фәнис Җиһанша белән очрашу. 19.00 «Килә ява, килә ява...» (З.Хәким).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

15 октябрь – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
16 октябрь – «Утка очкан күбәләктәй» (Н.Гыйматдинова әсәре, Т.Хәләф инсценировкасы).
18 октябрь – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
19 октябрь – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
20 октябрь – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
21 октябрь – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

19, 20 октябрь – Премьера. «Ромео һәм Джульетта» (У.Шекспир).
21 октябрь – «Микулай» (М.Гыйләҗев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

15 октябрь – зур залда – «Дюймовочка» (Г.-Х.Андерсен). Кече залда – «Әлфия» (И.Зәйниев).
16 октябрь – Фойеда – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина), зур залда – Сны Диснея» (И.Зәйниев), кече залда – «Су анасы» (Г.Тукай).
20 октябрь – 11.00, 13.00 – «Русалочка» (Г.-Х.Андерсен).
21 октябрь – 11.00, 13.00 – «Русалочка» (Г.-Х.Андерсен), 15.30 – Театр буенча сәяхәт.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

16 октябрь – 11.00 – «Конек-Горбунок» музыкаль әкияте. 17.00 – «Летучая мышь» опереттасы.
17 октябрь – Анна Павлованың балет дөньясы.
18 октябрь – Композитор Франц Шубертның 225 еллыгына багышланган концерт программасы.
19 октябрь – И.Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевидение бәйгесенең гала-концерты.
21 октябрь – Татарстан Республикасы филармониясе джаз оркесты концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

16 октябрь – А.Сладковский җитәкчелегендәге дәүләт симфоник оркестрына күренекле пианист Денис Мацуев кушылып уйный.
19 октябрь – «DEAT NOTE» мультсериалына багышланган симфоник концерт.
21 октябрь – Башкортстан Республикасының Линар Дәүләтбаев җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары милли оркестры концерты. Программада курай, кубыз, кыл-кубыз, домбра, ятаган һ.б. милли музыка уен коралларында башкарыла торган башкорт музыкасы, рус җырлары, заманча хитлар, джаз композицияләре.

Риза казый

Уфада Ризаэтдин Фәхретдингә бәйле

Ризаэтдин Фәхретдин (1859-1936) – бөек галим, тарихчы, педагог, шәркыят белгече, язучы, журналист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул, бөтен гомерен һәм көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган. Р.Фәхретдиннең үткен каләме беркайчан да кәгазьдән аерылмау сәбәпле, аның 142 китабы (өстәвенә, берничә дистәдән артыгы кульязма рәвешендә саклана), 800 ләп мәкаләсе һәм төрле характердагы язмалары басылып чыккан, шуңа күрә ул иң зур, күп һәм кыйммәтле язма мирас калдырган татар галиме булып санала һәм башка гыйлем ияләреннән бер баш өстен тора. Р.Фәхретдин төрле фән өлкәләрен яхшы белгән, шул исәптән эпиграфика тармагында да үзен чын белгеч буларак таныткан. Галим күп кенә борынгы кабер ташларын ачыклаган һәм үзенең мәшһүр «Асар» исемле күптомлы хезмәтендә аларның тулы текстларын теркәп калдырган. Р.Фәхретдиннең үзенә һәм якын туганнарына куелган кабер ташлары да тарихи-мәдәни кыйммәткә, фәнни әһәмияткә ия.

Мәгълүм булганча, Р.Фәхретдин Уфа шәһәренең борынгы мөселман зиратында җирләнгән. «Гофран» мәчете янында урнашкан әлеге каберлекне халык телендә Татар зираты дип тә йөртәләр. Ул XIX гасырның 30 нчы елларында барлыкка килгән. Бу каберстанның борынгы кабер ташлары әле һаман фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгәнлектән, хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча, сакланып калган бөтен татар ташъязма истәлекләрен барлау һәм өйрәнү өчен, 2021 елның май аенда Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан фәнни экспедиция оештырылды. Анда бу юллар авторы һәм тарихчы Сайрус Хәмидуллин катнашты һәм барлыгы 163 гарәп язулы борынгы кабер ташы табылды. Зиратны безгә хәтле өйрәнгән эпиграфист В.Усманов биредә бары тик 50 эпиграфик истәлек кенә ачыклый алган. Ниһаять, Уфа мөселман зираты эпиграфик планда тикшерелде, дип санарга тулы нигез бар. Анда мөфтиләрдән Габдессәлам Габдеррәхимов, Габделвахид Сөләйманов, Мөхәммәдьяр Солтанов, казый Гыйнаятулла Кабкаев, матбагачы Ильяс Борагани, тәрҗемәче Закир Ишмөхәммәдов, дин әһелләре Әхмәд бине Мәүлед, Исламгали бине Җиһанша, Хәйреддин Сөбханколов, Хәйрулла Госман, сәүдәгәрләр Гайфулла Госмани, Мөхәммәдкәрим Биглов, Мөхәммәдгәрәй Терегулов, Салих Еникиев, Сөләйман Дәүләткилдиев һ.б. мәшһүр шәхесләрнең ташбилгеләре табылды һәм өйрәнелде. Кызганычка каршы, барлык кабер ташларының фәнни тасвирламасын төзеп, аларның тулы каталогын бастырып чыгарырга җыенабыз. Шунысы кызганыч, вакыт узган саен, эпиграфик истәлекләребезнең саны кимегәннән-кими һәм без ачыклап өйрәнгән ташларның кайберләре берничә елдан инде бөтенләй табылмаска мөмкин. Хәзерге көндә зираттагы байтак кыйммәтле ташъязма истәлекләребез ауган, ватылган, җимерелгән, туфрак астында калган, агач чүпләре белән күмелгән. Шулай ук аларны саклау, консервация, реставрация эшләре һаман тиешле дәрәҗәдә башкарылмаган, хәтта Р.Фәхретдин кебек милләтебезнең йөзек кашлары булган шәхесләрнең кабер ташлары да дәүләт тарафыннан саклауга куелмаган.

Иң олуг галимебез Ризаэтдин хәзрәт 1891–1906 елларда Диния нәзарәтендә казый булып эшләгәндә һәм 1918 елдан алып гомеренең соңгы көннәренәчә кабат казый һәм мөфти булып торганда, Уфада яшәгән һәм шунда вафат булган. Үпкәсенә салкын тиеп, ул 3-4 атна урын өстендә авырып яткан. Әлмәт районы Кичүчат авылында урнашкан Ризаэтдин Фәхретдин мемориаль музее фондларында Р.Фәхретдин килене Зәйнәпнең (улы Габдрахманның икенче хатыны) 1936 елның 29 мартында аның кызы Зәйнәпкә язылган бер хаты саклана. Анда галимнең температурасы гел югары булуы, бик каты ябыгуы искәртелгән: «Әткәйнең эссělеге гел кич берлә 38,3, иртә берлә 37 дән күтәренке буладыр иде, кичә кич берлә 38,2. Бүген иртә берлә нормальный, кич берлә 37,8 булган... Бик ябыккан бичаракай. Артык ябыгу сәбәпле, тешләрен дә куя алмый икән...». 1936 елның 15 мартында язылган васыятендә ул үзен җирләргә хезмәттәше, дусты казый Кәшшафетдин Тәрҗеманига, ә җеназа намазын укырга Уфа мәчете имам-хатыйбы ахун Җиһангир Абызгилдингә кушкан. Шул сәбәпле, К.Тәрҗемани үз куллары белән галимнең җәсәден ләхеткә төшереп урнаштырган, шулай ук күмү мәрасимнәрен үткәргән. Р.Фәхретдиннең каберенә известьташтан эшләнгән артык зур булмаган бер ташбилге куелган һәм анда түбәндәге сүзләр уеп язылган:

1) «Һәзәл-мәркад-
2) -үш-шәйхыйль-гаалим-
3) -ил-фәдыйли мөфти
4) Ризаэддин
5) бине Фәхреддин
6) түвуффийә мөхәррәм 20
7) 1355 сәнә һиҗри»

Татар теленә тәрҗемәсе: «Бу – шәех, хөрмәтле галим, мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин кабере, һиҗри 1355 елның 20 мөхәррәмендә вафат».

Әлеге таш текстының укылышын беренчеләрдән булып В.Усманов тәкъдим иткән, тик ни өчендер «түвуффийә» сүзен «тәвәффа», «мөхәррәм» сүзен «мәрхүм» дип биргән, ә соңгы юлын тулысынча укымыйча калдырган.

Р.Фәхретдин кабере зиратның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан, ташның эпитафиясе гарәп графикасында һәм телендә язылган, үлү датасы да һиҗри ел исәбе белән күрсәтелгән. Аның якыннары, дуслары һәм шәкертләре кабер ташына бик күп мактаулы сүзләр, төрле эпитетларга бай гыйбарәләр яза алган булыр иде, әмма галимнең тыйнаклыгын, карашларын бик яхшы белгәннәр. Ул үзенең бер мәкаләсендә ташларга ничек һәм нәрсә язылырга тиеш икәнлеген ап-ачык рәвештә язып калдырган: «Кабер ташлары нотык һәм хөтбәләр язылачак дәфтәрләр, матур язу үрнәге һәм инша язылачак кара тактадар түгел. Шуның өчен вафат булучының исеме, гаилә һәм фамилиясе дөрес язылу, туу һәм вафат көннәре хатасыз теркәлү җитә». Шулай да, каберенә килгән кешеләр галимне башка гади кешеләр белән бутамасын өчен, аның исеменә «шәех, хөрмәтле галим, мөфти» дип өстәргә мәҗбүр булганнар, чөнки зиратта аның адашлары да җирләнгән булырга мөмкин. Аның каруы шушы дүрт сүз дә Р.Фәхретдин турында бик күп нәрсә сөйли, аның җәмгыятьтә иң изге, хөрмәтле һәм югары дәрәҗәгә ирешкән шәхес булуын күрсәтә.

Әгәр башка дин галимнәренең һәм мөфтиләрнең кабер ташларына күз салсак, күбесендә чагыштырмача шактый күп мәгълүмат, хикмәтле сүзләр, шигырьләр, Коръән аятьләре, хәдисләр, догалар язылганлыгын күрә алабыз. Р.Фәхретдин исә ташларга кабер иясе хакында кыскача мәгълүматтан тыш башка нәрсә язуны өнәмәгән, бу эштә малны кирәкмәгәнгә исраф итүдән сакланырга чакырган. Шул сәбәпле, аның кабер ташы башка мөфтиләрнең ташларыннан кечкенә үлчәмнәре һәм кыска гына эпитафик текст язылуы белән аерылып тора. Казанның Яңа Татар бистәсе зиратына җирләнгән мөфти Галимҗан Барудиның ташындагы текст Р.Фәхретдиннекенә охшаш, тик, аннан аермалы буларак, Г.Барудиның ташбилгесенә гарәпчә «рахимәһүмә-ллаһү рахмәтән вәсигаһ» («Аллаһ аларның икесен дә киң рәхмәте белән рәхим кылсын») догасы өстәлгән һәм эпитафиясе яртылаш гарәп, яртылаш татар телендә язылган.

каберлеге

эпиграфик истәлекләр

Дөрес, Р.Фәхретдин вафат булган вакыт бик дәһшәтле чорга туры килгән һәм, матур дини текстлар язып, купшы ташлар кую мөмкинлеге булмаган. Әмма андый мөмкинлек булса да, ул үзенең каберенә затлы, кыйммәтле таш куюны барыбер хупламас иде, чөнки галим үзенең улларына да гади итеп эшләнгән ташлар куйдырган. Мәгълүм ки, аның Хәсән исемле ике улы булып, алар бик яшьли бакыйлыкка күчкәннәр. Р.Фәхретдин үзен балаларының каберләре янына җирләргә васыять итеп әйткән һәм Диния нәзарәте ишегалдындагы башка мөфтиләр күмелгән урынга җирләмәскә кушкан. 1899 елда вафат булган Хәсәннең известьташтан эшләнгән ташбилгесендә түбәндәге сүзләр уелган:

Алгы ягы:

1) «Хәсән бине Ризаэддин
2) бине Фәхреддин түвүффийә
3) фии 16 шәһри рамәданә
4) гаами 1316 вә һүвә
5) ибнү 14 әшһүр».

Хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: «Хәсән бине Ризаэддин бине Фәхреддин [һиҗри] 1316 елның 16 рамазанында 14 айлык вакытта вафат булды».

Үлчәмнәре: 72х35х15.

Галим үзе белдергәнчә, Хәсән 1897 елның 25 ноябрендә (һиҗри 1315 елның 12 рәҗәбендә) сишәмбе көн көндезге сәгать 2 дә туган, 1899 елның 16 гыйнварында шимбә көн үлгән. Уфа шәһәре метрика кенәгәсендә аның шул елның 17 гыйнварында кызылча авыруыннан мәңгелек дөньяга күчүе турында язылган. Хәсәнне соңгы юлга озаткан мулла аның үлү датасы итеп күмелү көнен күрсәткән булса кирәк.

Р.Фәхретдин үзенең 1901 елның 5 сентябрендә (һиҗри 1319 елның 7 җөмадиәл-ахирендә) чәршәмбе көн Уфада туган улына тагын Хәсән дип исем биргән, тик, кызганычка каршы, анысы да 1902 елның 17 апрелендә чәршәмбе, төнге сәгать бердә, җиде-сигез айлык вакытта вафат булган. Метрика кенәгәсендә аның эпилепсия авыруыннан үлгәнлеге хакында язылган. Икенче Хәсәннең ташындагы эпитафия нәкъ беренчесенеке кебек формада һәм эчтәлектә, фәкать даталары гына башкача:

Алгы ягы:

1) «Хәсән бине Ризаэддин
2) бине Фәхреддин түвүффийә фи
3) 14 мүхәррами гами
4) 1320 вә һүвә ибнү
5) 8 әшһүр».

Хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: «Хәсән бине Ризаэддин бине Фәхреддин [һиҗри] 1320 елның 14 мөхәррәмендә 8 айлык вакытта вафат булды».

Шулай ук известьташтан эшләнгән бу ташның беренче өч юлын заманында эпиграфист В.Усманов укыган, ләкин соңгы ике юлы аның тарафыннан, җир астында калган булганга, бөтенләй бирелмәгән, шулай ук әлеге эпиграфист «түвүффийә» сүзен инде бу очракта «тәвәффи» дип тәкъдим иткән.

Ике Хәсәннең каберләре бер ихата эчендә булган. Аларның ташларын аталары үзе яздырып куйган. Эпитафияләрдә бер генә артык сүз дә юк, фәкать кабер ияләре хакында төп мәгълүмат кына китерелгән. Р.Фәхретдин гади халыкны эпитафик текстларны гарәп телендә түгел, ә төрки телдә язарга чакырган, чөнки гарәп телендә язылган бик күп эпитафияләр элек хаталар белән тулган. Әмма үзе бу киңәшен тотмаган, чөнки моңа зарурлык булмаган: галим гарәп телен үз ана телендәй белгән һәм гарәп җөмләләрен язганда беркайчан да хата җибәрмәгән. Бәлки, Ризаэтдин хәзрәт эпитафияләрне гарәпчә язуда Ш.Мәрҗанигә ияргә теләгәндер, чөнки ул да үзенең бөтен якыннарының кабер ташларын фәкать шул телдә һәм һиҗри ел исәбе белән яздырган. Мәрҗани моны: «Һиҗри ел исәбе – сәхабәләрнең үзара килешүләре белән мөселманнар өчен һәртөрле мөгамәләләрендә тотуны һәм гамәлдә куллануны тиешле күргән ел исәбе», – дип аңлаткан. Р.Фәхретдин дә, гәрчә, Мәрҗанидән аермалы буларак, хезмәтләрендә миладе ел исәбен кулланса да, улларының үлү датларын һиҗри ел белән күрсәткән. Ризаэтдин хәзрәтнең кабер ташын да якыннары нәкъ газиз улларының ташлары кебек яздырган һәм тышкы ягы белән дә алар бер-берсе белән бик охшаш.

Уфа зиратында Р.Фәхретдиннең 1944 елда вафат булган Сәгыйдь һәм 1953 елда үлгән Габдеррәшид исемле улларының кабер ташлары да сакланган, тик аларның текстлары ни сәбәпледер русча язылган. Сәгыйдь 1900 елның 13 февралендә (һиҗри 1317 елның 24 шәүвәлендә) Уфада туган. Ул башта мәдрәсәдә, аннан соң Оренбург реаль училищесында, Ленинград урман техник академиясендә укыган, соңыннан урман сәнәгате өлкәсендә инженер булып эшләгән. Сәгыйдь, үпкәсенә салкын тиеп, 44 яшендә гүр иясе булган һәм атасыныкыннан соң бер кабер аша җирләнгән. Габдеррәшид исә 1892 елның 22 гыйнварында (һиҗри 1309 елның 4 рәҗәбендә) чәршәмбе көн хәзерге Зәй районы Чыбыклы (Чубытлы) авылында дөньяга килгән. Ул «Хөсәения» мәдрәсәсендә, Оренбург реаль училищесында, Пермь университетында гыйлем алган, соңра, фән юлын сайлап, төрле уку йортларында математика фәнен укыткан, озак еллар Уфа авиация техникумында эшләгән, дәреслекләр язган. Йөрәк өянәге тотып, Габдеррәшид 1953 елда вафат булган һәм нәкъ атасы янына җирләнгән.

1990 нчы еллар башында галимнең каберенә тексты кириллица белән язылган икенче бер яңа таш та куелды. Күптән түгел Р.Фәхретдиннең һәм аның өч улының (Хәсән, Хәсән, Габдеррәшид) кабер ташлары «Татнефть» гамәви акционерлык җәмгыяте ярдәме белән реставрацияләнде һәм 2022 елның 26 маенда аларның каберләре өстендә мемориаль комплекс ачылды. Әлеге проектның авторы һәм скульпторы – Искәндәр Биишев, ә инициаторы – Ризаэтдин Фәхретдин мемориаль музее мөдире Диләрә Гыймранова. Р.Фәхретдин улы Габдеррәшиднең кабер ташы, атасыныкы белән рәттән торганга һәм берничә җирдән сынганга күрә, шушы проект кысаларында яңа ташка алыштырылды һәм анда гарәп графикасында түбәндәге сүзләр язылды:

1) «Мөгаллим
2) Габдеррәшид
3) бине Ризаэддин
4) 1892 – 1953».

Моңа кадәр галимнең Кичүчат авылы зиратында җирләнгән ата-анасы Фәхретдин хәзрәт һәм Мәүһүбә абыстай, үги анасы Маһиҗиһан абыстай, энесе Зыятдин каберләре Ризаэтдин Фәхретдин мемориаль музее хезмәткәрләре тарафыннан тәртипкә китерелеп, алар 2006 елда таш һәм тимер койма белән әйләндереп алынган иде. Эпиграфик экспедициябез вакытында барысының да ташбилгеләре өйрәнелде һәм болардан тыш шул ук авылда Р.Фәхретдиннең бабасы Сәйфетдин хәзрәт һәм әбисе Хәдичә абыстайның кабер ташы да табылды. Шунысын әйтергә кирәк ки, Фәхретдин хәзрәтнең ташбилгесенә гарәп телендә озын эпитафия язылган: вафат булу хакында төп мәгълүматтан тыш «әгузе-бисмилла», Коръән аяте, догалар, хикмәтле сүзләр язылган, әмма аларны Р.Фәхретдин түгел, ә аның энесе Минһаҗетдин үз куллары белән язган, чөнки ул бик маһир ташка язу остасы булган.

Уфа мөселман зиратында Р.Фәхретдиннең үзенә һәм аның якын туганнарына куелган кабер ташлары гаять кыйммәтле тарихи-мәдәни истәлекләр булып саналсалар, алар әле һаман галимнәр тарафыннан тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән һәм ташларының тулы текстлары фәнни әйләнешкә кертелмәгән иде. Экспедициябез вакытында бөек галимебез белән бәйле барлык ташбилгеләр өйрәнелде. Күргәнебезчә, ул балаларына гади итеп эшләнгән ташлар куйган һәм аларга гарәп телендә кабер ияләренең исемнәрен, аталарының исемен, һиҗри ел исәбе белән үлү даталарын һәм яшьләрен генә яздырган. Р.Фәхретдин заманында кайбер кешеләр, бер-берсен уздырырга теләп, туганнарына бик кыйммәтле һәм затлы кабер ташларын куюда ярышкан, хәзерге көндә дә андый ямьсез күренешләрне күзәтергә мөмкин. Ләкин галимебез, сүзләр белән генә чикләнмичә, гамәлләре белән дә һәр эштә тыйнаклыкка өндәгән. Үзенең кабер ташы да башка олуг галимнәр һәм мөфтиләрнекеннән гадилеге белән аерылып тора.

Айдар ГАЙНЕТДИНОВ,
филология фәннәре кандидаты.

Айга карап (кырын карама)

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

15 октябрь (шимбә). ***Рабигүл әүвәл аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,18.50 сәгатьтә калка, 14.04 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.30 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Чикләвекле бал

Югары кан басымын төшерү өчен, 1аш кашыгы әстерхан чикләвеге төшен термоска салып, өстенә 1 стакан кайнар су коялар, төнгелеккә калдыралар. Иртән сөзеп, 1 аш кашыгы бал кушалар да, өчкә бүлеп, көн буена эчеп бетерәләр. Берничә көн шулай дәвалангannan соң, кан басымы төшә башлый. Көн саен балга манып 3-4 чикләвек ашау да файдалы. Кишер орлыгын төеп, шуның 100 граммын ярты литр сөттә 15 минут пешерәләр: көненә 1 тапкыр 1 әр стакан эчү шулай ук кан басымын нормага китерә.

16 октябрь (якшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 20 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,19.40 сәгатьтә калка, 14.44 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.26 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Холециститтан – каен яфрагы

Үт куыгы ялкынсынганда,болай дәваланып була. 5 данә каен яфрагын 200 г кайнар суга салып, төнгелеккә калдыралар. Икенче көнне шуны өчкә бүлеп (ашар алдыннан) эчеп бетерәләр. Көн саен 1 әр каен яфрагы өсти барып, 25 данәгә җиткерәләр, аннары кабат 5 кә калганчы берәмтекләп киметәләр. Мондый төнәтмә бавырны бик шәп чистарта.

17 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 21 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,20.44 сәгатьтә калка, 15.11 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.21 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

18 октябрь (сишәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 22 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 21.59 сәгатьтә калка, 15.29 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.17 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Суганлы сөт

Салкын тигәндә, уртача зурлыктагы 1 баш суганны ваклап, өстенә кайнап торган 250-350 грамм сөт коялар. Җылы сөлгегә төреп, 20 минут төнәтәләр, аннан соң, болгатып, эчеп бетерәләр. Иртән эчсәң, урамга чыкмау хәерлерәк. Кич тагын бер тапкыр кабатласаң, иртән торганчы салкын тиюнең эзе дә калмаска мөмкин.

19 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Арыслан йолдызлыгында, 23.18 сәгатьтә калка, 15.44 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.13 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Дәфнә мае

Тез авыртканда, мондый май белән дәвалану файдалы. Каһвәтарткычта 6 данә дәфнә яфрагы, 1 чәй кашыгы артыш җиләген ваклатып, шуңа 120 грамм атланмай кушалар, яхшылап болгаталар. Суыткычта саклыйлар. Сызлаган буыннарга бик әйбәтләп ышкыйлар.

20 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 15.47 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.08 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Эремчек сихәте

Ашказаны-эчәк тракты авырулары кискенләшкән чорда төче эремчек ашарга кирәк. 1 литр сөтне кайнатып чыгарып, ут өстеннән алалар да, даруханәдә сатыла торган 1 чәй кашыгы кальций лактаты кушып болгаталар. Сөт әчеп төшә, аны иләккә салып, суын саркыталар. Эремчекне иртән ач карынга ашап бетерәләр. 1 атна буе шулай дәвалананалар.

21 октябрь (җомга). ***Рабигүл әүвәл аеның 25 нче көне.26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,0.39 сәгатьтә калка,15.50 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.03 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Суганлы кетчуп

5 кг помидор, 3-4 баш суган, 5-6 алманы турап, барысын бергә пешереп, иләк аша сыттырып чыгаралар да, өчтән бер өлешкә кимегәнче кайнаталар. 1 әр чәй кашыгы коры горчица, дарчин, төелгән кара борыч, 1 әр аш кашыгы серкә һәм тоз, 1 стакан шикәр, 5-7 данә канәфер өстәп, тагын 10-15 минут пешерәләр, кайнар килеш бүлеп, тимер капкач белән каплыйлар.

Киләчәкне онытмыйк

Фани дөньяга бирелеп, еш кына бакый тормыш турында онытып җибәрәбез. Әйе шул, тамак туйдырырлык, гаиләңне тәэмин итәрлек акча эшлисе дә бар, үз йортың да кирәк... Шушы бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләргә күмелеп, киләчәк ахирәт тормышы турында уйланырга вакыт та калмый.

Гамәлләр генә

Әгәр дә үзебезне мөселманга санасак, иманның бер нигезе булган кыямәт көненә ышанырга, үлгәннән соң яңадан терелеп, бу дөньяда кылган гамәлләребез өчен Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачагыбызны белеп торырга тиешбез.

Хисап көне булачагын белгән кеше барысы хакында да уй йөртәдер ул. Кесәләребездәге акча хәләл юл белән табылганмы? Алдалап яки ришвәт юлы, яисә кеше хакына кереп, җәбер-золым белән алынмаганмы? Динебез тыйган риба кебек начар ысул белән табылмаганмы ул акча? Ашаган ризыгыбыз хәләлме? Табыннарга динебездә таләп ителгән шартлар буенча чалынмаган терлек ите куелмыймы? Эчкән эчемлекләребез нинди? Акылны алып, кешелектән чыгара торган градуслысына үрелмибезме? Кешеләр белән мөгамәлә кылганда дөресен генә сөйлибезме, әллә булмаганны «булды» дип тә әйтеп куйгалыйбызмы? Туганлык җепләрен ныгытабызмы, әллә туганнарның кем икәнен дә оныта башладыкмы? Күңелебез кемгә бәйле? Безне юктан бар иткән Раббыбызгамы, әллә акчагамы?

Мондый сорауларны бик күп китереп була. Аларны үз-үзегезгә биреп, җавапларын да уйлап карагыз әле. Тормышта нинди генә гамәлләр – яхшысын йә начарын, файдалысын яки файдасызын кылып яшәсәк тә, кыямәт көнендә барысын да үз алдыбызда күрәчәкбез, Аллаһы Тәгалә бу турыда безне кисәткән: «Кыямәт көнне һәр кеше эшләгән изге эшләренең әҗерен алдына куелган килеш табар. Бозыклыкны эшләүчеләр дә гөнаһлары алларына куелганны күрерләр. Бу явыз эшләрнең иясе, явыз эшләре белән үзенең арасы бик ерак булуны теләр. Аллаһы сезне үзенең газабы белән куркыта. Аллаһы – колларына карата бик Мәрхәмәтле» («Әли Гыймран» сүрәсе, 30 нчы аять). Һәм, әлбәттә инде, игелекле эшләребезне дә күреп шатланачакбыз. Их, күбрәк эшлисе калган икән, дип үкенәчәкбез, әмма кире кайтып булмаячак. Ә менә калдырган намазларны, әти-әниләргә карата игелексезлекне, акчага табынып эшләгән гөнаһларны күреп, алардан ерагаясы, качасы килер, шулар аркасында бер дә газапка дучар буласыбыз килмәс. Әмма кыямәт көне газабыннан беркем дә кача алмас, анда ришвәт биреп котыла торган хөкемдарлар да, акча биреп яллый торган адвокатлар да булмаячак. Бары тик гамәлләребез генә калачак.

Ахирәт газабы

Кыямәт көненең катылыгыннан, аның дәһшәтеннән хәтта сабый балаларның да чәчләре агарыр: «И-и, кешеләр, ахирәт газабыннан ничек котылырсыз? Кыямәт көненең катылыгы гөнаһсыз сабый балаларның чәчләрен агартыр» («Муззәммил» сүрәсе, 17 нче аять). Җир тетрәгән вакытта да ишелмәгән, искиткеч нык булган таулар да ваканып бетеп, ком булыр, хәтта йомшак йонга әйләнер, ди Раббыбыз. «Карига» сүрәсендә, башыннан ахырына кадәр, шул хакта аңлатыла: «Катылыгы вә куркынычы белән җирне, вә күкләрне кагучы кыямәт көне. Никадәр каты куркынычлыдыр ул кыямәт көне. Ул кыямәт көненең катылыгы, вә куркынычы ни дәрәҗәдә икәнлеген сиңа кем белдерде? Ул көндә кешеләр котлары алынып куркуларыннан тузылган чикерткәләр кебек тузылып, таралып китәрләр һәм берберсен күрмәсләр. Вә таулар буялган, вә тетелгән йон кебек булырлар. Берәүнең, ягъни мөселманның, үлчәүдә гөнаһына караганда савабы авыррак, күбрәк булса, ул мөселман – җәннәттә үзе разый булган рәхәт тормыштадыр. Вә бер мөселманның үлчәүдә савабына караганда гөнаһы авыр килсә, ягъни яхшылыгына караганда яманлыгы күбрәк булса, аның урыны Һавийә исемле мәрхәмәтсез җәһәннәм булыр. Ул Һавийәнең нәрсә икәнен беләсеңме? Ул Һавийә – кыздырылган уттыр».

Алданмыйк

Адәм балаларын шундый куркыныч хисап көне көтсә дә, җәһәннәмнән котылу юлы бар икән, ул – Аллаһыга буйсыну, Аны гына бердәнбер илаһ дип танып, барча гыйбадәтләрне Аңа гына багышлау. Раббыбыз ризалыгын алыйм дип, кешедән бернәрсә көтмичә, Аллаһыдан гына өмет итеп, игелекле гамәлләр кылу, чөнки «үлчәүдә гөнаһына караганда савабы авыррак, күбрәк булса, ул мөселман – җәннәттә үзе разый булган рәхәт тормыштадыр».

Хәзер үз-үзебезгә сорау бирик инде: үлчәүләребез нәрсә белән тулы – хәерле гамәлләр кылып җыелган саваплар беләнме яки савапсыз гөнаһлы начар эшләр беләнме?! «...Үлчәүдә савабына караганда гөнаһы авыр килсә, ягъни яхшылыгына караганда яманлыгы күбрәк булса...» дигәнен, хәтта уйларга да куркыныч. Йөрәгебез тибә, тәнебездән җаныбыз чыкмаган икән, димәк, әле үзгәрә алабыз, әле соң түгел, бары тик гафил булмаска кирәк. Үлчәвебезне саваплы гамәлләр белән авырайтырга тырышырга кирәк. Шуңа да киләчәгебез турында уйланыйк, өч көнлек вакытлы дөньяга гына алданмыйк, барысы да бу дөньяда калачак: йортыбыз да, машинабыз, эшләп тапкан акчабыз да. Безнең белән бары тик кылган гамәлләребез генә китәчәк...

«Ул көндә җәһәннәм китерелсә, адәм баласының исенә төшәр, алданганын белер, вәгазьләнергә бик теләр, ләкин эш узган булыр. Һәм адәм баласы: «Ни үкенеч, дөньяда чагымда, ахирәтем өчен изге гамәлләр кылган булсамчы», – дип әйтер. Ул көндә, Аллаһының газабы илә һичкем газап кыла алмас, мәгәр Аллаһы әмере белән газап фәрештәләре газап кылырлар» («Фәҗер» сүрәсе, 23-25 нче аятьләр).

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының
Тәберде Чаллысы мәчете
мөгаллиме.

Намаздагы сүрәләрнең озынлыгы

– Намазның беренче рәкәгатендә кыска сүрә, ә икенчесендә озын сүрә укысаң, намаз дөрес буламы?

– Намазның икенче рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсеннән соң беренче рәкәгатьнекенә караганда кыскарак сүрәләр уку хәерлерәк. «Әл-Фәтәва әл-Хиндия» авторы болай дип яза: «Коръәнне беренче рәкәгатьтә икенчесенә караганда озынрак уку барлык галимнәр тарафыннан иртәнге намазның сөннәте дип санала. Имам Мөхәммәд рахимәһуллаһ: «Мин барлык намазларда да беренче рәкәгатьтә озынрак сүрә уку хәерле дип саныйм», – дип әйткән. Фәтва шушы фикердән чыгып бирелгән». Намазның беренче рәкәгатендә икенчесенә караганда 3 аять яисә аннан күпкә кыскарак сүрә уку мәкруһ тәнзиһән хөкемендә. Әмма намаз дөрес була. Имам Әл-Хәскафи исә «Дурр әл-мохтар» хезмәтендә болай яза: «Икенче рәкәгатьне беренчесенә караганда озынрак уку – мәкруһ.» Шунлыктан, икенче рәкәгатьтә укыган сүрәләрнең беренчесеннән кыскарак яисә шул аятьләрнең зурлыгына тигез булуы хәерлерәк.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче.

Әүвәбин намазы саналамы?

– Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының бер өлеше саналамы?

– Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә ахшам намазыннан соң укыла торган алты рәкәгать намаз искә алына. Бу намазның саваплары турында төрле чыганакларда төрле фикерләр бар: намазның савабы 20 ел намаз уку савабына тиң, гөнаһлар кичерелә, бу намазны укучы гөнаһларыннан тәүбә итүчеләр рәтендә булыр һ.б. «Әүвәбин» сүзе Аллаһыга «еш һәм күп тапкырлар кайту» мәгънәсендәге фигыльдән ясалган, ягъни Аллаһыга тәвәккәл кылып, Аннан гафу сорау мәгънәсен белдерә.

Ахшам намазының ике рәкәгать сөннәте әүвәбин намазының алты рәкәгатенә керүе хакында хәнәфи мәзһәбе галимнәре арасында каршылыклар бар. Имам Шурунбуләли «Мараки әл-Фәлак» хезмәтендә болай дип яза: «Ахшамнан соңгы алты рәкәгатькә ахшамның ике рәкәгате керми». Бу фикер буенча, башта ахшамның ике рәкәгать сөннәте, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазы укылырга тиеш. Башка фикер дә бар дидек. «Әд-Дурр әл-Мохтар» хезмәтендә мондый юллар бар: «Ике рәкәгать сөннәт муәккадә алты рәкәгатьнең мөстәхәб өлеше саналамы? Аларны бер сәлам белән укырга ярыймы? Әл-Камәл (Ибне Хөмәм) «әйе» дигән фикердә».

Иң элек ахшам намазының ике рәкәгать муәккадә сөннәтен, аннары алты рәкәгать әүвәбин намазын уку хәерлерәк. Башка фикерләр дә барын исәпкә алып, дүрт рәкәгать әүвәбин намазын уку да ярый. Ә Аллаһы – яхшырак Белүче.

Булат хәзрәт МӨБАРӘКОВ.

Өч чишмәле авыл

Удмуртиянең төньягындагы Глазов районында бердәнбер татар авылы – Парҗы бар. Байтак еллар элек хезмәттәшем Фәридә Хафизова белән Глазов якларына барып чыккан идек. Тик ул вакытта миңа Глазов шәһәре татарлары турында язарга туры килде, ә Фәридә Татар Парҗысын яктыртты. Кайтыр юлда Фәридә Татар Парҗысындагы инештә сакланган сөт шешәләре, консервланган банкалар турында сөйләп кайтты.

«Инеш өстендә кечкенә генә өй бар. Ишегендә йозак та юк, ә эче тулы – байлык. Биш-алты идән сайгагы. Сайгаксыз әлешендә сөтле шешәләр утыра. Табигый суыткыч бит бу. Акчасыз эшли. Халыкның зирәклегенә ис-акылың китә», – дип, Ф.Хафизова «Яңарыш» газетасына (2010 ел) язып та чыккан иде. Шул чагында ук ул инешне күрәсем килгән иде. Ул вакыттан соң 12 ел вакыт үтеп китте. Замана көнләп, сәгатьләп үзгәреп тора. Ә Парҗыда бу гадәт һаман да сакланды микән? Халкы ничек яши? Шуларны ачыклау өчен, янә Татар Парҗысына юл тоттык.

Татар Парҗысы авылы иң элек удмуртларныкы булып саналган. Аңа Парҗы атлы удмурт нигез салган. XVII гасыр ахырында әлеге авылга Киров өлкәсенең Нократ авылыннан Нияз исемле татар килеп төпләнә. 1782 елда Парҗыда 3 татар гаиләсе (22 ир һәм 24 хатын-кыз) яшәгән, дигән мәгълүмат та бар. 1891 елгы документларда удмуртлар белән татарлар сан буенча 1:3 күләмдә булган. 1897 елда биредә 40 татар гаиләсе яшәү билгеле. 1903 елда татарлар авылда мәчет төзергә уйлагач, Вятка губернаторы: «Удмуртларны авылдан чыгарып җибәргәндә генә мәчет төзергә рөхсәт биреләчәк», – дигән шарт куя. Ул вакытта авылда бары 15 удмурт гаиләсе генә калган була. 1906 елда авылның күрке булып мәчет калкып чыга һәм ул бүген дә авыл уртасында балкып утыра. Авыл үсә, татар халкы да арта. Касимов, Бузиков, Фәйзуллин, Абашев фамилияләре барлыкка килә. Халык игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Элек-электән үк авылда агач эшкәртү, йортлар, хуҗалык корылмалары ясау белән шөгыльләнүче балта осталары булган. Авылның планы XIX гасыр ахырыннан бирле үзгәрмәгән. Авыл алты өлешкә бүленгән: Абаул як, Югары як, Тау урам, Түбән як, Ар парза урам, Мулла урам. Мондый бүленеш бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

Парҗы урамнары

Ниһаять, мин дә Татар Парҗысында. Көне җәй ае кебек җылы, кояшлы. Шуңа күрә безне каршы алган «Глазов районы тарихи-туган якны өйрәнү музее комплексы» директоры Рәйдә Иванова, «Сепычкар» район бүлеге музее мөдире Фәридә Касимова, «Кыңгырау» ансамбленең актив әгъзасы Раилә Касимова белән без авыл урамнары белән хозурланып йөрдек.

1991 елда ук авыл урамнары асфальт белән түшәлгән, йортларга телефон кертелгән, су уздырылган. Парҗы авылында йортлар төзек, күбесе заманча итеп җиткерелгән. (Глазовтан 20 чакрым ераклыкта булгач, кайтучылар күп). Өй алды бакчаларында матур чәчәкләр үсә. Һәрбер хуҗалыкка балан-миләш куаклары, аларның җимешләре ямь биреп утыра.

Авылда өч чишмә бар: аринеш, авылинеш, абабыл инеш. Танышуны авыл уртасындагы авылинештән башладык. Тау итәгеннән саркып торган чишмәләр түгәрәк күл хасил иткән. Рәхәтләнеп казлар йөзеп йөри. Чишмәдә керләрне юарга улагы да, бәләге дә бар. Тирән улактан су тулып, мул булып ага. Олы паласларны югач, элеп куярга җайланмасы да бар. Олы мал суйганда, биредә эчәге дә юалар икән. Инеш өстендәге кечкенә өй дә, басмалары да яңартылган.

«Элекке авыл советы рәисе Исмәгыйль Касимов бригадасы бу инешнең бурасын, басмаларын яңартып куйган иде, хәзер дә балалары авылны ташламый», – ди Фәридә Касимова. Кызганычка, Исмәгыйль ага үткән елны вакытсыз вафат булган.

Ә абавыл инешенә төшкәч, элек хезмәттәшем Фәридә Хафизова сөйләгән хикмәтләргә тап булдым. Заманалар үзгәрсә дә, Парҗыда йозаксыз кечкенә өйнең идәне астында һаман консервланган банкалар саклана. Яшермим, матур итеп тезелеп утырган банкаларны күргәч, берсен булса да ачып карыйсы килде. Әмма ярамый. Парҗылылар кеше әйберләренә тими. Авылга шәһәрдән күчеп кайтучылар байтак булса да, күз тимәсен, бу гадәт сакланган. Абавыл инешенә дә юл чистартылган, чүп үләннәре чабылган. Раилә Касимова әлеге чишмәдән көн дә су алып кайта икән. Бу көнне дә ул чишмәнең тешеңне сындырырлык суыннан курыкмыйча керен дә чайкап күрсәтте, көянтә-чиләген тотып, суын да алып кайтты.

«Авылның яме ул – әбиләр, балалар, эшләүче кешеләр һәм мал-туар. Хәзер малларны үзебез өчен генә үстерәбез. Авылда сыер аз инде. Элек, әлбәттә, әбиләр урамга чыгып эскәмияләрдә утыра иде. Аларның өйдә эшләргә киленнәре, балалары булган. Ә хәзер бөтен эш үзебездә. Урамда утырырга вакытыбыз юк», – ди Р.Касимова.

Авылда шулай ук ишекләргә ялган йозаклар кую гадәте дә сакланган әле. Ә көтмәгәндә килеп кергән кунакларны алар шишара пешереп сыйлыйлар икән. Шишара ул печенье кебек. Ул сөт, йомырка, шикәр салып ясалган камырдан ясала. Камырны төрле формаларда кисеп, мичтә пешерәләр.

Мин Парҗы авылында тагын бер күркәм гадәткә тап булдым, монда авылны төзекләндерү фонды бар. Авылларда мондый фонд булуын беренче тапкыр ишетүем. «Һәрбер хуҗалыктан ай саен 100 сум акча биреп баралар, әлбәттә, бирми калдыручылар да бар. Әмма халыкның күп өлеше үзләреннән өлеш кертә», – ди Ф.Касимова. Әйе, авылны карап, төзәтеп торулары Парҗы урамнарыннан үткәндә дә күзгә ташланды. Монда кешеләр үзләренең хуҗалыкларыннан тыш, яндагы мәйданнарны да чистарта...

Вакытында Татар Парҗысында мәктәп, балалар бакчасы, клуб, медпункт булган. Тик барысы да бер-бер артлы ябылган. Бүген авыл халкына бәйрәмнәрдә җыела торган урын да калмаган. Без дә авыл халкы белән беседкада гына очраштык.

«Бүген без ике бәйгедә: «Инициативалы бюджетлаштыру» һәм «Удмуртия республикасының иң яхшы муниципаль проекты»нда җиңү яуладык. Беренче конкурста җиңгән өчен безгә миллион җиде йөз кырык сум акча бирделәр. Бу акчага без клуб бинасын төзекләндерәчәкбез. Аның түбәсен яңартабыз, җылылык уздырылачак, идәне, диварлары яңартылачак. Икенче конкурста җиңгән өчен бирелгән 300 мең сум акчага сәхнә ясалачак, урындыклар алыначак, баскычлар эшләнәчәк. Бу проектны тормышка ашыру өчен авыл халкы да үзеннән өлеш кертте. Фәридә Касимова халык белән сөйләшеп, алардан 160 мең сум акча җыйды. Төзекләндерү эшләре ел ахырында тәмамланыр дип өметләнәбез. Без аны татар үзәге дип ачачакбыз», – ди Рәйдә Иванова.

«Парҗының элекке авыл картасы булдырылды. Үзәк ачылгач, аны яңартып элеп куячакбыз. Яшь буын элекке авыл планына карап, әби-бабайларының кайда яшәгәнлекләрен күрер. Бездә Касимовлар, Рәхимов, Бузиковлар шәҗәрәсе бар. Аларны Габдулла Хәмитов ясаган. Ул башланган эшне без дәвам иттек. Касимовлар җыенына кайткан бик күп кешеләр ул шәҗәрәләрне фотога төшереп китте. Рәхмәт белдерделәр. Татар үзәге музей, клуб ролен дә үтәячәк. Бездә «Кыңгырау» ансамбле эшли. Иске клуб булганда спектакль куя идек. Татар телендәге китаплар, газета-журналлар белән баетырбыз. Җәй көннәрендә оныклар кайта. Алар авылга кайткач, «рәхмәт» сүзләрен әйтергә, санарга өйрәнеп китә. Кечкенәдән ишетеп калсалар, онытмыйлар. Аларны да татар үзәгенә тартырбыз», – дип дәвам итте Фәридә Касимова.

Безнең белән очрашуга килүче апа-абыйлар арасында Сәлим хәзрәттән кала, барысы да хатын-кызлар иде. Безне каршы алган һәм озатып йөрүче ханымнарга бу хакта искәртеп алгач: «Безнең авылда – матриархат. Оештырган чараларга ир-атларыбыз килергә мөмкин. Әмма милли тормышыбызны, башка төр чараларны оештыру эшләрендә бары хатын-кызлар гына җигелеп тарта», – ди Рәйдә Иванова. Әйе, элек-электән гаилә йөген, ил йөген тарткан ир-атлар дилбегәне хатын-кызларга тапшырды шул. Кызганыч, татар ир-атлары да заман шаукымына иярде. Парҗылылар да бу яңа гадәткә буйсынган, шунысы кызганычрак.

Рилия ЗАКИРОВА.
«Яңарыш» газетасы. Ижау.

Белеп ябыгу зарур

Галимнәр раславынча, кинәт ябыгу кеше организмы, тәгәлрәге, бавыр өчен экчечелектән дә куркынычрак икән. Эш шунда: тиз арада ябыкканда, тире асты катламындагы май "ирекккә" чыга, канга эләгә һәм тамырлар буйлап бавырга барып житә. Анда ул тамчы булып утыра, шуның нәтиҗәсендә әгъзада май тукымага сеңә. Атнасына 0,5-1 килодан да артыгракка ябыгырга ярамый. Хәзер исә аена 5-15 кило авырлык югалтуга китерә торган препаратлар сатыла, алар токсик гепатит китереп чыгарырга мөмкин. Статистика буенча, бавыр авыруларыннан интегүчеләрнең күпчелеге – исерткеч эчемлек белән мавыгучылар һәм гепатит кичергән кешеләр. Бавыр – тулаем диярлек торгызылуга сәләтле бердәнбер әгъза. Бавыр күзәнәкләре 4 ай эчендә үзләренең беренчел күләменең 75 процентына кадәр кире торгызылырга мөмкин, шулай да аны саклау зарур.

("Die Presse").

Цуккини аша!

Табиб-диетолог Джозеф Сент-Пьер ябыгу өчен цуккини һәм брюссель кәбестәсе кебек крахмалсыз яшелчәләр ашарга киңәш итә. Бәрәңге, кукуруз, кабак кебек крахмаллы яшелчәләр дә сәламәтлек өчен файдалы. Әммә ябыгырга теләүчеләргә крахмалсызларын сайлау яхшырак, чөнки аларда калорияләр һәм углеводлар азрак. Сент-Пьер С витаминына бай цуккинины, составында майлы омега-3 кислоталары булган брюссель кәбестәсен, калий, магний, В һәм К витаминнарына бай шпинатны иң файдалыга саный. Белгеч шулай ук рационга клетчатка һәм калийга бай кыяр белән чәчәк кәбестәне дә өстәргә тәкъдим итә.

("Health News Hub").

Уңышка ирешү сере

Күкрәк сөтен имеп үскән сабыйларның киләчәктә югары социаль статуска ирешү һәм баш әйләндергеч карьера ясау ихтималы зуррак. 34 мең кешенең социаль күрсәткечләрен һәм интеллектуаль сәләтен тикшергән Лондон университеты көллияте галимнәре шундый фикергә килгән. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, күкрәк сөтен имезеп үстерү социаль үсеш ихтималын 24 процентка арттыра һәм тормыш баскычыннан аска тәгәрәү ихтималын 20 процентка киметә икән. Күкрәк сөте балаларның неврологик үсешен яхшырта, бу исә аларның акыл сәләтенә уңай тәэсир итә. Имезеп үстерелгән баланың стрессларга бирешү ихтималы да кимрәк, чөнки ул ашаганда әнисе белән тыгыз бәйләнешкә керә һәм тынычлана. Күкрәк сөте баланың баш миенә тизрәк үсәргә дә булыша. Кимендә 3 ай гына булса да имезелгән сабыйның баш миендә сөйләм, эмоцияләр һәм танып-белү сәләтенә җаваплы зоналар 2 яшькә җиткәндә күбрәк үсешкә ирешкән була.

("КП").

Нәрсә ул ләззәт?

Британиядәге Манчестер университеты галимнәре, төрле илләрдә яшәүче кешеләрне сораштырып, аларга иң зур ләззәтне нәрсә бирүен ачыклаган. Нәтиҗәдә 50 пункттан торган исемлек төзелгән. Андагы иң-иң рәхәтлекләр мондый булып чыккан: көн буена ач торганнан соң тәмле ризык ашый башлау; чиста урын-җиргә ятып йоклау; чит кешегә аталган хатны ачып уку; башкаларның телефоннан сөйләшкәнен сиздерми генә тыңлап тору; яңа машинада җилдерү; төчкерү; яңа әйбер сатып алу; кулга зур акча керү; күңелгә ятышсыз кешенең яки чакырылмаган кунакның ниһаять чыгып китүе һ.б.

("Le Figaro").



Хәзинә кая киткән?

1942 елның ноябрендә ленд-лиз буенча җибәрелгән корал белән җиһазлар өчен түләү сыйфатында алтын һәм көмеш коелмалар тутырылган "Ulster Queen" крейсеры СССРдан АКШка юнәлә. Ул Мурманскидан чыгып, 13 көннән соң Шотландиянең Гринок портына килеп җитә, анда алтын-көмешле авыр әрҗәләрне башка суднога күчереп төйиләр дә, Америкага озаталар. Күчергәндә, бер әрҗә алтын коелма ни рәвешледер Клайд елгасына төшеп китә. Менә шул хәзинәнең табылганмы-юкмы икәнлеге әлегә кадәр билгесез. Аның турында корабль инженеры Леонард Томас көндәлекләреннән белеп алганнар. Үз иминлеген кайгыртып, Томас көндәлеген яшереп тоткан, андагы язмаларны шифрлаган. 2000 елда, 88 яшендә генә, ул аларның шифрын кызына ачкан. Леона Томас шул язмаларны бастырып чыгарган. Берничә миллион долларга бәяләнә торган әлеге кыйммәтле йөк бәлки әле хәзер дә Клайд елгасы төбендә ятадыр, бәлки инде шул вакытта ук кемнеңдер кулына эләккәндер – бусы һаман билгесез.

("The Daily Mail").

Игезәкләр фаҗигасе

1980 елда 19 яшьлек Роберт Шафран, Нью-Йорк янәшәсендәге Салливан округындагы колледжга укырга кергәч, беренче көнне үк үзенә Эдди дип килеп эндәшүчеләр күп булуга гаҗәпләнә. Тулай торактагы бүлмәсенә кергәч исә Робертның күршесе Майкл Домитц аптырап кала: яңа бүлмәдәше былтыр аның белән бергә яшәп, быел башка уку йортына күчкән Эдди Галландка ике тамчы су кебек охшаган икән бит! Икесенең дә 1961 елның 12 июлендә туусы да ачыклангач, шик калмый: бу егетләр – игезәкләр. Тиз арада Эддины эзләп табалар. Аларның IQ дәрәҗәсе, сөйләшү рәвешләре, яраткан ризыклары да бер үк төрле булып чыга, икесенең дә бер үк төрле китаплар укырга, фильмнар карарга яратуы ачыклана. Ике туганның 19 елдан соң табышуы матбугатта шау-шу куптара, нәтиҗәдә өченче игезәк – Дэвид Келлман табыла. Егетләр бер-берсеннән аерылмаска карар кыла, өчесе дә халыкара маркетинг буенча укырга керә, бергәләп ресторан ачалар, уңышлы гына эшләп китәләр. Әммә Эдди әледән-әле күңел төшенкелегеннән интегә һәм 33 яшендә үзенә кул сала. Шуннан соң Роберт – адвокат, Дэвид иминиятче булып эшли башлый. Әлеге өч игезәк тарихы журналист һәм язучы Лоуренс Райтка тынгы бирми, ул тикшеренү үткәрергә була. Нәтиҗәдә игезәкләрне фәнни тәҗрибә аркасында бер-берсеннән аерулары ачыклана – психоаналитик, Яһүд гаилә советы каршындагы Балаль үстерү үзәге директоры Питер Нойбауэр кеше холкы формалашуга нәрсәнең (табигатьме, тәрбиЯме) зуррак йогынты ясавын дәлилләмәкче була. Ул уллыкка бирү агентлыгын өч игезәк туганны өч төрле керемле гаиләгә бирергә күндерә: Роберт – бай, Эдди – урта хәлле, Дэвид фәкыйрь гаиләгә эләгә. Психологлар балаларны даими күзәтеп тора. (Соңрак әлеге экспериментта тагын 4 мең пар игезәкнең катнашуы ачыклана, әммә аларның берсе дә бу турыда белми.) Роберт белән Дэвид, тугач ук бер-берсеннән аерулары өчен Нойбауэр аларның кичерүен үтенер дип өметләнсә дә, психоаналитик, 2008 елда бакыйлыкка күчкәнче, үзен хаклы булган дип саный. Чөнки ул әлеге тәҗрибәсе белән геннарның кешегә үзе тәрбияләнгән мохиттән көчлерәк йогынты ясавын дәлилли.

("АиФ").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

17 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35, 19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рәшидә Җиһаншина турында телеочерк. 6+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВЕРНЕШЬСЯ - ПОГОВОРИМ». 12+
14.35 «Россия. Связь времен». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Путилов.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 «Самара. Дом Сандры».
8.45 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
8.55, 16.30 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Встречи с Ильей Глазуновым».
12.10 «Рядом с медведями. Дневник воздушной экспедиции».
13.10 Линия жизни. Александр Аузан.
14.00 Дороги старых мастеров. «Палех».
14.15 «Что ты сделал для Родины?»
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
17.35 Д.Хворостовскому посвящается... Дмитрий Хворостовский и Олег Бошнякович.
18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Российская государственная библиотека до и после Ленинки».
21.15 «Сати. Нескучная классика...»
22.00 «СПРУТ-4».
23.40 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Сишәмбе

18 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.45 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Кыргый океан серләре». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән - йөрәккә». Әнвәр Гобәйдуллин турында телеочерк. 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВЕРНЕШЬСЯ - ПОГОВОРИМ». 12+
14.35 «Россия. Связь времен». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
8.45 Цвет времени. Надя Рушева.
8.55, 16.30 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Встречи с Ильей Глазуновым».
12.00 «Три тайны адвоката Плевако».
12.30 «Игра в бисер» «Томас Манн. «Иосиф и его братья».
13.10, 22.00 «СПРУТ-4».
14.50 Цвет времени. Марк Шагал.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Андрей Рябушкин».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.35 Д.Хворостовскому посвящается... Дмитрий Хворостовский и Михаил Аркадьев.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 Искусственный отбор.
21.15 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Чәршәмбе

19 октябрь

Телевизор караучылар игътибарына! Чәршәмбе, 19 октябрь көнне, профилактика чаралары үткәрү сәбәпле, «Татарстан - Яңа гасыр» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында 9.00 сәгатькә кадәр тапшырулар трансляцияләнми.

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 0.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
14.45 «Татар халык җырлары».
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
17.30 «Трибуна Нового Века». 12+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Металлург» (Мг). 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

9.00, 19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 Спектакль «Умырзая». 12+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
20.30 «Юлчы». 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «В БЕГАХ». 12+
14.35 «Россия. Связь времен». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Рина Зеленая».
12.15 «Забытое ремесло».
12.30 Искусственный отбор.
13.10, 22.00 «СПРУТ-4».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
16.30 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
17.35 Д.Хворостовскому посвящается... Дмитрий Хворостовский и Иварс Илья.
18.25 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 Абсолютный слух.
21.15 Власть факта. «Накануне Петра».
23.30 «Первые в мире».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

20 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 22.00 Ежегодное послание Президента РТ Р.Н.Минниханова Государственному Совету РТ.
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45, 0.40 «Каравай». 6+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Туган авылым». 6+
10.00 Татарстан Президенты Р.Н.Миңнехановның Дәүләт Советына еллык юлламасы. 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15, 20.30, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «В БЕГАХ». 12+
14.35 «Россия. Связь времен». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.

9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
8.45 Цвет времени. Леонардо да Винчи. «Джоконда».
8.55, 16.15 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 Концерт «Мои любимые мелодии. Муслим Магомаев».
12.20 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
12.30 Абсолютный слух.
13.10, 22.00 «СПРУТ-4».
14.45 «Забытое ремесло».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Люди великой степи».
15.50 «Огюст Монферран».
17.20 Большие и маленькие.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Борис Минаев. «Площадь Борьбы».
20.30 «Туполев». «Андрей Туполев».
21.15 «Энигма. Андрей Хржановский».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Җомга

21 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ФАРЦА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «РЕКА ПАМЯТИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Күңел - җыру». Георгий Ибушев турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15 «Родная земля». 12+

19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «В ПЛЕНУ У САКУРЫ». 16+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Мировой рынок». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.50 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Императрицы Древнего Рима: женщины на вершине власти».
8.45 Цвет времени. Василий Кандинский. «Желтый звук».
8.55 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
10.15 «РЕВИЗОР».
12.25 Цвет времени. Густав Климт. «Золотая Адель».
12.40 Открытая книга. Борис Минаев. «Площадь Борьбы».
13.10 «СПРУТ-4».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Андрей Хржановский».
16.20 «ПЕЧНИКИ».
17.40 Д.Хворостовскому посвящается... Дмитрий Хворостовский, Николай Калинин и Национальный академический оркестр народных инструментов России им. Н.П. Осипова.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 Линия жизни. Иван Агапов.
20.40 Искатели. «Тайна архива 44».
21.25 «РОДНЯ».
23.00 «2 Верник 2».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Шимбә

22 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+

9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 «ИСӘНМЕСЕЗ!» 12+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Салават Юлаев». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.15 «ПОЧТИ ЗНАМЕНИТЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы-тылсымчы Бакый Урманче». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Күңел - җыру». Георгий Ибушев турында телеочерк. 6+
14.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Яшик әле!» Разил Вәлиевнең юбилей кичәсе. 6+
23.05 Спектакль «Хуҗа Насретдин». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПАРК РАЗВЛЕЧЕНИЙ». 16+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
16.20 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛУЧШЕЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ». 16+
23.10 «МИЛЛИОНЕР». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.40 «А У НАС ВО ДВОРЕ...» 12+
16.55 «Горячий лед». Фигурное катание.
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период».
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.00 Лига Бокса. Россия-Куба.

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ВХОДЯ В ДОМ, ОГЛЯНИСЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВЕСНА ПЕРЕМЕН». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55 «ПЕЧНИКИ».
9.15 «Мы - грамотеи!»
9.55 Неизвестные маршруты России. «Томская область. От Парабели до Чулыма».

10.35 «РОДНЯ».
12.10 Земля людей. «Оленные чукчи. Там, где нет леса».
12.40 Черные дыры. Белые пятна.
13.20 «Великие мифы. Одиссея».
13.50 «Земля, взгляд из космоса».
14.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.35 «Раздумья на Родине».
16.10 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БУРАТИНО».
18.25 Линия жизни. Елена Санаева.
19.20 «Энциклопедия загадок».
19.50 «БЕЗЫМЯННАЯ ЗВЕЗДА».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»

5.15 «Спето в СССР». 12+
6.00 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

23 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «ИСӘНМЕСЕЗ!» 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 Габделфәт Сафин концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «КРАСАВИЦА И ЧУДОВИЩЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Хәйләсез - деньга файдасыз». 12+
8.40 «Яшәсәк тә еракта...» Айдар Гайнуллин концерты. 6+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Илфак Ибраһимов турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
13.50 Спектакль «Әлдермештән Әлмәндәр». 12+
16.20 «Гомер юлы». Резидә Шәрәфиева концерты. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Хәят». 12+
23.20 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»

5.00, 15.10 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+

6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
9.20 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛУЧШЕЕ ПРЕДЛОЖЕНИЕ». 16+
15.30 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПАРК РАЗВЛЕЧЕНИЙ». 16+
22.45 «500 ДНЕЙ ЛЕТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.30, 6.10 «ВОПРЕКИ ВСЕМУ». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.35 «УБОЙНАЯ СИЛА». 16+
16.35 «Горячий лед». Фигурное катание.
17.55 «Романовы». 12+
18.55 «Поем на кухне всей страной». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «ДЕВЯТЫЙ КАЛИБР». 18+

«РОССИЯ»

5.35 «ВЕСОМОЕ ЧУВСТВО». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «ВХОДЯ В ДОМ, ОГЛЯНИСЬ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «В яранге горит огонь».
6.55 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БУРАТИНО».
9.15 «Обыкновенный концерт».
9.45 Диалоги о животных.
10.25 Большие и маленькие.
12.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Балыбердин.
13.05 «Игра в бисер» «Судебные процессы в творчестве Ф.М. Достоевского».
13.45 «Элементы» с Ильёй Доронченковым.
14.15 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ РОГОНОСЕЦ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 Передача знаний.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «КЛЮЧ БЕЗ ПРАВА ПЕРЕДАЧИ».
21.45 Спектакль «Травиата».

«НТВ»

5.05 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.40 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер!» 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Бу көннәрдә Балтач район судында Казан арты төбәкләрендә кәсеп иткән тагын бер һөнәри мошенник эше карала. Кукмара районындагы Югары Чура дигән керәшен авылыннан Станислав Агачев читтән торып кына түгел, ә гади халыкны очрашып-сөйләшеп тә алдаган, акча да электрон рәвештә түгел, башлыча, кулдан-кулга тапшырылган. Шунысын да искәртеп үтик, аның кармагына эләккән уникe кешенең унысы, йомшаграк итеп әйтсәк, бик үк намуслы булмаган ысул белән, ягъни зур акчалар түләп шофер таныклыгын алырга йөрүчеләр.

Ялган яшерен калмый

1996 елгы С.Агачев гади авыл гаиләсендә туып үскән, мәктәптән соң ике техникумга кереп караса да, берсен дә тәмамлый алмаган, аның каруы, 17 яшендә урлап тотылып мәҗбүри эшләргә тартылып өлгергән, 19 яшендә өйләнешкән хатыны белән аерылышкач та балаларына алимент түләмәгән өчен 4 айлык төзәтү эшләренә, исерек килеш машина йөрткән өчен таныклыгын алдыргач та салмыш хәлдә тагын рульгә утырып мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән, кеше кыйнаган өчен административ тәртиптә 5 мең сум штрафка тартылган. Рәсми оешмалар бәяләмәсендә законсыз гамәлләре күрсәтелсә дә, ошбу авыл малаеның аралашучан вә әдәпле икәне дә әйтелә.

Соңгылары мошенниклар өчен бик тә мөһим сыйфатлар, әлбәттә. Юкса, адәм баласының айлар буена эшләп тапкан, бурычка җыйган акчасына җиңел генә ия булу мөмкин эш түгел. Танышы Г.Муллабаева ЮХИДИда юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча сынауны тапшыра алмагач, аңа «ярдәмгә» килә ул. Бик итагатьле итеп 85 мең тәңкә барәбәренә әлеге мәсьәләне хәл итә алуына ышандыра, ике көннән хатын-кызның эш урынында 60 мең сумны кесәсенә шудыра, тиздән бәһаләр арта бару һәм башка сәбәпләр уйлап чыгарып тагын 28 меңне күчерттерә. Шуннан соң шактый вакыт юкка чыгып торганнан соң, быел гыйнвар аенда яңадан пәйда була, вәгъдәләр яудыра, аз-азлап акча каера, шул рәвешле сатлык таныклыкның бәясе 104 мең сумга җитә. Аның сүзенә ышанган хатын-кыз Казанга барып сынаулар да биреп карый, ләкин «не сдал» дигән тамга алып чыга. Ахыр чиктә, теге бәндә таныклыкны өеңә китереп бирәм дип ышандыра. Әлбәттә, андый уе да, мөмкинлеге дә булмый аның.

«Клиент»ларны үзе эзләп таба Стас. Хәзерге заманда кыен эш түгел бу.

Әйтик, автомәктәп укытучыларыннан белешергә мөмкин. Байлар Сабасында инструктор начар укучы кызны атый, анысы 80 мең тәңкәгә булышырга әзер егетне хуплап каршы ала, 68 меңне үз өендә тапшыра, калганын соңрак электрон тәртиптә озата.

Рәттән өч тапкыр имтихан бирә алмаган Арча егете С.Агачевка 70 меңне тоттыра. Байлар Сабасында сатучы булып эшләп көн күргән хатын-кыз укып мәшәкатьләнмичә генә «права» ясап бирәм дип, 65 мең сум сораган алдар каракка 30 меңне биреп өлгерә. Балтач районында 2 нче төркем инвалид та шундый ук «хезмәт» өчен 100 мең сум сораган ир-атка 45 меңне бирә дә, расписка язарга куша, Агачев Агеев Руслан Эдуардович исеменнән кәгазь сырлап калдыра...

Таныш булмаган кешеләр арасында үзен Руслан дип танытучы егет карымагына транспорт йөртү хокукыннан мәхрүм ителүчеләр эләгә. Әтнә районында кибетче кыз шома егет белән танышкач, аны ярдәмгә мохтаҗ этисе янына җибәрә. Нәтиҗәдә, гаилә 120 мең сум акчасын суга сала. Арчадан Б.Хөрмәтуллиннан алдан 65 мең таләп ителә, акрынлап бәя арта, шуллер кесәсенә җәмгысы 93150 сум акча керә. Балтач район үзәгеннән А.Сабиров 115 мең, Карадуганнан С.Ильин 70 мең сум акчасыннан колак кага.

«Рено Дастер» машинасы хуҗасы З.Гамиров белән бөтенләй сәер хәл килеп чыга. Шофер танышы С.Агачевка, узып китү кагыйдәләрен бозган өчен, 5 мең сум штраф салуларын әйтә. Мошенник шунда ук аны куркытырга керешә, ягъни моның өчен 94 тәүлеккә кадәр ябып куярга, яисә ярты миллион сумга чаклы штраф салырга мөмкиннәр, дип чынлап торып шүрләтә. Һәм, әлбәттә, акча түләп ярдәм итәргә вәгъдә бирә. Гаҗәп, ләкин З.Гамиров аңа бар булган 16 мең акчасын тоттыра, аннан соң икеүләп Казанда машинасын автоломбардка тапшырып 50 мең акча алалар. Бу сәмән дә Агачев кулына эләгә. Гомуми зыян 66 мең сум тәшкил итә.

Агачевны куркытып кына калмыйча, бу хакта полициягә җиткерүчеләр дә табыла. Балтач оперативниклары аны җинаять өстендә тоткарлыйлар. Р.Шакировка 2018 елда алдырган «права»сын 120 мең сумга алып бирергә сүз бирә ул. Оперлар Шакиров кулына, алдаркаракка тапшыру өчен, тамга салынган акчалар тоттыра. Алыш-биреш ясалганнан соң, Агачев тоткарлана.

Быел гыйнвар-март айларында булган әлеге вакыйгаларны таный ул. Аңлап, алдан ук планлаштырып эшләдем, зарар күрүчеләр гозерен үтәргә исәбем һәм мөмкинлегем булмады дип белдерә. Бары тик үзенең 1960 елгы абзасын талавын танымый, төгәлрәк, бу хакта нинди дә булса аңлатма бирүдән баш тарта. Балтач эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе Е.Петрова зарар күргән пенсионердан аның каршында сорау ала. Ул сөйләгәннәргә кыскача гына тукталсак, абзый үзенә иске ГАЗель машинасы алырга уйлагач, Стаска мөрәҗәгать итә, анысы, әлбәттә ки, табарга ярдәм итәргә ышандыра. Шул нияттән, алар банкка барып, абзый исеменә кредит алалар, Агачев банкомат картасын үзендә калдыра һәм абзыйга әйтмичә, кыска гына вакыт эчендә 179 441 сум акчаны тотып бетерә. Дөрес, 100 мең сумны кире кайтара ул, әмма аңа 179441 сумны урлауда гаепләү белдерелә.

Шулай итеп ул 12 җинаятьчел гамәл буенча җавап тота. Күрәсең, алдап яшәү рәвешен сайлаган кешеләр иртәме-соңмы фаш ителәчәкләрен уйламый. Моның өчен кыйммәт түләргә туры киләчәк. Суд аларны берничә елга колониягә озатыр кебек.

Наил ВАХИТОВ.

Гомерлеккә төрмәгә

Сентябрь ахырында Татарстан Республикасының Югары судында Казанның Чуйков урамында өч кешене үтерү турындагы җинаять эше буенча хөкем карары чыгарылды. Гаепләнүче Рөстәм Мөхәммәдуллинны гомерлеккә ирегеннән мәхрүм итү турында җәза билгеләнде. Ул аерым режимлы колониягә озатылды. Мөхәммәдуллин фаҗига көнендә булган хәлләр турында бернәрсә дә хәтерләмәвен әйтә.

Эш материалларыннан күренгәнчә, узган елның 7 гыйнварында Рөстәм Мөхәммәдуллин йөргән кызы Камилә һәм аның әти-әнисе яши торган фатирга кунакка килгән. Кызның әти-әнисе (әнисе Фәридә Хәмәтҗанова озак еллар «Мәдәни җомга» газетасында хезмәт куя) белән егет арасында низаг чыга. Рөстәм пычак ала, ир белән хатынны чәнчи, соңыннан йөргән кызына ташлана. Экспертлар аларның гәүдәләрендә пычактан калган утызга якын җәрәхәт исәпли.

Тикшерүчеләр фикеренчә, егет барысын да планлаштырган һәм кибеттән аш-су пычагы сатып алган. Нәкъ менә шушы пычакны җинаять урынында тапканнан һәм ул төп дәлил буларак җинаять эшенә беркетелгән. Өстәвенә, тикшерү версиясе буенча, егетнең мотивы да булган – кызның әти-әнисе аларның очрашып йөрүенә рөхсәт бирмәгән.

Гаиләне үтергәннән соң Рөстәм үз-үзенә кул салмакчы була. Ул үзенең корсагына берничә тапкыр пычак белән чәнчи һәм фатир тәрәзәсеннән сикерә. Тикшерүчеләр һәм гаиләнең туганнары сүзләренчә, ул шикне башка кешегә күчерү өчен шундый адымга барган.

Рөстәм Мөхәммәдуллинга җәза билгеләгән вакытта исәпкә алынган барлык шартларны судья ике сәгатьтән артык укыды. Рөстәм Мөхәммәдуллинга гомерлек срок турындагы карарны зал көчле алкышлар белән каршы алды. Мәрхүмнәрнең туганнары һәм якыннары әлеге карар белән канәгать калды. Алар фикеренчә, бу каты җәза Мөхәммәдуллин кылган җинаятькә туры килә.

Хөкем карарына карамастан, Рөстәм Мөхәммәдуллин үз гаебен танымады.

Мавыктыргыч керамика



Снежана Хәйруллина җитәкләгән “Ишморат” керамика остаханәсе Казанның нәкъ үзәгендә үк урнашкан. “Кайчандыр бу йортта XVIII гасырның үтә бай сәүдәгәре И.Михляев яшәгән, – дип башлады сүзен керамика остасы. – Ә ул үз заманында Петр I белән яхшы мөнәсәбәттә булган. Остаханәбезнең М.Җәлил урамында урнашуы да безнең Ишморатовлар нәселе өчен символик мәгънәгә ия төсле. Чөнки каһарман шагыйрьнең “Моабит дәфтәрләре”н рус теленә Казанда беренче булып бик якын туганыбыз Суфия апа тәрҗемә иткән, ә дәү әниебез, Г.Камал исемендәге дәүләт академия театры артисткасы Рәшидә Җиһаншина исә “Моңлы бер җыр” спектаклендә Муса Җәлилнең әнисе ролен дә күңелләргә үтеп керерлек итеп башкарган. Аның улы исә, газиз әтием Рөстәм Ишморатов, бар хыял-планнарымны да хуплый килде. Остаханәбез өчен беренче махсус мичне алырга кирәк булганда, мин аның киңәшенә дә колак салдым. Әтием Рөстәм Риза улы Казан дәүләт университетының география факультетын тәмамлап, озак еллар конструкторлык бюросында инженер-конструктор булып эшләде. Ул уйлап табучы да иде, балалар өчен төрле уеннар да иҗат итте. Мин үзем исә башка һөнәр сайладым. Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, теш табибәсе булып эшли башладым. Бернičә елдан соң сәүдә буенча менеджер эшенә күчтем, гаилә тормышын алып бару, балалар үстерү белән бәйле куанычлы мәшәкатьләр дә өстәлде. Улым мәктәпкә укырга кергәч тә, рәсем ясау белән шөгыльләнә башлады. Һәм мин дә ясап карарга булдым. Күрәм: рәсемнәрем башкаларныкыннан аерылып тора, төгәлрәк тә килеп чыгалар. Шулай итеп, үземдә рәссамлык сәләте булуын ачыкладым. Һәм кырык яшемдә Казанның Халык сәнгате һөнәрләре техникумына укырга кердем. Ә анда көндезге уку гына бар иде, шулай да каушап калмадым, бер ел укып, рәссам-бизәүче белгечлеген алдым. Мин бит әле педагог-психолог белемен дә үзләштердем. Бу өлкәдә дә үз уңышларым бар. Бергә укыган иҗатташларым белән 7 ел шушы остаханәдә эш алып барабыз, чөнки керамика белән шөгыльләнү барыбызның да күңелен яулап алды. Миңа үзле балчык терапиясе бик ошый, аның белән мавыгучы кешеләрнең күбрәк булуын телим”.

Снежана Рөстәм кызы коронавирус зәхмәтенә кадәр үк ТИСБИ лаек булган грант программасы нигезендә мәрхәмәтле укыту проекты эшенә кушылган һәм сәламәтлекләре чикле, шул исәптән сукыр кешеләрне керамика сәнгатенә өйрәткән. “Башта керамикага өйрәнергә дип барлыгы 170 кеше килгән иде, соңрак аларның саны 20 гә генә калды... Үзле балчыктан савыт-саба, башка төр әйберләр ясау – җиңел хезмәт түгел. Әмма бу сәнгатьтә һәрчак үсеш мөмкинлеге булуы барыбер күпләрне үзенә җәлеп итә. Менә без дә быел яз һөнәребез нечкәлекләренә төшенер өчен, ике атнага Үзбәкстанга барып кайттык. Үзбәк керамикачылары биргән тәҗрибәдән бик канәгать калдык! Димәк, үз иҗатыбызда аларда кабул ителгән матурдан-матур формаларны да кулланачакбыз. Үзбәкстанда күп гасырлар буе дәвам итүче җирле сәнгать төрләрен пропагандалау киң колач алган, дәүләт программалары буенча теләге булган һәркемне бирегә үз сәнгатьләренә төшендерәләр, кеше юл бәясен генә түли. Ә керамикачылар анда, чыннан да, күп. Фирганә даласының иң борынгы каласы Риштанда барлыгы илле мең кеше яши, шуларның бер меңе – керамика осталары. Бу шәһәр Үзәк Азиянең үзенчәлекле глазурьлы керамика ясау үзәге дә...”

Снежана Хәйруллинаның үз иҗат әйберләренә дә игътибар иттем: остаханә киштәләрендә алар байтак. Биредәге татар милли орнаментлары белән бизәлгәннәре дә, үз фантазия көче булышлыгында туган үзенчәлекле савыт-сабалар да, интерьер бизәү өчен кирәкле сынчыклар да... һәммәсе сокландыргыч итеп эшләнгән!

“Ишморат” олылар өчен дә, балалар өчен дә осталык дәресләре оештыра. Остаханәнең “Талантлар университеты” һәм сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыкларга булышлык күрсәтә торган “Сириус” республика үзәге белән берлектәге нәтиҗәле хезмәтләре дә җитәрлек.

Болардан кала Снежана Рөстәм кызының киләчәктә тормышка ашырырга теләгән тагы бер якты хыялы бар: ул Казан үзәгендәге шушы ишегалды керамик мозаикалы ишегалды итеп үзгәртеп бизәргә тели. “Хыялым тормышка ашса, әлеге ишегалды башкала халкын һәм туристларны да үзенә җәлеп итеп торырдай матур җир буларак танылыр иде!” – ди иҗатчы.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 14.10.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2774

16+